КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№ 17
10 ноябрь
1995 ел

95 елның июленнән
баш... чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



ҮГЕНГЕ САНДА:

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Хәзерге тормышның кыйбласызлыгы, гадел хезмәт кешеләренең властьлар тарафыннан тагын бер тапкыр, элеккеләреннән дә шәрәрәк алдануы яңа буынның әхлакый савыгуына ярдәм итми, киресенчә, гаделсезлекләргә җавап булып, шәфкатьсезлек, миһербансызлык, җинаятьчелек үсә.

Юныс САФИУЛЛИН. Шәп драматурглар да вакытлы гына, шул чорда гына билгеле бер роль уйный ала торган цирк, концерт, балаган алымнары катнашлысын үзләренә мәңгелек канун итеп алдылар һәм иҗат, эзләнү, фәлсәфи уйлану кебек төп ...ралларын үтмәс хәл... төшерделәр.

Марс МАКАРОВ. ...айбер үзешчән авто...лар, тәнкыйтьнең юга...ыннан файдаланып, ...хнәдән сәнгати кыйм...те булмаган мәгънә..., тозсыз һәм төссез ...ирлар «яңгыры» сибә ...шладылар.

Ирна ГАТОВА. ...ек, хәтта патша за...нында да җәмәгать ...шмаларыннан салым ...әтмәгәннәр, ә хәзер ...тр берлеге әгъзалары ...әсеннән, йә булмаса, ...маячеләр биргән ак...ан да салым тоты..., без икеләтә, өчләтә хәерчелеккә дучар ...әбез.

Ә балачак, җылы карлар булып,
Хәтерләрдә мәңге калачак...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Һәртөрле зур байлык артына җинаять яшеренгән, дигән бер бөек француз язучысы. Ни аяныч, империянең мәңге туймас нәфесен канәгатьләндерер өчен гасырлар буе бил бөгә торган безнең халык та, эшләп кем баеган, дип әйтергә күнегеп киткән. Шулайдыр, әгәр бу илдә эшләп баеп булса, үнике яшеннән үгез җигеп, җир сөрә башлаган безнең әтиләр лимузинга утырып йөрер иде... Әллә, мин әйтәм, безгә дә берәр фирка укмаштырып, депутатлыкка ыргылып карарга микән, шайтан алгыры.

Газинур МОРАТ

МИН ӘЙТТЕМ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ

«Сез татарлар түгел инде»

Ат җигелгән арба өстендә орчык кадәр бер малай кучерлык итеп азаплана. Ферма атын бөйдән чишеп алган да, бер йөреп килергә җыена бугай. Миңа да яхшылык эшләмәкче: «Әйдә, утырасыңмы?» — ди.

— Рәхмәт, барып җитәм бит инде, — дим, якындагы үрне күрсәтеп һәм атлавымны дәвам итерәм. Шулчак артымда ачудан ысылдап чыккан галәмәт ямьсез сүгенү сүзләре ишетәм дә, имәнеп борылып карыйм. Миңа түгел, «кучер»ның нәрсә теләгәнен төшенмәгән атка җикеренүе икән. Абау ла, «сүзләрнең» бу кадәр каплаулыларын кемнәрдән өйрәнгән ул? Һәм өйдән читтә үз балаларыбыз ничек сөйләшә икән? Алар да бит шушы тупас җәмгыять җимешләре.

Бервакыт бер таҗик карты белән халыкның гореф-гадәтләре, әдәбе-тәртибе хакында сөйләшеп торган идек. Ул әйтә куйды:

— Сез күптән татарлар түгел бит инде. Хатыннарыгыз хөмер эчә, тәмсез телләнә, ирләренә дә, сава торган сыерына да телесә ни кычкыра, бозыклык кыла. Юк, безнең белән диндәш татарлар түгел инде сез...

Карасана, милләтнең ниндиләгән хатын-кызларыбыздагы әхлакый сыйфатларга карап бәяләмәкче була бит бу. Һәм, бәлки, ул хаклыдыр да: балага иң зур йогынтыны алар ясый, әдәп-инсафны алар тәрбияли ич. Ни дип каршы төшәргә, ничек кире кагарга соң карт таҗикның сүзләрен? Дөрес әйтмисең, безнең татарда андыйлар бик аз, дияргеме? Аз микән соң? Әллә беренче карауга бик инсафлы күренгән Тәңкабикәләребезнең эчендә дә, Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясеннән Дивана әйтмешли, «бөгәрләнеп-бөгәрләнеп, бөгәрләнеп-бөгәрләнеп кара елан ята»мы? Шулай булмаса...

Нурия, авыл читендәге бәрәңге бакчасына баргач, сугышта җиңгән амазонкалардай, чыраена ярсу-горур кыяфәт белән кайтты. «Сәбәбе» дә зур шул. Бакча читендә, эшкә комачау ясап, зур гына тимер кисәге ята икән. Хатын шул тимерне юлның икенче ягына алып ташлауга, өйләреннән Шәмсия чыга:

— Нәрсәгә басу чүбен безнең өй каршына ыргытасың? — ди ул, һәм тимерне элекке урынына атып бәрә.

— Минем бакча ягына фәлән-төгән дип тимер ташлыйсыңмыни? — ди Нурия һәм моңа кадәр көн саен күрешеп, бер үк сукмактан эшкә йөргән киленнәр, мәгънәсезгә ярсып-ярсып, сүзләрнең иң үтергечләрен сайлап, талашалар.

— Махы бирмәдем, эчтә йөргән бөтен ачуны әйтеп бетердем, — ди Нурия, симез чыраен кот очарлык канәгатьлек белән балкытып.

Эчтә йөргән ачу! Менә нәрсә ярсыта безне! Күңелендә ачу, бөтеннәргә карата кара фикер бар икән, сәбәбен табып, бер бәреп чыгачак инде ул. Кемнәргәдер шул зәһәрен яудыру өчен «теге елны» гекачепе хакимлек иткән өч көн булышты, ә күпләр андый җай да көтеп тормыйлар: ачулы буын бер-берсенә ташланырга гына тора. Ә кайтавазы, әнә, балаларыбызда, аларның күңел катылыгында. Өлкәннәр үрнәгеннән ерак китсеннәрмени! Кайчандыр иплелек үрнәге саналган авылларыбызда хәзер яшь кенә егетләр тәмсез сүз катнаштырмыйча бер җөмлә дә оештырып сөйләшә белмиләр.

Бервакыт ишек алдында нидер эшләп йөргәндә авылдашым Сәүбән Шакирҗанов килеп керде. Авылның иң бәхетсез буыны вәкиле — сугыш чоры үсмере ул. Менә шушылар инде ун-унбер яшьтә ат белән янәшә тырмага, тагын бер-ике елдан сыер белән бергә сукага җигелгәннәр. Тормыш аз-маз рәтләнеп, ипи ашый башлаган елларда Сәүбән абый ат белән урман ташыды, тонналы йөкләр төяп Казанга йөрде, сөрде, чәчте, урды. Хәзер бер энесе һәм өч улы колхозда механизатор, кызы укытучы, үзе пенсиядә. Бүген аны, өлкәннәр көне дип, ашханәгә күмәк ашка чакырганнар һәм шунда хуҗалык рәисе Ришат Нургалиев аңа нәрсәдер әйткән. Нәрсәдер, дим, чөнки Сәүбән абый аны үзе дә сөйләп аңлата алмый: сүз әйтә башлый да елап җибәрә. «Сөйли алмыйм, күңелем тулды, чөнки күңелем булды, — ди үзе һәм шулай дәвам итә. — Мин үз гомеремдә унсигез колхоз председателе белән эшләдем, мактаганы да, төрмәгә утыртып черетәм дип янаганы да булды, әмма ләкин бүгенгедәй хөрмәт күргәнем юк иде».

Ришаттан нинди генә җылы сүз ишетте икән соң бу ветеран, дип уйлыйм һәм уйлана торгач җавап тапкандай булам: монда сер рәис сүзенең нинди булуында түгелдер, мөгаен. Үләрлек булып ачыккан кешегә бәрәңге кушып пешерелгән бер телем икмәк тә җәннәт сые булып тоелырга мөмкин ич. Ә без җылы сүзгә, әчкерсез мөгамәләгә шундый ук ачлар-мохтаҗлар түгелмени? Сирәк хөрмәт нәрсә генә эшләтми безне! Һаман уйлап йөрим: әгәр гекачепе һәм урыннарда аны яклаган җитәкчеләр безнең тормышыбызга танклар, яман кисәтү-тыюлар, «монменттан файдаланырга!» дигән коточкыч күрсәтмәләр белән кермичә, ил юксылларына иманлы җылы сүз белән, икмәк белән килсәләр, тарафдарларын да табарлар, җиңеп тә чыгарлар иде. Тик алар да эчләрендәге ачуны яшерә белмәделәр һәм ул чорда аз-маз иркенрәк сулый башлаган халыкны кабат шиккә салдылар, нәкъ шуның белән отылдылар.

Сугыш чоры тракторчысы Галимә апаның сөйләгәне бар: тракторы ватылгач, шуны төзәтәм дип, МТСтан ничәдер смена кайтмыйча эшли бу. Ашарына юк, авылы ерак. Хәер, өендә дә эне-сеңелләре ач утыра. Үләем шушы икән, дип уйлый Галимә һәм үзенең чыннан да сүнеп баруын сизә. Шул вакыт бригадир — авылдашы Мотыйк МТС ашханәсеннән ниндидер юллар белән Галимәгә бер телинкә аш алып бирә.

— Соңыннан, бергә эшләгәндә, Мотыйкка бик хәтерем калган чаклар да булды, әллә нилләр әйтерлек идем, тик берсендә дә әндәшмәдем, теге чакта биргән бер телинкә ашын оныта алмадым, — дип сөйләдә күпне күргән ветеран. Карасана, бик теләсәң, авыр сүзне әйтми калырга да була, димәк. Әйе, читен, ләкин кемнәндер кулыннан килә әнә. Тәрбияле булу, зурлык дигәнебез кайвакыт әнә шулай дәшми, дәрләп кабынмый калудыр, бәлки. «Ахмак әйтер — сүз бирмәдем, дип, акыллы әйтер — юл куйдым, дип». Син яман сүз әйтәсе кешенең яхшы гамәлләре дә бар ич, ник аларны искә төшермибез?

Татар милләтенең теленә әшәке сүзләр урыслардан күчеп керде, дип уйлаучылар бар. Икенчеләр, киресенчә, яман сүгенүне урыс милләтенә татар сугышчылары китереп калдырды, дип расламакчы булалар. Әммә болай гади-

ләштерү урынлы микән? Әл... ңгы сугышка кадәр генә хат... зларыбыз ул яктан шактый ... флы-тыйнак булганнар, исе... ләргә дә якынаймаганнар. Ә ... гыш аларны урыслар белән ... аралаштырып калмады. Йә, ... карыйк, авылның чәчәкләре ... сында гына йөрисе (ә чәч... бар иде әле!), өнкәсе назын... нәнәсе (наз да бетмәгән чак ... өлкәннәрдән милли әдәпкә ... нәсе үсмер кызлары нилә... күрмәде ул чорда? Көчсез ж... кәсенә нәрсәләр генә күтәрмәде... Өеннән еракта айлар буена ка... мыйча, салкын баракларда яр... ач яшәп, урман кисү, торф чыга... мәҗбүри ФЗО һәм аны тәмамла... гач шәһәрнең «бөек» төзелешләре... нең иң пычрак, иң каһәрле то... мышы. Авылда калганнары...

МТСның таралган тракторлары... җимерек фермаларның ач малла... ры. Гаҗизлектән бүредәй ул... җибәрерсең. Җитмәсә, бу ми... ләрнең әҗере ни булды... кем кемне җиңде? Рухи изге... әхлакый гарипләнгән тулы бер... ын менә шулай барлыкка ки... Әле сугыштан соң дистә еллар... көч тә колхоз рәисләрә җе... кичке уенга чыккан яшьләрне... өстендә таратып-куып йөр... иде. Иң гади күңел ачудан да... рүм ителгән, түләүсез авыр... бөтен берниге дә хакы бу... кыз баланың ул чакта җаны... сланмыйча ни эшләсен?

Кеше күңеленең бик таб... җавап реакциясе бу. Тик ме... чактагы рухи имгәнүләрне шу... бәпләр белән аклап кыла... идек тә, фаҗигале мирас... озын гомерле булып чыкты... ки ананың рухи зәгый... аның улларына һәм кыз... күчә, тагын да бозыграк, ... сезрәк булып күчә. Күчтә д... Җитмәсә, хәзерге торм... кыйбласызлыгы, гадел хез... шеләренең властьлар та... нан тагын бер тапкыр, эле... реннән дә шәрәрәк алдану... буынның әхлакый савыгу... дәм итми, гаделсезлекләр... вап булып, шәфкатьсезлек, ... лык, җинаятьчелек үсә. «Ко... төшкән суык сүз йөрәккә... — боз була», — диелә «И... дастанында. Без дә әнә шу... сез сүзләр, буш вәгъдәләр, ... салкын мөнәсәбәтләр йөрәгебе... төшеп, бозга әверелгән бу... де. Чагылышы — балаларда. ... алар кемнәрнә тәрбияләр! ... яңа буын үз элгәреннән гыйб... түгел, өлгә ала бит ...

Бу баткактан бик-бик озак ... гарга туры килер әле. Уйланм... — бигрәк тә.

Камаллар нигезенә хәвеф яный

Казанның Нариман урамында классик драматургыбыз Галиәсгар Камал яшәгән 67 нче йорт мескен хәлендә моңаеп тора Әле бит анда Галиәсгар Камалның улы — язучы һәм драматург Әнәс Камал да яшәгән Кемнәр генә булмаган бу йортта — Габдулла Тукайдан башлап. Галимҗан Ибраһимовка кадәр!

Күптән түгел генә Г.Камал спектакльләр куеп йөргән амбарны сүткәннәр Г Камалның йорты икәү булган Шуның ике катлысын инде җимергәннәр Алар урынына тугыз катлы йорт салып куйганнар. Г.Камал яшәгән йорт-нигезне көннән-көн ныграк кысрыклыйлар, бу йорт яныннан инде үтеп йөрерлек кенә юл калган Шушы өзер йортны инде күптән музей итәргә мөмкин иде югыйсә

— Бу йортны да инде күптән алып ыргытасылар иде, — дип сөйли Г.Камалның шунда яшәүче оныгы Фидакарь әфәнде — Үзегезгә фатир бирәбез, бусын сүтик, диделәр Тик бабамның васыяте бар. бу нигезне ташлама. музей итеп ачсалар, яхшы булыр иде. дип әйтеп калдырды Мондагы тугыз катлы йортны салганда күтәрү краннары белән бөтен төзү әйберләрен безнең йорт өстеннән ташыдылар. кайчан безнең өскә төшәр дә, кайчан безне сытып үтерер, дип көттек. Чыксаң, өйне сүтәләр...

Менә шулай дип сөйли классикның оныгы

Ә бит музейны ачар өчен йорты гына түгел, бөтен җиһазлары, кирәк-яраклары өзер Г.Камалның бераүнең дә кулы тимәгән архивы оныгының кулында, 1914 елда ясалган портретына кадәр стенада эленеп тора, хәтта үлгәч алынган маскасы да исән

Хөрмәтле язучылар, шагыйрьләр, артистлар., галимнәр, театр зыялылары, мәдәният министрлыгы хезмәткәрләре бу хакта сез ничегрәк уйлыйсыз? Матбугатта сезнең дә фикерне ишетәсе килә иде?!

Фәния ӘМИРОВА,
Г.Тукай музееның фәнни хезмәткәре

Сагаялар, күрәсең

Быел көз Русия мөселманнары тормышында күп кенә яңалыклар булды Мәскәүдә бөтендөнья Ислам конгрессы, Русия мөселманнары берлеге корылтае үткәрелде һ.б Бүгенге көндә Русиядә 20 миллион мөселман яши Инкыйлабка кадәрге Думада мөселман фракциясе шактый зур абруйга ия булган. Ләкин бүген, кызганычка, Русия мөселманнарының мәнфәгатен яклардай сәяси көч юк. Буласы сайлаулар алдыннан аларның җитәкчеләренең активлашып китүе православие конфессиясенең югары даирәләрен сагайтты, күрәсең. Һәм менә Мәскәүдә патриарх Алексий II тәкъдиме белән Русиядәге мөфтиләр белән очрашу уздырылды. Очрашу дуслык шартларында үтте, анда мөһим, көнүзәк мәсьәләләр күтәрелде, шул исәптән Кандагарда тоткарланган Татарстан самолеты экипажы, Чечен Ичкериясендә әсир төшеп, Ислам динен кабул иткән солдатлар турында да сүз булды. Дин башлыклары белән РФның Федерация Советында да очрашу оештырылды. Кунакларны Рамазан Абдулатыйпов җылы сәламләде.

Күрәсез, соңгы арада мөфтиләр Мәскәүдә еш кунак була башлады. Хәерлегә генә булсын инде...

Бергә булганда оттырмабыз

Мөхтәрәм җәмәгать,
гәзит укучылар!

Алдан искәртмәдегез, дип, соңыннан безгә үпкәли күрмәгез: 1996 ел өчен көндәлек матбугатка язылу дәвам итә. Белгәнегезчә, республикабызда төрле дәрәҗәдәге дистәләрчә гәзит чыгып килә. Шулар арасында «Мәдәни җомга» башка басмалардан байтак яклары белән аерылып тора. Күләмнәрен, эчтәлекләрен, бәяләрен чагыштырып карагыз да күңелегезгә һәрьяктан хуш килгән гәзиткә тукталыгыз. Әмма оттырмагыз:

«Мәдәни җомга» — татар дөньясында халкыбызның рухи елъязмасы булырлык бердәнбер. гәзит;

«Мәдәни җомга» — һәр. атнаның бишенче көнендә 24 битле булып чыгучы иң саллы басма;

«Мәдәни җомга» — күләменә карата иң арзан гәзит.

Язылу бәясе:

1 елга — 36 мең сум;

6 айга — 18 мең сум.

Бу җәһәттән Казанда яшәүчеләр өчен шундый яңалык турында хәбәр итәбез: хөрмәтле укучыларыбыз, әгәр редакциягә килеп язылсагыз, гәзитнең еллык бәясе нибары 25 мең 392 сумга гына төшә. Бу бәягә почта чыгымнары кертелми, һәм сез гәзитне һәр җомгада редакциягә килеп алачаксыз. Безнең адрес: Казан, Бауман урамы, 19 нчы йорт, 2 нче кат.

Хөрмәтле милләттәшләр, бергә булыйк! «Мәдәни җомга» атналык гәзите сезне һәрьяктан канәгатьләндерер!

Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар 5 6 7 1 2 3 4

Алпарда милли киемнәр тегеләчәк

ылдашларың бай
ын икән. Бу телә-
дәреслеге Әлки
ныдагы Алпар
ының 300 еллык
ей тантанасын
гән вакытта рас-
ы. Алпарлылар-
ылдашы, Каза-
ы «Актай» фир-
җитәкчесе Габ-
әфәнде Зиятди-
әйрәм хөрмәтенә
авылына 5 мил-
сум. күләмендә
ата бүләк белән
чикләнмәде. Иң
гы — ул авылы-
тегү фабрикасы
Милли киемнәр
абрикада тегелә-
е, дигән сорауга,
ас әфәнде кыска
«Тегеләчәк»,
п җавап бирде.

Ырынбур татарларына рәхмәт!

Шушы көннәрдә Казан милли мәдәният үзәгендә са Җәлил истәлегенә Ырынбурда куелачак һәйнең макеты турында фикер алышу булды. Аның оры — Мәскәүдә яшәп иҗат итүче сынчы, безнең ашыбыз Кадим Җәмитов. Фикер алышуда Бөтенья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе дус Таһиров, Татарстан халык депутаты Фәндәс фиуллин һ.б. катнашты. Макетка нигездә уңай бәя релде.

Фикер алышуда катнашкан Ырынбур шәһәр татар тимагый үзәге рәисе Зиннур Шакировка мөрәҗәть итеп, Индус Таһиров:

— Шушындый эш майтарып йөргәне өчен Ырынур татар җәмәгатьчелегенә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты исеменнән рәхмәт әйтез, — диде.

● Сынчы Кадим Җәмитов.

Казан Кремле ничек яңартыла?

Татарстан Президенты М Шәймиев Казан Кремлен реставрацияләү һәм реконструкцияләү мәсьәләләре буенча киңәйтелгән киңәшмә үткәрде

Казан Кремленең бик тә камил ансамбле безнең галимнәрне дә чит ил белгечләрен дә күптәннән кызыксындырып килә Колшәриф мәчетенең тәгаен урынын билгеләү җәһәтеннән зур тикшеренү эшләре үткәрелде Галимнәр архитекторлар шәһәр төзүчеләр шулай ук мөселман һәм православие дине вәкилләре элекке юнкерлар училищесы ишегалдындагы мәйданчыкка өстенлек бирәләр

Татар-мөселман дөньясында

■ **Удмуртиядә яшәүче 40 меңнән артык татар яшьләрен үзенә туплаган «Иман» берлеге оешуга бер ел тулды Берлекнең максаты әдәбият, мәдәният дин һәм спортның милли төрләре буенча мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат бирү туган телдә төрле җыеннар үткәрүдән гыйбарәт.**

■ Казан «Полимерфото» заводы Мәскәү эстрада йолдызларының концертларын магнитофон тасмасына яздырырга зур заказ алды Әлеге предприятие җитештергән аудиокассеталар соңгы вакытта Мәскәүдә аеруча абруйлы чөнки «Полимерфото» белгечләре кассеталарны заманча, үзенчәлекле итеп чыгару өчен пресс-формалар булдырдылар тасманың сыйфаты да күпкә яхшырды

«Полимерфото» хәзер аена ярты миллион аудиокассета җитештерә ә ел ахырына кадәр бу сан миллион данәгә җитәчәк

■ **Мәскәүнең «ВлаДар» нәшрияты Хәрби Фәннәр академиясе президенты, Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире, хәрби һәм тарих фәннәре докторы, профессор Мәхмүт Гәрәевнең «Если завтра война?» дигән китабын чыгарды. Автор китабында хәзерге сәясәткә, сугыш коралларына һәм хәрби техникага үзенчә анализ ясый.**

■ Санкт-Петербургның шәһәр галереясында һәм «Аврора» нәшриятының күргәзмәләр залында татар рәссамы Рәшит Гыйләҗев күргәзмәсе ачылды Петербургта яшәүче әлеге үзенчәлекле рәсем остасының әсәрләре белән киләсе елда казанлылар да таныша алачак

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Русиянең иң яхшы шәһәрләрә мәрларын билгеләүче «Мэр-95» Бөтенрусия конкурсының оештыру комитеты составына кертелгән.

Республика Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачевның Төркиягә визиты Төркия һәм Татарстан дәүләтләренең югары закон чыгару органнары арасында беркетмәгә кул кую белән тәгәлләнде

Мәскәүдә нәшер ителә торган «Человек и труд» журналының 10 нчы саны Татарстанда реформаларның ничек тормышка ашырылуына багышланган.

Татарстанның тәүге тапкыр нәшер ителгән Кызыл китабына республикада аз калган яки югалып баручы 745 җәнлек һәм үсемлек турында мәгълүмат тупланган

Казан авиация берләшмәсе эшчесе фатирыннан ике яшь егет, хуҗаның малаен куркытып, 20 мең сум акча, аудиокассеталар һәм 109 мең сумлык китап(!) урлап чыкканнар.

Татарстан Президенты Указы белән Әлки районы хакимияте башлыгы вазифаларын башкару Әмир Вәгыйз улы Кыямовка йөкләнде

15 ноябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданда «Суверенитет» комитеты, Татар иҗтимагый үзәге, Мәрҗани җәмгыяте республиканың бәйсезлеген яклап митинг үткәрә.

Алабуга шәһәрендә керәшен татарлары фестивале булды

Күренекле драматург Туфан Миңнуллинга «Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Төркиядә җитештерелгән сәгатенә 230 километрга кадәр тизлек белән йөри ала торган Татарстанның юл һәм климат шартларына җайлап эшләнгән беренче милиция автомобиле — «Рено-19» Түбән Камада хезмәт юлын башлап җибәрде

Күренекле тележурналист В.Познер «Без» дип исемләнгән телевизион тапшыру өчен Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев белән әңгәмә уздырды. Аны сез 1 нче каналдан 20 ноябрьдә 20 сәгатьтә карый аласыз.

Ташкентта республиканың бәйнәлмиләл үзәгендә Татарстан Республикасы Конституциясенә багышланган кичә булды

Бөгелмә районы Карабаш эшчеләр бистәсендәге ясалма күл төбендә шартлаткычы алынган авиация бомбасы табылды.

Сәхифәдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды

Фән һәм техника өлкәсендә 1995 елгы Татарстан Республикасы Дәүләт премияләрен бирү турында УКАЗ

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре комиссиясенең тәкъдимнәрен карап карар бирәм

Гуманитар табигать һәм техник фәннәрне үстерүгә шактый зур өлеш керткән принципиаль яңа технологияләр эшләгән һәм керткән өчен фән һәм техника казанышларын киң куллану нигезендә алынган күренекле нәтиҗәләр өчен фән һәм техника өлкәсендә 1995 елгы Татарстан Республикасы Дәүләт премияләрен һәм **«Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты» дигән исем бирергә:**

1. 1993 елда басылган «Татар әдәбияты һәм кончыгыш классикасы (үзара элемтәләр һәм шигърият мәсьәләләре») монографиясе өчен

Миңнегулов Хатип Йосыф улына — филология фәннәре докторы В И Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры

2. «Гәүдәнең нормадан тайпылуларын исәпкә алып түбән очлыклары (аяклары) ортопедия авырулы булган балаларны хирургия юлы белән терләндерүнең яңа системасы» дигән хезмәт өчен

Гаффаров Хәйдәр Зәйнулла улына — Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире Татарстан Фәннәр академиясенең «Торгызу травматологиясе һәм ортопедиясе» фәнни-тикшеренү үзәге диреторы

Әхтәмов Илдар Фуат улына — медицина фәннәре докторы Татарстан Фәннәр академиясенең «Торгызу травматологиясе һәм ортопедиясе» фәнни-тикшеренү үзәгенең гыйльми секретаре

3. «Авыл хуҗалыгы хайваннары, кыйммәтле мехлы җәнлекләр һәм кошларга диагноз кую, дәвалау һәм профилактика ясауда биологик препаратлар һәм методлар эшләү» дигән хезмәт өчен

Равилов Габделхәмит Зариф улына — Татарстан Фәннәр академиясе әгъза-мөхбире. Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү институты директоры, хезмәтнең җитәкчесе.

Гаффаров Харис Зариф улына — ветеринария фәннәре докторы Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү институты лабораториясе мөдире.

Хәмәдиев Ривнур Хаҗи улына — ветеринария фәннәре докторы Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү институтының баш гыйльми хезмәткәре.

Шәфикова Рисалә Әхәт кызына — ветеринария фәннәре докторы Н.Э Бауман исемендәге Казан ветеринария медицинасы дәүләт академиясе профессоры.

Боровик Роман Владимировичка — ветеринария фәннәре докторы. Биопрепаратлар токсикологиясе һәм гигиена регламентациясе фәнни-тикшеренү үзәге директоры (Мәскәү өлкәсе Серпухов шәһәре),

Никитин Иван Николаевичка — ветеринария фәннәре докторы. Н.Э Бауман исемендәге Казан ветеринария медицинасы дәүләт академиясенең кафедра мөдире.

Равилов Рөстәм Хәмит улына — ветеринария фәннәре кандидаты. Н.Э.Бауман исемендәге Казан ветеринария медицинасы дәүләт академиясе ассистенты.

Хөсәенов Фидаил Миңнегали улына — ветеринария фәннәре кандидаты, Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү институтының гыйльми хезмәткәре

4. «Нерв-мускул системасында күзәнәкләр арасындагы үзара бәйләнешнең физиологик нигезләре» дигән хезмәт өчен

Полетаев Герман Ивановичка — медицина фәннәре докторы С.В Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университетының кафедра мөдире,

Выскочил Франтишекка — медицина фәннәре докторы. Чехия Фәннәр академиясенең Физиология институты лабораториясе җитәкчесе.

Волкова Ирина Николаевнага — медицина фәннәре докторы С.В Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университеты профессоры,

Хәмитов Хәниф Сабир улына — медицина фәннәре докторы С.В Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университеты профессоры,

Зефиров Андрей Львовичка — медицина фәннәре докторы С В Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университетының кафедра мөдире,

Никольский Евгений Евгеньевичка — медицина фәннәре докторы. С.В Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университетының кафедра мөдире,

Гыйниятуллин Рәшит Әсхәт улына — медицина фәннәре докторы. С.В.Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университеты профессоры,

Волков Евгений Михайловичка — медицина фәннәре докторы. С.В Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина университеты профессоры.

5. «Татарстан Республикасының төзелеш материаллары минераль-җитештерү комплексы проблемаларын геологик-икътисади өйрәнү һәм аны үстерү перспективаларын нигезләү» дигән хезмәт өчен

Пленкин Александр Павловичка — география фәннәре кандидаты рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институтының төп гыйльми хезмәткәре,

Рәхимов Равил Зөфәр улына — техник фәннәр докторы Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясенең кафедра мөдире,

Садыйков Равил Касыйм улына — география фәннәре кандидаты, рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институты бүлек мөдире, эшнең җи экчесе,

Семенов Владимир Федоровичка — техник фәннәр кандидаты, рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институтының бүлек мөдире,

Сенаторов Павел Петровичка — геология-минералогия фәннәре кандидаты, рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институтының өлкән гыйльми хезмәткәре,

Тихвинский Индрик Николаевичка — геология-минералогия фәннәре докторы, рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институтының сектор мөдире,

Чуприн Николай Семеновичка — география фәннәре кандидаты, рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институтының баш гыйльми хезмәткәре,

Шаманский Иосиф Львовичка — геология-минералогия фәннәре кандидаты, рудасыз файдалы казылмалар геологиясе Үзәк фәнни-тикшеренү институтының баш гыйльми хезмәткәре.

6. «Катлаулы профильле өлешләрне механик эшкәртү юлы белән формалаштыру» дигән хезмәт өчен

Юнысов Фәйзрахман Сәлах улына — техник фәннәр докторы, А.Н.Туполев исемендәге Казан дәүләт техник университеты профессоры.

7. «Фән һәм техника казанышларын производствога киң кертү нигезендә бөртекле культуралардан югары уңыш алу» дигән хезмәт өчен (Арча районы буенча)

Минһаҗев Вәгыйз Васыйл улына — Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Арча районы хакимият башлыгы,

Хөсәенов Рәхимҗан Сабит улына — Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе,

Гарипов Роберт Зариф улына — Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Сельхозхимия» район берләшмәсе рәисе,

Вәлиев Инсур Габделхак улына — Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Ашытбаш» колхозы рәисе,

Сабиров Ринат Сабир улына — Татарстан Республикасының атказанган агрономы, «Известия» колхозы баш агрономы,

Габдрахманов Әлфәт Әфләтүн улына — «Северный» совхозы механизаторы.

Татарстан Республикасы Президенты
М.Ш.ШӘЙМИЕВ.
Казан, Кремль
1995 елның 2 ноябре

Фән һәм техника үсешенә лаеклы өлеш

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт премияләре комиссиясенә 1995 елда 13 хезмәт керде Алар фәнни учреждениеләрнең, предприятиеләр һәм берләшмәләрнең гыйльми һәм фәнни техник советларында җентекләп тикшерелде республика газетләре битләрендә киң яктыртылды. Галимнәр һәм белгечләр һәр эшне рецензияләделәр һәм эксперт ясадылар. Байтак кына очракларда бу эш республикадан читтә дә эшләнде Нәтиҗәдә яшерен тавыш юлы белән җиде эш сайлап алынды 34 галим һәм белгеч фәнни-производство . казанышлары өчен Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты дигән югары исемгә лаек булды Арттырмыйча шуны әйтергә мөмкин бу хезмәтләр Ватаныбыз фәне һәм практикасына гына түгел дөнья фәне һәм практикасына да лаеклы өлеш керттеләр

Дәүләт премиясе лауреаты Х.Й Миңнегуловның «Татар әдәбияты һәм Кончыгыш классикасы (үзара элемтәләр һәм шигърият мәсьәләләре)» дигән монографиясе соңгы елларда республика гуманитар галимнәренең иң яхшы казанышлары рәтендә тора Бу энциклопедия колачы белән эшләнгән төпле, концептуаль хезмәт Анда татар әдәбияты тарихы беренче тапкыр халыкның этник тарихы белән тыгыз элемтәдә бәян ителә Тикшеренүгә комплекслы булу хас ул башка фәннәр белән тыгыз элемтәдә башкарылган

Монография татар халкына аның борынгы бабаларының рухи мирасын кайтару эшенә зур өлеш булып тора

Шушы хезмәттәге нәтиҗәләр һәм нигезләмәләргә таянып урта мәктәп өчен әдәбият дәреслеге чыгарылды Бу хезмәт республиканың рухи алгарышына, үсеп килүче буынны патриотик тәрбияләүгә ярдәм итә

Х З Гаффаров һәм И Ф Әхтәмовның «Гәүдәнең нормадан тайпылуларын исәпкә алып түбән очлыклары (аяклары) ортопедия авырулы булган балаларны хирургия юлы белән терләндерүнең яңа системасы» дигән хезмәте дәүләт премиясенә лаек булды Бу проблеманың кискенлеге һәм әһәмияте шунда ки. халыкның социаль хәле һәм экологик мохитның начараюы яңа туган һәм өлкәнрәк яшьтәге балаларның авыруларын арттырды Шуңа күрә балаларны. шул исәптән тумыштан килгән һәм тормышта килеп туган терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын дәвалау бик әһәмиятле дәүләткүләм бурычка әверелде чонки өлкән яшьтәге кешеләрнең гарипләнгән кисәтү дә шуңа бәйле

Тикшеренү нәтиҗәләре дәвалауның югары нәтиҗәле физиологик яңа ысуллары терәк-хәрәкәт аппараты авырулары белән авыручыларны дәвалауда бөтенләй яңа юнәлешне үстерү мөмкинлеге бирде Бу — республика балаларына ярдәм күрсәтүне шактый яхшыртты тумыштан килгән һәм тормышта килеп чыккан авырулардан инвалидлылыкны кисәтүгә булыша

Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү институты һәм Казан ветеринария медицинасы дәүләт академиясе галимнәренең «Авыл хуҗалыгы хайваннары кыйммәтле мехлы җәнлекләр һәм кошларга диагноз кую дәвалау һәм профилактика ясауда биологик препаратлар һәм методлар эшләү» дигән күмәк хезмәте ветеринария фәне өлкәсендә Казан фәнни мәктәбенең данын лаеклы аклый Бу хезмәтләрнең авторлары Г З Равилов, Х З Гаффаров, Р Х Хәмәдиев Р Ә Шәфикова, Р В Боровик, И Н Никитин. Р Х Равилов, Ф М Хөсәенов байтак мәсьәләләр буенча уйлап табу дәрәҗәсендәге тикшеренүләре һәм йөздән артык фәнни мәкаләләре ике монография белән хламидиоз проблемасын эшләүгә зур өлеш керттеләр Аларның нәтиҗәләрен тормышка ашыру үле тууларны, бозаулар һәм дуңгыз балаларының үлүен, мәҗбүри суюны киметү исәбенә югары икътисади файда бирә

Казан дәүләт медицина университеты галимнәреннән Г И.Полетаев, И.Н Волкова. Х.С.Хәмитов, А.Л.Зефиров, Е.Е.Никольский, Р.Ә Гыйниятуллин Е.М Волков һәм Чехия Фәннәр академиясенең Физиология институтыннан Ф Выскочилның «Нерв-мускул системасында күзәнәкләр арасындагы үзара бәйләнешнең физиологик нигезләре» дигән хезмәте фәнгә зур өлеш булып тора Авторларның фундаменталь тикшеренүе күп кенә фармакологик препаратлар һәм токсиннарның йогынты механизмын ачу өчен теоретик нигез булып хезмәт итә ягъни клиник медицина өчен бик әһәмиятле.

А П.Пленкин, Р З Рәхимов, Р К Садыйков. В Ф Семенов, П П Сенаторов, И Н Тихвинский, Н.С Чуприн И.Л Шаманскийның «Татарстан Республикасының төзелеш материаллары минераль-җитештерү комплексы проблемаларын геологик-икътисади өйрәнү һәм аны үстерү перспективаларын нигезләү» дигән хезмәте галимнәр һәм хуҗалыкларның игътибарын җәлеп итми калмас Татарстан Республикасында хуҗалык реформаларын тормышка ашыруда. төзелеш материаллары җитештерүдә барлыкка килгән тискәре тенденцияләрне бетерүдә аның әһәмияте зур Татарстан Республикасында төзелеш материаллары промышленностеның чимал базасын булдыру, аның минераль ресурс потенциалына фаразлы геологик бәя бирү буенча башкарылган геологик-икътисади тикшеренү бездә төзелеш материаллары промышленностен нормаль үстерү мөмкинлекләре барлыгын күрсәтә

А.Н.Туполев исемендәге Казан дәүләт техник университеты профессоры Ф.С.Юнысовның хезмәтләре ике монография һәм 40 уйлап табудан гыйбарәт

Алар БДБ илләрендә дә, ерак чит илләрдә дә киң танылды, Казан, Мәскәү, Самара, Уфа һәм Русия Федерациясенең башка шәһәрләрендәге предприятиеләр. фәнни-тикшеренү институтлары, конструкторлык бюролары тарафыннан технология процессларын технологик җиһазлар эшләүдә файдаланыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреатларыннан В.В.Минһаҗев, Р С.Хөсәенов, Р.З.Гарипов И.Г Вәлиев, Р С.Сабиров, Ә.Ә Габдрахмановның «Фән һәм техника казанышларын производствога киң кертү нигезендә бөртекле культуралардан югары уңыш алу» (Арча районы буенча) дигән хезмәте авыл хуҗалыгын фәнни нигездә алып баруның туфрак түбән уңдырышлы булган шартларда да югары уңыш алырга мөмкинлек бирүен ышандырырлык итеп дәлилли Алдынгы фәнне һәм технологияләрне белеп [illegible] рес файдалану бөртекле культураларның уңышын күп тапкыр арттырырга мөмкинлек бирде 1986-1994 елларда мәсәлән ул гектарга уртача 17,4 центнердан 49,1 центнерга җитте. Ас[illegible] хуҗалыкларда исә 70 центнердан артып китте.

Югары бүләккә лаек булган хезмәтләр турында сөйләгәндә, аларның фән-техника-җитештерү чылбырының безнең зур казанышларыбыз булуына ачык мисал булып торуын басым ясап әйтергә кирәк Дәүләт премияләре [illegible] рү Татарстан мәнфәгатьләрендә [illegible] һәм техника алгарышы, аның сүг[illegible] нитетын ныгыту, тормышыбызның [illegible] лык өлкәләрендә тискәре күренеш[illegible]нә бетерү өчен этәргеч булып хезмәт итәр

Мансур ХӨСӘЕН[ОВ]

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премияләре комиссиясе р[әисе], Татарстан Фәннәр академиясе президенты, академик

Дусларыбыздан үрнәк алып...

Флүн МУСИН,
академик

Каядыр бәйрәмгә барсаң, анда сый-хөрмәт күрсәтү белән бергә, гадәт буенча нин-дер бүләк тә бирәләр. Ан- ый бүләкләр арасында төр- е булырга мөмкин — кыс- гомерлесе дә, мәңгелеккә тәлек булып калырдае да. Быел август аенда казакъ лкының бөек улы Абай Ко- нбаевның 150 еллык юбиле- а баргач бирелгән бүләкләр асында минем өчен аеруча дерлесе һәм кыйммәтлесе бай энциклопедиясе» бул- Әлеге юбилей көннәренә басма табактан артыграк ләмдә, 100000 данәдә, ка- ъ телендә, офсет кәгазьдә играфик яктан югары дә- әдә чыгарылган бу китап ем игътибарны үзенең кү- е яки тиражы белән генә ел, бәлки безнең көннәр н күп яктан уникаль булуы торки халыкларга, шул птән безгә дә үрнәк булып уы белән җәлеп итте.

Классик таләпләргә җавап ерлек итеп эшләнгән бу иклопедия белән танышу- туган беренче гомум тә- р шул: Казакъстанның дә- т һәм фән-мәдәният даирә- ендә әлеге эшнең нинди мияткә ия булуын яхшы аганнар һәм аңа бик җава- караганнар. «Абай энцик- едиясе»н төзү белән тулы фәнни оешма — Казакъ иклопедиясе институты, шка эшләрен куеп торып, сус шөгыльләнгән. Әйтергә әк, 1967 елда оештырыл- бу институт моңа кадәр эн- лопедияләр яки шул хара- рдагы хезмәтләр тудыруда е шактый тәҗрибә тупла- Мисал өчен ул моңарчы томлык «Казакъ совет эн- лопедиясе»н, 4 томлык закъ ССР» энциклопедия- Ч.Вәлиханов әсәрләренең млыгын, берничә тематик иклопедияне һ.б. езерләп арган.

Абай энциклопедиясе»н буенча эш 1989 елда баш- ган. Башта булачак энцик- едиянең сүзлекчәсе эшлә- Аны төзүдә һәм тикшерү- Казакъстан Милли фәннәр демиясенең күпчелек ин- утлары, югары уку йортла- иҗат берлекләре һ.б. кат- кан. Абайны казакълар- рухи юлбашчысы итеп ка- әлегә энциклопедиядә лда бу халыкның бөтен та- ын һәм мирасын, аның ке- ек дөньясы белән борын- ан килә торган күптөрле нәнешләрен чагылдыру сат итеп куелган. Шундый ь киң мәгънәле һәм яңгы- лы фундаменталь хезмәт ы сәбәпле, аны төзүдә дә акъстанның төп фәнни-мә- көчләре, ягъни респуб- дагы күпчелек фәннәр ләре, язучылар, шагый- р, журналистлар, компо- рлар, рәссамнар, музыка, р, сынлы сәнгать белгеч- һ.б. катнашкан. Энцикло- янең төп авторлары кол- ы гына да 160 тан артык дән тора. Казакъстан фә- мәдәнияте, мәгарифе вә- әреннән тыш, бу эшкә та- әлекке СССРның союздаш убликаларыннан һәм кай- чит илләрдән дә галимнәр ылган. Энциклопедия үз 2000 нән артык исем-то- гә бирелгән мәкаләләр- ла. Китапның структурасы нциклопедик характерда. Мохтар Әүэзовның «Ка- халкының олы акыны» программ характердагы мәкаләсе белән ачыла. Шунда ук энциклопедияне төзегән коллективның җитәкчесе Казакъстан Милли фәннәр академиясе әгъза-мөхбире Р.Нургалиевнең бу хезмәтнең ничек эшләнүен, структурасын аңлаткан кереш сүзе бирелгән. Энциклопедиянең төп өлеше — алфавит тәртибендә бирелгән «сөзтизбесе», ягъни сүзлеге 15 тематик юнәлешне колачлый. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) Акын әсәрләре; 2) Абай әсәрләренең персонажлары; 3) Абай һәм әдәбият белеме; 4) Абай һәм тел белеме; 5) Абай һәм Шәрык әдәбияты; 6) Абай һәм Көнбатыш әдәбияты; 7) Абай һәм урыс әдәбияты; 8) Абай һәм тугандаш халыклар әдәбияты; 9) Абайның дөньяга карашлары; 10) Абай һәм сәнгать, 11) Абай үскән мохит; 12) Абай әсәрләрендәге географик атамалар; 13) Абай әсәрләренең басмалары; 14) Басма сүз һәм Абайны өйрәнүчеләр; 15) Абай бүләге лауреатлары. Моннан тыш кушымталар рәвешендә а) Абайның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан төп фәнни хезмәтләр библиографиясе; б) Абай файдаланган башка телләр сүзлеге; в) Абай поэзиясендәге рифмалар сүзлеге; г) Абай теленең ешлыклы сүзлеге; д) Исемнәр күрсәткече кебек бик кирәкле һәм мөһим бүлекләр дә бирелгән.

Энциклопедиянең фәнни яктан ничек эшләнешенә мисал яки үрнәк итеп анда шагыйрь иҗатының бирелешен генә аласы килә. Китапта Абайның һәр әсәренә — шигырьме ул яки башка жанрга караган әсәрме — аерым мәкалә тәкъдим ителгән. Ул мәкаләләрдә әсәрнең язылу тарихын, идея-эстетик эчтәлеген, бигрәк тә төрле басмаларда ничек бирелүен ачыклауга басым ясала. Эш шунда: Абай әсәрләренең автор кулъязмалары сакланмаган, алар башкалар тарафыннан күчереп язылган нөсхәләр рәвешендә яшәгәннәр икән. Шунлыктан шагыйрь әсәрләрен төрле басмаларда төрлечә бастыру киң таралган.

Гаять киң колачлы бу китапта мине бигрәк тә Абайга бәйле рәвештә татар халкы турында нинди мәгълүматлар һәм бәяләмәләр бирелүе кызыксындырды. Анда безнең халык, аның әдәбияты, Казан шәһәре, Абай белән турыдан-туры бәйле татарлар, аңа теге яки бу рәвешле мөнәсәбәте булган әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләребез турында мәкаләләр кертелгән. Аларда безнең өчен кызыклы һәм гыйбрәтле мәгълүматлар, фикерләр белән очрашасың. Әйтик, татар халкына багышланган мәкаләдә Абайның бу халык турындагы фикерләре китерелә. Аерым алганда, үзенең «Кара сүз» яки «Гаклия» дигән фәлсәфи-әхлакый рухтагы чәчмә әсәрендә ул татарлар хакында болай язган: «Мулла-мәдрәсәләрен саклап, Ходайга зарланмый гына яшиләр. Хезмәт куеп мал табуның да җаен белә, зат-зиннәт тә юк түгел үзләрендә... Андый халык һич хур булмас, чөнки һаман һөнәр үзләштереп, төрлечә мал табып, бер-берсенә булышып көн күрәләр».

Безнең халыкның килеп чыгышы мәсьәләсенә дә дикъкать итеп, Абай аның кайчандыр монголлардан аерылып чыккан татар дигән халыкка барып тоташуы, шушы халыкның казакълар белән Идел буе татарларының да чишмә башы булуы турында фараз кылган. Энциклопедиядә моңа кадәр безгә бөтенләй диярлек билгесез мәсьәләгә — татарларның Абай белән аның балалары тормышында һәм язмышында уйнаган рольләренә шактый игътибар бирелә. Аерым алганда, Абайның әтисе Кунанбай махсус чакырткан беренче мөгаллиме Габитхан Габденазар улы (1835-1932), икенче мөгаллиме — Семипалатинскидагы татар мәдрәсәсе мөдәррисе Әхмәт Риза, Абайның балаларын укыткан Мәхмүт Габитхан улы (1870-1927), шагыйрьнең иң яраткан килене — улы Әбдерахманның хатыны Мөгърипә (Казакъстандагы исеме Мағыш (1879-1896) һ.б. турында мәкаләләр кертелгән. Габитхан белән ӘхмәтРизаның Абай тормышында мөһим роль уйнаулары сәбәпле, китапта аларга шактый киң дикъкать ителә. Әйтик, бу дөньяда 97 ел яшәп, бөтен гомерен диярлек Абай нәселенә багышлаганы өчен Абайның иң хөрмәт ителгән хатыннары Зере белән Улжан зиратына күмелгән Габитхан 15 урында, яшь Ибраһимны олы дөньяга чыгарган Әхмәт Риза 7 урында телгә алына. Габитханның улы Габидуллага Абайның шул исемдәге шигырен багышлавы күрсәтелә. Абайның балаларын укыткан Мәхмүт мулла турындагы мәкаләдә бу татар зыялысының бер үк вакытта шагыйрь мирасын җыюга һәм саклауга зур гына өлеш кертүе әйтелә. Татар кызы Мөгърипә хакындагы мәкаләдә аның ире Әбдерахманның иртә үлемен күтәрә алмыйча 17 яшендә, иреннән соң бер ел да тормыйча кайгыдан үлүе хәбәр ителә. Үзенең яраткан киленен багышлап, шагыйрь «Әбдерахманның җәмәгате Магышка Абайның әйткән юатуы» дигән шигырен язган. Мөгърипәнең Мәрфуга исемле кызы әле дә исән икән.

Татарлар белән бөтен гомере буена якыннан аралашуы һәм алардан бары яхшылык кына күрүе сәбәпле, Абай бу халыкка бик җылы мөнәсәбәттә булган. Аның бу мөнәсәбәте татар теленә игътибарлы булуында да күренә. Энциклопедиянең «Абай файдаланган башка телләр сүзлеге» дигән бүлегеннән күренгәнчә, шагыйрь үз әсәрләрендә татар сүзләрен шактый күп кулланган икән.

Инде Абайга теге яки бу яктан бәйле татар әдәбияты һәм сәнгате әһелләренә килсәк, китапта бу уңайдан Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Бабич, М.Максуд, Б.Урманче, Х.Госман, З.Нури, М.Хөсәен һәм С.Әдһәмова турында аерым мәкаләләр, Б.Урманченың «Абай портреты» дигән картинасының (1945) репродукциясе бирелгән. Аерым әдипләргә багышланган мәкаләләргә күз салсак, Тукай турындагысында татар шагыйре иҗатына казакълар арасында ул исән чакта ук игътибар бирелүенә, аның шигырьләрен казакъ укучысына җиткерүдә М.Әүэзов, С.Муканов, Т.Нуртазин, Җ.Сыздыков, Т.Әбдерахманов кебек күренекле әдип-шагыйрьләр катнашуына, М.Әүэзовның Абай белән Тукай поэзияләренең рухи якынлыгын ассызымлап күрсәтүенә басым ясала. Г.Ибраһимовның революциягә кадәрге казакъ дөньясын яхшы белеп «Казакъ кызы» романын язуына, Өфедәге «Галия» мәдрәсәсендә укытканда казакъ шәкертләренә ана телләрендә «Садак» дигән кулъязма журнал чыгарырга булышуына, Абай иҗаты белән якыннан таныш булып, аңа югары бәя бирүенә дикъкать ителә. Аерым алганда, аның Абайны «бөтен казакъ сахрасына әдәби азык булып килгән... киң далада авазы яңгыраган» шагыйрь дип бәяләве искә алына. Ш.Бабичның да яшьтән казакъ арасында мөгаллимлек итеп бу халыкның авыз әдәбияты, Абай шигырьләре белән яхшы таныш булуы күрсәтелә һәм аның: «Мин Конанбайның өләнендә фәсахәт, матурлык вә ләззәт табып, аны татарның Тукае, гарәпнең Имрелкайсе дәрәҗәсенә мәңгердем», — дигән сүзләре китерелә. З.Нури, С.Әдһәмова һәм М.Хөсәеннең Татарстанда Абай мирасын, казакъ әдәбиятын пропагандалау буенча эшчәнлекләренә югары бәя бирелә. Казанга багышланган мәкаләдә бу шәһәрнең төрки халыкларны Абай белән таныштыруда башлап йөрүе һәм күп көч куюы әйтелә. Бу юнәлештә беренче карлыгачлар рәвешендә Казанда басылган «Кенәз белән Загифә» дигән кыйсса китабында (1897) һәм М. Кәшимовның «Сылу кыз» исемле шигырьләр җыентыгында (1909) Абай шигырьләре дә бирелүе карала.

Гомумән алганда, бу энциклопедия Абай шәхесе һәм эшчәнлегә аша казакъ халкын, аның тарихын, телен кешелек дөньясына танытучы китапка милләтнең үзенчәлекле визит карточкасына әверелгән. Аны хәтта чын мәгънәсендә «Казакъ милли энциклопедиясе» дип тә атарга мөмкин. Мондый күркәм сыйфатлары һәм казанышлары белән ул инде әйтелгәнчә безгә дә үрнәк булып тора ала. Татар халкының безне милли яктан милләт буларак тагын да паеклырак төстә киң дөньяга күрсәтерлек һәм танытырлык энциклопедик яңгырашлы шәхесләре бар.

Бу мәсьәлә белән махсус шөгыльләнгән Татар «Мирас» фонды фикеренчә бүгенге көндә татар дөньясында «Абай энциклопедиясе» тибындагы басмага өч гали шәхес — Риза Фәхретдинов, Гаяз Исхакый һәм Габдулла Тукай беренче чиратта дәгъва итә ала. Мондый сайланыш әлеге шәхесләр эшчәнлегенең күләме мәгънәсе һәм иҗтимагый-тарихи яңгырашы белән бәйләнгән. Дөрестән дә, бу олуг затлар халкыбыз тарихында, аның иҗтимагый-рухи үсешендә аеруча зур роль уйныйлар. Бу эшнең дәүләткүләм әһәмиятле булуын күздә тотып һәм казакъ дусларыбыздан үрнәк алып, Татар «Мирас» фонды советы Фәхретдинов, Исхакый һәм Тукай энциклопедияләрен әзерләү мәсьәләләре буенча республика җитәкчелегенә мөрәҗәгать итәргә карар кылды. Эшне Тукайдан башлау мәгъкуль күренә. Чөнки Тукай Фәхретдинов белән Исхакыйга караганда күбрәк өйрәнелгән, шунлыктан энциклопедия төзү өчен бу өлкәдә инде күпмедер фактик җирлек тә бар. Әйтергә кирәк, бу юнәлештә әзерлек эшләре дә алып барыла башлады. Мисал өчен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтындагы кулъязмалар һәм текстология бүлегенең 1995-2000 елларны эченә алган планнарында «Тукайның энциклопедик сүзлеге»н төзү дә каралган. Әмма ул әле «Абай энциклопедиясе» тибындагы басмага дәгъва итә алмый, бәлки андый басманың билгеле бер өлеше генә була ала. Мәсьәләгә казакъ дусларыбызча, булган-булган берәгәйле булсын дип карап, без хәзердән «Тукай энциклопедиясе» өстендә эш башлауны һәм аны бөек шагыйрьнең 115 еллыгына бастырып чыгарырга планлаштыруны тәкъдим итәбез. «Абай энциклопедиясе» дә нәкъ менә шул вакыт аралыгында, ягъни 6 ел эчендә төзелеп нәшир ителгән. Моның өчен әлеге мәсьәлә буенча хөкүмәтнең махсус карарын кичектермәстән булдырырга һәм шул документта Тукай энциклопедиясен төзүне бер фәнни оешмага йөкләргә кирәк дип саныйбыз. Мондый вазифаны, әйтик, Татар энциклопедиясе институтына яки Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырырга мөмкин. Әлбәттә, бик катлаулы һәм күләмле бу эшне башкару өчен бөтен шартларны тудырырга кирәк. Казакъстандагы кебек эшкә бердәм теләк һәм гомум көч белән тотынганда, иманыбыз камил, без дә «татарлар чынлыкта менә нинди икән алар» дип әйттерерлек һәм милли горурлыгыбызга әверелерлек милли энциклопедия тудыра алыр идек.

КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАП

Искәндәр ГАЛИМОВ,
Татарстан Республикасы эчке эшләр министры:

Мин тормышның китапча гына булмавына төшендем

— Искәндәр әфәнде, иң элек Сезне милиция генерал-лейтенанты дәрәҗәсе алуыгыз белән котларга рөхсәт итегез...

— Рәхмәт. Ләкин бу очракта мин моны министрның гына хезмәтенә бәя буларак кабул итмәс идем. Монда бөтен эчке эшләр органнарындагы хезмәткәрләрнең өлеше бар дип саныйм. Соңгы вакытта республикабызда җинаятьчелек шактый кимеде, булганнарын ачу, җәмәгать тәртибен саклау юнәлешендә дә алга китеш бар. Әйтик, быелның ун аенда, узган елның шул чоры белән чагыштырганда, җинаять кылу очраклары 1,5 меңгә, ягъни 3 процентка, кеше үтерүләр — 4, көчләүләр — 22, квартираларга ясалган һөҗүмнәр — 52, фатир басулар 11 процентка, хуҗаларны куркыту юлы белән фатирларны талап чыгулар 315 очракка, ягъни 67 процентка, кешеләрне талаулар 10 процентка кимеде. Республикабызда җинаятьчелек мәсьәләсендә хәл аеруча киеренке иде. Соңгы ике елда без аны уңай якка үзгәртергә ирештек.

— Русия белән чагыштырганда, республикабыздагы криминаль хәлне ничек бәяләргә мөмкин?

— Русиядә җинаятьчелек үсә бара һәм аларны ачу бездәгегә караганда 10 процентка түбән. Бездә кылынган җинаятьләр күләме соңгы вакытта 25 процентка кимеде. Ә эшчәнлегебезнең төп күрсәткече саналган җинаятьләрне ачуда узган елгы эш йомгаклары буенча без Русиядә икенче урынны алдык.

— Җинаятьчелеккә каршы көрәшәм дип һәр фатир саен каравылчы, һәр кешегә тән сакчысы куеп та булмый бит әле. Көтелмәгәндә ясала торган һөҗүмнән саклану чарасын беренче чиратта кеше үзе күрергә тиештер.

— Сүз дә юк, кешеләрнең үзләреннән күп нәрсә тора. Өйдә балаларны ялгыз гына калдырмаска, калган очракта да, чит кеше ишек шакыганда үз-үзләрен ничек тотарга кирәклеге хакында беренче нәүбәттә ата-ана аңлатырга тиеш. Ялгызың кая булса да барганда яки кайтканда, аеруча аулак җирләрдә, кешедән икеләтә-өчләтә сизгерлек сорала. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, нәкъ шундый урыннарда шаһитларсыз җинаять эшләнә. Ә аны ачу, аңлашылганча, бик тә кыен һәм ул озакка сузылырга мөмкин. Кылынган яки кылынырга мөмкин булган җинаять хакында да кешеләрнең үз вакытында эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә хәбәр итүе мөһим. Узган ел җинаятьләрнең 56 проценты ачылган булса, быелның узган чорында бу күрсәткеч 75,4 процентка җитте. Әлеге саннар артында хезмәткәрләребезнең фидакарь эшчәнлеге белән беррәттән, аерым кешеләрнең, шаһитларның да өлеше ята. Әлбәттә, җинаятьчеләрдән саклану чаралары күп төрле һәм җәмәгать тәртибе сагында торучылар бу уңайдан халыкка үзләренең тәкъдим-киңәшләрен җиткереп торалар.

— Сезнең эшчәнлеккә «Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча гадәттән тыш чаралар»ның да йогынтысы булмый калмагандыр дип уйларга кирәктер?

— Ихтимал, сез бу очракта шул исемдәге законны күздә тотасыздыр. Аның бер пунктында: хокук саклау органнары җитәкчеләрен Президент эшкә билгели һәм аннан кире алдыра ала, диелгән. Минем биредә эшкә билгеләнүем дә шуның белән бәйле. Аңарчы мин Казан шәһәре эчке эшләр идарәсе башлыгы идем. Бу законга килгәндә, ул безнең эшчәнлектә зур роль уйный. Шуның нигезендә җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча дәүләт программасы эшләнде. Эчке эшләр органнары өстәмә кадрлар, оператив техника, транспорт белән ныгытылды, ягъни җинаятьчелеккә каршы көрәштә нык-лы база булдырылды.

— Кешеләрнең иминлеге сагында тору җиңел хезмәт түгел. Кайберәүләр бу хакта китаплардан гына укып белә, икенчеләре исә чынбарлыктан чыгып фикер йөртә. Әйтик, укучыларыбызны республикабыздагы иң яшь генералның кем булуы да кызыксындыра. Искәндәр әфәнде, җинаятьчелек хакында сөйләшүдән өз генә читкә тайпылып, газет укучыларыбызның кайбер сорауларына да җавап бирә алмассызмы икән?

— Бик рәхәтләнеп җавап бирә алам.

— Әйтик, берәү болай ди: «Мин детектив китаплар укырга яратам, үзем дә детектив булып китмәсәм ярый инде. Беләсе килә: безнең эчке эшләр министры Галимов яшь чакта нинди китаплар укырга яратты икән?»

— Әлбәттә, бала чакта безнең һәркайсыбыз китаплар укырга, кинофильмнар карарга ярата. Мин дә шундый идем. Кулга нинди килеп эләксә, шуларын укыдым. Ә хәзер уйланам. Китапларда язылган һәм тормыштагы хәлләр арасында аерма зур икән. Әсәрләрдә бар да җиңел, шома гына бара, ахыры да әйбәт кенә бетә. Үземнең эштән чыгып фикер йөртсәм, бер җинаятьне ачу өчен генә дә кайчагында айлар уза иде. Никадәр кешеләр белән очрашып сөйләшәсең, аларның фикерләрен кәгазьгә төшереп, калын-калын папкаларны тутырасың. Әнә шундый зур эш башкарып та, җинаять ачылмыйча калырга мөмкин. Чынбарлык китап кына түгел шул, дип әйтергә генә кала.

— Һәр кешенең диярлек хоббие, ягъни нинди дә булса шөгыле була. Әйтик, берәүләр китаплар, икенчеләре борынгы акчалар җыярга ярата. Ә министр нәрсә белән мәшгуль икән?

— Мин китаплар да, акчалар да җыймыйм. Минем хоббием — спорт. Футбол, көрәш белән кечкенәдән шөгыльләндем. Самбо буенча спорт мастеры, чаңгыда йөгерү буенча спорт мастерлыгына кандидат нормаларын үтәдем. Ә иң яраткан уеным, әлбәттә, футбол. Спорт миңа яшәү көче өсти. Хәтта миннән күреп хезмәттәшләрем дә спорт белән чын-чынлап мавыга башладылар.

— Сәнгать кешене начар гадәтләрдән, кыек юлга басудан коткара, диләр. Сез мондый фикер белән килешәсезме?

— Әлбәттә, сәнгать кешене рухландыра, җанын чистарта дияр идем. Концерт-спектакльләрдә мин үзем дә ял итеп, үземә күрә бер рухи азык алып кайтам. Андый тамашалар эштән өз генә булса да бүленеп торырга ярдәм итә. Кешенең табигате шундый: ул гел эш турында гына уйлап яши алмый, күрәсең.

— Музыка тыңлыйм дип кайберәүләр магнитофоннарын, телевизорларын бөтен көчкә ачып куя. Хәтта аны көннәр буена, караңгы төнгә кадәр акыртырга мөмкин. Андыйларны культуралы ял итүчеләр буларак кабул итәргәме? Еш кына кешеләрне мондый «үзенчәлекле тыңлаучыларга» карата нинди чаралар күрергә икән дигән сорау борчый...

— Кызганыч, андый кешеләр, аеруча яшьләр арасында очрап тора шул. 15-17 яшьлек кешегә шау-шулы музыка ошарга мөмкин. Андый чакта ул тирә-юньдәгеләрнең, әби-бабаларның, авыру кешеләрнең барлыгын да оныта. Олыгая барган саен ул үзе дә андый музыкалардан бизә бара дип уйлыйм. Дөрес, без үскән чакта башкачарак ял итә идек. Мәктәпнең спорт залына җыелып кичәләр, биюләр үткәрә, аннан ял итеп, күңел ачып кайта идек.

Ә инде көннәр буена музыка акыртучыга килсәк, андый кешегә иң элек кисәтү ясарга кирәктер. Инде ул да тәэсир итмәсә, аны административ җаваплылыкка, штрафка тартырга да мөмкин.

— Культура чараларында еш кына без тәртип сагында торучыларны күрәбез. Культуралы ял итәргә килүчеләрне шулай саклау кирәкмени соң?

— Әйе. Безнең тәртип сагында торучыларыбыз төрле тамашаларда, спорт ярышларында еш булалар. Кызганыч, әлегә аларны профессиональ бурычларын бик югары дәрәҗәдә үтиләр дип әйтә алмыйм. Ә бит аның максаты, тамашачылар һәм чыгыш ясаучылар мәнфәгатен искә алып, андый чараларда көтелмәгән хәлләрне булдырмый калу. Тамашачылар әлеге урыннардан ял итеп, күтәренке, тыныч күңел белән кайтып китсеннәр иде, әлбәттә.

— Җәмгыятебездә үзгәртеп кору башланган елларда байтак кына видеосалоннар ачылган иде. Андагы фильмнар үтерү, көчләүне пропагандалады, яшьләргә порнофильмнар күрсәтелде. Хәзер инде андый фильмнарны кинотеатрларда, хәтта өйләрдә дә карарга була. Моның тәрбия эшенә шактый тискәре йогынты ясавы ихтимал ич...

— Әйе, андый чор булып алды. Видеомагнитофоннар киң тарала барган саен мондый эчтәлектәге фильмнар да, кызганыч, арта бара. Икътисади кризис чорында әхлак нормалары да икенче планга күчте шул. Безне дә бу нык борчый. Әлеге фильмнар яшьләргә, аеруча тиешле тәрбия алмаганнарга тискәре йогынты ясарга мөмкин. Кинофильмнардан карап төрле җинаятьләр эшләүчеләр д... юк дип әйтә алмыйм.

— Ә андый фильмнарны читтән кертүне ту... тотырга мөмкинме соң?

— Мөмкин, әлбәттә. Телевидениедән күрсәтел... торган фильмнарны да контрольгә алырга бул... Белгәнебезчә, соңгы елларда анда да шундый э... тәлектәге фильмнар еш күрсәтелә башлады. Ләкин, икенче яктан караганда, мондый фильмнарга игътибар, аны тыйган саен арта гына төшәчәк. Ул яшерен юл белән видеофильмнар сатуга һәм күр... сәтүгә китерер иде. Үз чиратында, андый кешеләр... не җаваплылыкка тарта башласак, төрмәләрд... урын да җитмәс. Димәк, мондый юл белән ге... әлеге фильмнарга булган кызыксынуны бетерә а... маячакбыз. Күрәсең, бу «авыру» белән авыры... алырга гына кала. Күпмедер вакыттан соң үзең ... шул «боевик»ка, «порнофильм»га булган кызыксы... ну кими һәм бөтенләй диярлек бетүен тоясың. Соңгы чиктә кеше мондый фильмнарның мәгънәсе... булуын һәм үзенә бернинди дә рухи азык бирмәвен аңлар, аны караудан туяр, дип уйлыйм.

— Сез Казанда туып үскән, шәһәр тәрби... алган кеше. Димәк...

— Тел төбегезне аңладым. Әйе, татар теле ... минем өчен ата-ана, бабаларым теле, мин бе... Тукай, Җәлил, олы композиторларыбыз, җырчы... рыбыз, сынчыларыбыз белән горурланам. Дөре... миңа урысча укырга, эш урынында да күбрәк ур... телендә аралашырга туры килә. Әлбәттә, мин... өчен ике мәдәният тә якын, кадерле, үзенә тарт... тора.

— Буш вакытларыгызда ниләр белән мавы... сыз, Искәндәр әфәнде?

— Буш вакытлар сирәк була. Менә бүген дә, ... көне булуга карамастан, эштә утырам. Әз ... вакытым булды исә, көндәлек матбугатка күз ... лам, китап укыйм, спорт белән мавыгам.

— Бакчада да казынасызмы соң?

— Әйе. Борисково бистәсендә үз йортыбыз ... ләп торганда мин байтак эшкә өйрәндем. Шул ... тан киләдер инде, бакчага баргач та, «кара» эш... тартынып торган юк анысы.

— Кайберәүләр үзләренә чәчәк биргәнне ... та, ә Сез?

— Мин дә яратам. Әмма кешегә, әйтик, ту... көннәрендә бер җылы сүз әйтү, килеп кулың ... да җитә. Әгәр ерактарак булса, телефоннан ... тыратып, телеграмма җибәреп котласа да, ке... рәхәт, күңелле булып китә. Бөтен кеше дә шун... дыр инде ул.

— Шушы очрашудан файдаланып, мин Се... профессиональ бәйрәмегез белән дә тәбрик ит... эшегездә уңышлар телим.

— Рәхмәт. Үз чиратымда мин дә эчке эшл... органнарында эшләүче хезмәткәрләрнең барыс... да бәйрәм белән котлыйм. Аларга һәм гаиләлә... нә, хатыннарына түземлелек, сабырлык телим. ... хезмәтне сайлап алганбыз икән, Татарстан Респ... ликасында яшәүче кешеләр тыныч яшәсен ө... без аны намус белән башкарырга, бергә-бергә ... рлыкларны җиңәргә тиешбез.

Әңгәмәне Альберт САБИРОВ үткә...

Кайтып киләм

Бүген генә түгел туган якның
Ашкындырып үзенә тартуы.
Һәрчак шулай — рәхәт басу эчләп
Ат юлыннан җәяү кайтуы.

Җырга сыеп бетмәс уйларымның
Һич чыгармын димә очына.
Чәчләремне сыйпап искән җилдә
Арышларым серкә очыра.

Тургайларның көр күңелле чагы —
Ашыкмыйлар җырдан туктарга.
Сиздермичә генә үзләренә,
Моңнарын, их, ничек отарга!

Аяк тавышымнан таныптырмы,
Бытбылдыклар куя эндәшеп.
Балачагымнан ук аларга мин
Серләремне йөрдем өләшеп.

Кайгы килсә, арыш арасыннан
Аваз салып шупар юаткан
Тавышлары әле дә өүвәлгечә
Ишетелеп тора ерактан.

Булдермәскә тырышам мин аларны,
Җилкенсеннәр, әйдә, җилкенсен.
Шул тавышлар белән изүемә
Балачактан искән җил керсен.

Ыспайлыкны сөйгән егетләргә
Тоелыр бәлки мәзәк кебек тә.
Ат юлыннан чалбар балакларын
Буяп кайтып киләм дегеткә.

Үзебезнең әләм тирбәлә

Карашыңны назлап җилпенсен дә
Куанма да, имеш, кинәнмә.
Ятларныкы түгел, күгебездә
Үзебезнең әләм тирбәлә.

Кыйбла җилләрендә тирбәлә ул,
Аваз салып чорлар түреннән:
— Хәтәр тартышларда без бит инде
Мең кат үлеп, мең кат терелгән.

Азмы тырыштылар халкыбызны
Илсез, денсез, динсез итәргә.
Иманына тугры ватандарлар
Ник баш исен әле читләргә?!

Ник үзенчә гомер кичермәсен
Үз җирендә, үзенең йортында?!
Болай да бит инде ничә гасыр
Исәпләндек коллар чутында.

Каршысында торган киртәләрнең
Бер як читкә атып барысын, —
Бәйсезлеген таләп иткән халкым
Үз кулына ала язмышын.

Олы бәйрәмгә тиң бу көннәрне
Кемнәр генә зарыгып көтмәгән?!
Яңа туып килгән Ай да, гүя,
Карашын тик безгә текәгән.

Галәм бушлыгында япа-ялгыз
Йөзсенмени шулай гомергә...
Яшь әләмнең урта бер җирендә
Телидер ул үзен күрергә.

Дусларым чит иткәндә дә

Әллә бер-бер йомыш белән
Җибәргәнме иманнәр:
Ак каеннар йөгерә-йөгерә
Таудан төшеп киләләр.

Төшеп киләләр каршыма
Парлашып-җитәкләшеп,
— Саумысез, сеңелләрем, — дип,
Узам аларга дәшеп.

Сәламемә җавап булып
Җилфердиме шәлләре...
Килми аерылып китәсем,
Һай, бу сагыну хәлләре!

Яфракларның саф сулышы
Бәрелә йөзләремә.
Алар минем бар моңымны
Җыйганнар үзләренә.

Җыйганнар сабый чагымнын
Шатлыгын-кайгыларын.
Дусларым чит иткәндә дә
Чит итмәс каеннарым.

Уҗым булып шыткан көннәрем

Нәрсәсе бар шушы Минзәләнең,
Нәрсәсе, әй, тарта үзенә?!
Кабат кайтмам, диеп китемен дә
Тора алмыйм әйткән сүземдә.

Аерылуыма өч-дүрт көн дә үтми,
Сагынып та инде өлгерәм.
Сагынмаслыкмыни, ул бит минем
Моңнарга бай туган җир генәм.

Газиз әнкәмнең бит бишек җырын
Шунда ишеткәнмен таңнарда.
Беренче кат шунда үрелгәнмен
Инеш читендәге талларга.

Чирәменә ятып аунаганмын
Кайгыларга тарыган чагымда.

Рәшит ГӘРӘЙ

Камылларның пышылдавы аша
Җир җылысы күчкән җаныма.

... Нәрсәсе бар шушы Минзәләнең,
Нәрсәсе, әй, якын күңелгә?!
Уйларымда сихри урманнарга
Әсир булып йөрим бүген дә.

Үзләренә дәшеп күз кысалар
Аланнарда янган тын утлар.
Хуш ис бөркеп, җилдә тирбәләләр
Күпереп чәчәк аткан шомыртлар.

Гомер юлларымны шушы җирнең
Ап-ак чәчәкләре нурлаган.
Уҗым булып шыткан көннәрем бу,
Аермагыз мине кырлардан.

Аермагыз,.. Телим хисләремне
Тургай моңнарына гөрергә.
Җылы буразналы басуларның
Улы булып калыйм гомергә.

Ромашкалар исән чагында

Нинди генә чәчәкләрне мактап
Җырламадым мин үз гомеремдә!
Бүген менә тагын ромашкалар
Килеп керә язган шигыремә.

Тәмле исләр бөркеп, тып-тын гына
Килеп керә: төшме, өнме бу?
Күктә очып арыгач, җиргә әллә
Фәрештәләр иңгән көнме бу?

Бөтен дөнья тоташ ап-ак чәчәк,
Түй сәгате мәллә җиһанның?!
Күреп сокландым да җирдә әле
Сафлык яшәвенә ышандым.

Ышандым мин якты буласына
Таңнарымның, барыр юлымның.
Болыннарда җилләр юкка гына
Назлыймыни гөлләр толымын?

Барысын-барысын ихлас тойган күңелем
Юккамыни канат кагына?!
... Җырларымда сыкрау ишетелмәс
Ромашкалар исән чагында.

Барысы да шул ук...

Без аунап үскән үзәннәр,
Без йөргән болын.
— Саумы сез, саумы сез, — диеп,
Сузамын кулым.

Алар да, саумы син, диләр,
Рәхәт соң җанга!
Эх, яшьлек үтте, дип, йөрәк,
Янма син, янма.

Шул ук бит, әнә, чәчәкләр,
Уҗымнар шул ук.
Шул ук кошларым сайраша,
Талларга куныл.

Шул ук чишмәләр челтери,
Тавышын тыңла:
Без яшь чактагы кебек үк
Бай алар моңга.

Монда синең дә тибешең
Шул ук бит һаман.
Бу җирдә кайнар эзебез,
Җырыбыз калган.

Җырлы эздә яшьлек сүнми,
Син шуны аңла...
Кылларың өзелгән булса,
Шушында ялга.

Кай тарафка икән...

Яфракларда әфлисуннар төсе,
Көз җитүләр инде шушыдыр.
Каеннарның сагышына тагын
Киек казлар моңы кушылыр.

Йөрәкләрне телеп-телеп алыр
Тын кичләрнең куе әңгере.
Нигә шулай кыска була икән
Ал шәфәкъле җәйнең гомере?!

Чыклы аланнарда тагын менә
Тынып калды чалгы чыңнары.
Җилләр куып килгән болытларның
Кай тарафка икән юллары?!

Ашыгадыр алар яңгырларын
Диңгезләргә илтеп коярга.
Мөмкин булса иде сагышларны
Яңгыр суларында юарга!

Шул болытлар аккан якка карап,
Китеп барыр идем үзем дә.
... И туган җир! Берүк бу юлы син
Ышанмыйча торчы сүземә.

Нишләп китим... Синең көзләреңнән
Бармыни соң әле туйганым?!
Боегып калган тирәк-талларыңа
Барып сарыла хыял-уйларым.

Юатырга теләп, һәркайсына
Кулларымны киләә сузасым:
— Сер сынатмый бергә кичик әле
Бу дөньяның бөтен нужасын.

Җаны юклар гына

Кыр казлары булып беттек инде,
Яз кайтабыз, көзен китәбез.
Нигә һаман шулай бер урында
Яши алмас кеше икән без?!

Күпме кабатладым: «Туган якта
Таңнар ата көлеп-алланып».
Ник соң үзем һаман чит җирләрнең
Кояшына йөрим алданып?

Ерактагы кояш җылы дипме...
Юк, андый сүз килмәс телемә.
Туган якның нәни учагы да
Кояштан ким янмый күңелемдә.

Гомерем ахырынача шул учакны
Алыштырмам һичбер кояшка.
Кояшта да туңам, җаным өгәр
Шул учакның җылысын тоймаса.

Көзләр җитте исә әнкәм сүзен
Искә төшерәм мин гадәттә:
«Кыр казлары үтте баш өстеңнән
Син һавага баккан сәгатьтә.

Кечкенәдән киек каз юлында
Булды, улым, синең күзләрең.
Шуңа, ахры, кыр казлары кебек
Юлда уза язың-көзләрең».

Көз җиткәндәр тагын... Очар кошлар
Юкка гына канат кагынмас.
Кыр казлары каурый койган җирне
Җаны юклар гына сагынмас.

Ялгышларым, гөнаһларым белән

Тумыштан ук, ахры, юләрерәк
Булганмындыр... нихәл итәсең.
Җитмешемне куып барганда да
Балачактан килми китәсем.

Күңелем белән һаман тыкрыкларга
Йөгереп чыгам бәбкә сакларга.
Кызыгып карыйм күрше малайлары
Иярләгән елгыр атларга.

Җиз төймәләр тезгән йөгәннәре
Ымсындырмаса соң ни булган?!
Бер җилдерәп килсәң иде хәзер
Болыннардан, басу юлыннан.

Бер әйләнеп чыксаң иде аннан
Сабан туе барган аланны.
Кочак җәеп, мәйдан уртасында
Көтмәсләр шул соңга калганны.

Әй, балачак, кирәк түгелдер лә,
Бер кая да мине чакырма.
Нишләсәк тә насыйп булмас инде
Сиңа кабат борылып кайтырга.

Гомер дигәннәре ике тапкыр
Бирелмәгән әле кемгә дә.
Нигә әле шулай үпкәләргә
Җилдәй шаулап үткән көннәргә?!

Биләүдән үк иңемә өелә килгән
Бурычлардан чәчләр агарган.
Балачакка кайтып китеп кенә
Арынырмын димә алардан.

Илдән, җирдән алган әҗәтләрем
Барыбер сизелер... яшер-яшермә.
Ялгышларым, гөнаһларым белән
Калыйм әле шушы яшемдә.

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ

Тамашачы

Юныс САФИУЛЛИН



● «Сагыш». Чмукин — Шәүкәт Биктимеров.

Безнең язмыш Г.Камал театры белән бәйле. Татар театрын дөньякүләм танытуда Камал театрының өлеше зур булды, диләр. Бу чыннан да шулай. Әмма, театрның бүгенгесе яисә киләчәге турында сүз алып барганда, көндәлек сорау арты сорау туа. Аларның һәммәсен берләштерергә, бергә тупларга уйласаң — халыклар, дәүләтләр кыйблаларын югалткан, кешелекнең аяк астында җир тетри башлаган бер чорда милли театрга нинди юл сайларга, ягъни, театрыбызны ничек саклап калырга? — дигән олы бер сорау барлыкка килә. Әлбәттә, бу хакта театр үзе генә — бер ялгызы уйланырга тиеш түгел. Театр ул — милләтне иңендә тотып торучы алтын баганаларның берсе. Димәк, театр язмышы хакында уйлану — гомумхалык эше. Шулай да, беренче сүзне, уй-фикерләшүләрне театр башлап җибәрергә тиештер. Чөнки театрга хезмәт итүчеләр үз өйләрендәге җитешсез якларны күбрәк күрә, үсешкә җитди аяк чала башлаган көчләр белән йөзгә-йөз очраша. Әйтәсе сүзне асылда репертуар тирәсенә туплап бирү кирәктер, чөнки театрдагы бар юллар да репертуарга илтә һәм нәкъ менә репертуар театрның нинди хәлдә булуын сөйли. Репертуар төрле чорда төрлечә оеша. Сүз бүгенгебез хакында барганга, бүгенге репертуарга мөрәҗәгать итәбез. Ул 24 әсәрдән тора. Аларның барысы хакында да сөйләп бетереп булмас. Кирәкмидер дә. Ул репертуардагы спектакльләрнең күпчелеге театр сөючеләр тарафыннан бик күп тапкырлар каралды инде...

Сүзне узган сезонда сәхнәгә менгән һәм әлегә киң тамашачы күрергә өлгермәгән спектакльләрдән башларбыз. 89 нчы сезон нәрсәсе белән үзенчәлекле булды? Театрга 91 нче сезонда, ягъни 1996 елның 22 декабрендә, 90 яшь тула. Әле аңа чаклы бер елдан артык вакыт булса да, театрдагы һәр кеше ул олы бәйрәмне дулкынланып көтә.

Әйе, театр тормышын җанландыруда, репертуарын үзгәртүдә әнә шундый факторлар да зур роль уйный. Бәйрәмгә хәзерлек чорында репертуарга кертелә торган әсәрләрне бөтен театр диярлек бергә сайлый.

Былтыргы сезон — 89 нчы сезон — моңа тамашачыларыбыз да игътибар иткәндер, яңа премьераларга аеруча бай булды. Театрның тотрыклырак заманнарда да болай нәтиҗәле эшли алганы юк иде. Театр 70 яшен тутырырга бер ел кала — биш яңа спектакль, 80 еллыгын уздырыр алдыннан дүрт яңа премьера күрсәтсә, 89 нчы сезонда, әйткәнебезчә, 90 яшенә бер ел кала сәхнәгә җиде яңа әсәр күтәрде. Куеласы әсәрләр, карaласы премьералар, бәлкем, Аллаһы кушса, шулай ук күп һәм җитди фикерле булырлар. Алары хакында сөйләшүне соңгарак калдырып, хәзергә, инде сәхнәдә күргән, әмма әле киң тамашачыга барып ирешмәгән яңа премьераларны барлап чыгыйк. Алар арасында даһи испан драматургы Лопе де Веганың иң камил әсәре булган «Биюче», француз драматургиясе классигы Эжен Лабишның «Тол ханымда тукталыш»ы, совет чорында бөтенләй куелмаган, бөек драматургыбыз Гаяз Исхакый язган «Жан Баевич», бүгенгесе көндә театрыбызның төп драматургларыннан булган Туфан Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре», яшьләрдән иң өметлеләрдән саналган Зөлфәт Хәкимнең «Карагы», җиңүнең 50 еллыгына Рәшидә Җиһаншина махсус язган «Улларым» драмасы һәм «Идегәй» трагедиясе. Боларга тагын театрыбызның яшь артистлары башкарган «Акчарлак» спектаклен дә өстәр идем. Чеховның бу әсәрен яшьләребез, халыкара фестивальгә алып барып, югары бәя алуга ирештеләр. Премьералар турында сөйләгәндә сүзне «Идегәй»дән башларга һәм мәкаләбездәге зур гына урынны да аңа багышларга туры килә. Театрның 89 нчы сезонында беренче булып куелганы өчен генә түгел, ә театр бюджетыннан күп дистә миллионнарны һәм — режиссерыннан башлап, иң көчле артистларына чаклы, — йөрәк итләрен ашаучы да ул булды бит. Ике тапкыр рәттән Мәскәү сәхнәсендә мәйдан тотты. Шул Мәскәүдә «Идегәй» спектаклен 2 елдан соң ерак чит илдә (Иерусалим шәһәрендә) узачак халыкара фестивальдә катнашырга чакырдылар. Олы галимнәребез һәм сәнгать осталарыбызның радио-телевидение аша бирелгән чыгышлары, яисә матбугатта чыккан хуплау мәкаләләре күплеге дә сүзне «Идегәй» белән башларга этәрә. Аның тагын шул яклары да бар: безне, килмешәкләр дип, тарихи ватаныбыздан Монголиягә сөрергә йөрүчеләр хәзер дә көчле. «Империя зла» — Рәсәй җитәкчеләре һәм аларның бүгенге дәвамчылары Алтын Урда чорына караган алтын тарихыбызны еллар буена халыклар хәтереннән җуеп ташларга, һич булмаса, каралтып язарга омтылдылар. «Идегәй», шуларга җавап йөзеннән, башта зыялыларыбыз тарафыннан матбугат битләренә кайтарылды, соңрак театр сәхнәсенә үк менде. Икенче ягы — бу спектакльнең трагедия жанрында булуы. Әйтәсе фикеремне барлык укучылар да аңласын өчен, чагыштыру аша бирәм. Мисал итеп филне алыйк. Ул да табигать баласы, башка җанварлар кебек ул да табигать законнарына буйсына. Әмма, башкалардан аермалы буларак, дөньяга ул 15 елга нибары бер бала китерә ала. Елына ике-өч тапкыр балалап торган куян бәхете тими аңа. Театрда трагедиянең дә хәле шулайрак. Сезон саен сәхнәгә күпләп тула торган комедиядән аермалы буларак, чын трагедия тамашачылар өчен сирәк кунакка әверелә. Кыскасы, трагедиянең зур ярдәменнән башка туа һәм яши дә алмавын яхшы белгәнгә, тамашачыларыбызга кат-кат шуны искәртәм: милләтебезнең зыялылары һәм гел комедия генә куясыз дип сүгелә килгән Камал театры кулыннан килгәннең бөтенесен дә эшләде; милләтебезнең яшәешенә кагылышы булган, җан азыгы булырлык трагедия тудырды, инде тамашачылар да карарга иренмәсеннәр иде. (Билет бәяләребез дә концертлардагыча 15 мең сум тормый — 1,5 меңнән алып иң кыйммәте 5 мең). Карасыннар һәм күрсеннәр иде: «Идегәй»дәге бабаларының дөньядагы иң зур көчләр каршында да корсакта шуышып йөрмәгәннәрен. Әйе, гүзәл мәдәниятле, искиткеч бай әдәбиятлы, һөнәрчелекне иң югары ноктасынача үстерә алган, иген иккән безнең ата-бабалар. Алтын Урда осталары теккән ас һәм кеш туннарын дөньяның бар патша һәм корольләре кигән. Меңләгән елкы үстереп ерак мәмләкәтләргә дә саткан, галим-голәмалар белән шыплап тулган йөзләрчә шәһәрләр салган (шушы галимнәр бит инде Коперниктан 150 ел алда Җирнең Кояш тирәли әйләнүен әйтеп биргәннәр). Алтын Урда татарлары безнең асыл бабаларыбыз икәнен тагын бер кат исләренә төшерсәк иде. Һәм иң мөһиме — шушындый дәүләттән колак кагуларының сәбәпләрен дә аңласыннар иде. Трагедия үзенә күпне сыйдыра ул. Әмма без әлегә моның киресе белән очрашабыз. Кызганыч, халык этешеп-төртешеп җыр-биюле тамашаларга агыла. Трагедия барган зал исә яртылаш буш кала. (15 октябрь көнне — сезон ачылган көндә — «Идегәй»не каршылаган тулы зал ул театр бәйрәмебез һәм Хәтер көне белән бәйле буларак кына тулган иде). Әнә шундый чакта, спектакль куйганда, роль өстендә эшләгәндә чын мәгънәсендә тау-таш актарырлык көч салган режиссер һәм артистларыбыз М.Сәлимҗанов, Р.Таҗетдин, Ш.Биктимер, Ә.Шакир, А.Гайнуллина, И.Хәйруллин, И.Әхмәтҗаннар күзеннән читтәрәк йөрергә тырышам. Җавап табып булмый торган сораулары барлыгын белгәнгә бу. Тамашачыга ни кирәк? — ди аларның күңелсез карашлары. Чыннан да, комедия ни белән алдыра соң? Юкса бит, трагедиядә дә халыкка аеруча ошый торган күренешләр артыгы белән табыла. Әйтик, көнчелек икән, ул шундый югарылыкта — андый көнләшүдән дәүләтләр җимерелә. Мәхәббәт икән, инде ул мәхәббәттән бөтен бер ил чәчәккә күмелә. Комедиядәге явызлык, күп булса, бер кешенең яңак төбенә менеп төшәргә дәрт бирә. Ә трагедиядәге явызлык бөтен бер нәселне юк итәргә, хәтта бишектәге сабыйны чабып үтерергә җитә.

Шулай да, бер нәрсә өметләндерә, трагедия барган залда укытучылары белән килгән балалар күп була. Өч сәгать буена зурлар кебек карыйлар да, соңыннан аягүрә басып, артистларны алкышлыйлар. Шулай ук гади тамашачылардан шундый сүзләр ишеткәндә күңел рәхәтләнә: башка инде мин җыр-биюгә генә тагылып чыккан тамашаларны карый алмам, ахры, диләр алар. Карасыннар. Үз-үзеңне бәрьяклылык белән генә чикләп кую яхшыга илтми. Нигә әле күңелне комедия биргән күп төрле шатлыклардан мәхрүм итәргә?! Әнә, «Тол ханымда тукталыш»ны куярга режиссер Кристоф Фетриене Франция башкаласы Париждан чакыртып китердек. Исәп безнең татарларны да французча көлдереп карарга иде. Менә; Фәрит Бикчәнтәев куйган испан «Биюче»се яшь артистларыбыз тарафыннан шундый дәртле итеп башкарыла ки, тамашачы спектакльләрдән яшәреп чыга. Шулай ук Бикчәнтәев куйган «Карак» та югарыга үрмәләгән начальник кисәкләреннән, караклардан да остарак урлашырга өйрәнгән җитәкче караклардан шәп итеп көлдерә икән, нигә көлмәскә... Әгәр Празат Исәнбәт сәхнәләштергән атаклы «Жан Баевич» үзләре теләп манкорт булган татарлардан ачы итеп көлә икән, аңа без дә кушылып көлик! «Гөргөри кияүләре»нә дә җыр-бию генә эзләп килмәсен тамашачы. Татарның телен, җыр-биюләрен һәм үзенең үзгәлекләрен дә күз карасыдай сакларга өйрәнгән кардәшләребездән күп нәрсәгә өйрәнеп була. Әйе, мин дә беләм керәшен балаларын татарга нәфрәт белән тәрбияләп үстереп, һәм шундыйларга таянып татарны изәргә теләүче Ильминскийлар да булганын. Һәм изгәннәр дә... Ә мөселман динен тотучылар арасында булмаганмы андый наданнар?.. Бүгенге кебек катлаулы заманда, халыкларны суештырырга, туган кулы белән туган-

● «Җанкисәккәем». Шүрәле — Рамил Вәзиев, Җәмилә — Элвира Сабриева.

● «Гөргөри кияүләре». Үринә — Илсөя Төхфәтуллина, Гөргөри — Наил Дунаев, Гөргөринең хатыны — Фирдәвес Хәйруллина.

НИ КӨТӘ?

ны суярга коне-төне хыялланып ятучылар. Алай гына да түгел, җиң сызганып шуңа хәзерләнүчеләр ишәеп килгән чорда, безгә — бер үк милләт балаларына — бер-беребезне кадерләп яшәргә кирәк! Күп тармаклы олы милләтебезнең бер генә ботагы да корып-сынып төшмәсен.

Инде 90 нчы сезонда нәрсәләр куеласы хакында уйлашыйк. Театр алган тизлекне киметмәскә тырышыр. Быел да премьералар җитәрлек булыр. Кайберләре инде сезон ачылуга ук уйнала башлар. Андыйларга «Инсаният» фондының «Сагыш» спектакле керә. Режиссеры — Илдар Хәйруллин. Өлкәннәребезнең катлаулы язмышы хакында бәян итүче бу әсәр урысның атаклы драматургы А.Галин тарафыннан язылган. «Ретро» дип аталган бу пьесаны татарчага Хәлим Җәләй тәрҗемә итте. Спектакльдә Ш.Биктимер, Р.Җиһаншина, В.Минкина, Ш.Әсфәндиярова кебек талантлы өлкән артистларыбыз барысы да катнаша. Тамашачы аларны белә, алар лар Бөтен гомерләрен Г.Камал театрының тормышын көйләп, театр һәм ган җан җылысын юмарт өләшеп килгән бу шәхесләргә уйланырлык нәрсәләр күбәебрәк китте шул бу заманда Елдан-ел бөтен өлкәдә дә тотрыклылык кими Театрга яңа пьесалар азрак килә, килгәннәре дә ашык-пошык кына әвәләнгән була Тамашачылар да элеккечә ябырылып йөрми Эш хакын вакытында түләмиләр Бәяләр котырып арта. Бу катлаулы чорның иҗат өчен тагын бер куркыныч ягы бар ул артистларның күңелләрен сүрелдерә, тупасландыра. Баш режиссерыбызның 15 октябрь көнне көндезге репетицияне уздырганнан соң әрнеп сөйләгән сүзләрен искә төшереп утырам «... бүген — Хәтер көне Биш меңнән артык халык мәйданнарга чыгып шәһит киткән бабаларыбызның изге рухларын искә ала. Безнең спектаклебез дә шушы вакыйгага авазлаш Кич без аны халыкка уйныйбыз. Ә артистлар әзерлексез килгәннәр. Башкасын ин-

да тамашачы белән уртак телне тиз таба, шуңа күрә бу хакта сүзне озайтып тормыйбыз. «Балачак» студиясе Назыйм Хикмәтнең «Сукыр патша»сын сәхнәләштерде. Режиссеры — Миләүшә Закирова. Спектакльне ул үзенең остазы Бикчәнтәев карамагында иҗат итте. Анда гел яшьләр генә. Балалар өчен куела башлаган икенче спектаклебез «Шәрә бүре» дип атала. Аның авторы — Хәлим Җәләй. Ул бу әкият-пьесасын татар халык әкиятләренә таянып язды. Спектакльнең режиссеры — Раушан Шәриф. Спектакльгә музыканы композитор Азат Хөсәенов иҗат итте. Бу спектакльдә төп рольләрне уйнаучы И.Әхмәтҗан, Р.Шамкаев кебек тәҗрибәле артистлар янәшәсендә театрыбызның яшь артистлары һәм мәдәният академиясе студентлары да уйнаячак. Тамашачыларга тагын шуны да әйтергә була: театрыбызда бүген 63 артист эшли. Әгәр спектакльләребезгә даими катнаша килгән студентларны да остәсәк, бу сан күпкә арта. Яшүсмер һәм яшь тамашачыларыбыз өчен театр Т.Миңнуллинның «Җанкисәккәем» дигән музыкаль комедиясен әзерләде. «Җанкисәккәем»-не сәхнәгә Ф.Бикчәнтәев күтәрде. Спектакльгә музыканы Азат Хөсәенов язды. Чиратта немец халкының даһи драматургы Шиллерның «Юлбасарлар»ы. Аны танылган шагыйребез Зөлфәт тәрҗемә итте. Әсәрне режиссер Валентин Ярюхин куя. Тамашачылар мәхәббәтен яулаган башкорт драматургы Ф.Бүләковның «Бибинур»ы да сәхнәләштереләчәк. Аны Башкорт академия театрының баш режиссеры Р.Исрафилов килеп куяр дип көтәбез. Бикчәнтәев исә, шулай ук, Нәкый ага Исәнбәтнең «Гөлҗамал»ын да сәхнәләштерергә җыена. М.Сәлимҗанов һәм П.Исәнбәтләр шулай ук җитди уйлана-

дә әйткән дә юк, сүзләрен белмиләр. Кәрим Тинчурин белән Салих Сәйдәш — милләтебезнең ике талантлы улы иҗат иткән «Зәңгәр шәл» репертуарыбыздан ни өчен шулай иртә төшеп калды? Артистлар аркасында! Чак-чак — тегендә шапшаклык китә, чак-чак — монда мизансценада төгәлсезлек, кирәкмәгән җирдә арттырып җибәрәләр, кирәк җирдә иң мөһимен җиткерә алмыйлар, бөтенләй юктан кызык эзләп көлешәләр һәм шуларның нәтиҗәсе — спектакльләр бик иртә туза, тарала. Менә бүген дә шуңа барганыбызны күрәм. Тудырган анасы да танымый башлый, дигәндәй, үзем куйган спектакльдән үзем оялып утырдым. Репетициягә әзерлексез, хәтта сүзләрен дә карарга онытып килгән артисттан осталык таләп итү көлке! Артист режиссердан яңа роль көтә. Ә мин менә карыйм — элекке роле спектакльдән спектакльгә үсәме? Образы камилләшәме? Юк, артист хәтта сүзен дә карап килми! Фаҗиганең башы әнә шундый вак-вак нәрсәләрдән башлана да инде. Күзгә күренмәгән ярыктан кергән су зур корабны батыра...»

Репертуарга нык тәэсир итүче шундый ук күңелсез хәлләр драматургия өлкәсендә дә күзәтелә. Дөрес, ул һәр драматург иҗатында да бертөсле бармый. Әйтик, берәүләр театрдан читләшеп чәчмә әсәрләр язуга күчәләр Икенчеләр — иҗатларында ваклана башлый. Ягъни, пьесадан пьесага мәгълүм характерларны күчереп йөртә, моңача инде кат-кат файдаланылган, кулга тота алмаслык хәлгә килгән сюжет-композицияләр белән эш итә Өченче берәүләре театраль алымнарның үз көченә генә ышанып яза. Ягъни, чын өй салмый, вакытлы корама алачык кына төзеп куя. Янәсе, режиссер — алла, телефон кенәгәсен дә сәхнәләштерә ала, нигә интегергә Болар барысы да бүгенгә замана шаукымы һәм түгел дә.. Мәсәлән, драматургны театрдагы рольдән читләштерү — гади ярдәмче итеп кенә калдыру ул инде театр сәнгатендә режиссерларның аллага әверелгән көннәреннән үк килә

● «Идегәй». Идегәй — Ринат Таҗетдинов.

Без алыпсатарлар тормышын коррупциянең кансызлыгын. дәүләтнең төп акчасы белән идарә итүче «капчыклары»ның чын йөзләрен, интеллигенциябезнең ваклануын, бюрократларның оятсызлануын, авыл кешесенең бозыклыкка йөз тотуын, заманыбызның бар чагылышын сәхнәбездә гәүдәләндерергә тиешбез. Ә аның өчен драматургиянең көчле булуы сорала. Бу урында әлеге аталган темаларны күтәргән пьесалар бар диярләр Бар Әмма үзләренең аңлау һәм аңлату көчләре, төп вакыйганы эчтән яктыртып бирә алу сәләтләре җитенкерәми

Боларның нигезен мин әлеге дә баягы театрның фәлсәфи фикерләвен яңарта, яңа күтәрелеш тудыра ала торган драматургның (бу урында театрларның Бернард Шоу Чехов, Булгаков, Т.Уильямс, Камал һәм Исхакыйлы чакларын үрнәк итеп алу кирәк) театрдан читләштерелүен дә, аннары режиссерның гаять зур көчкә ия булуын белеп торган драматургның язылачы әсәрләрен дә, инде режиссура эзләп тапкан театраль алымнарга буйсындырып иҗат итә башлауларында күрәм. Режиссерларның театрда алла булуы, режиссерга тормышын бер яктан шактый җиңеләйтсә дә, икенче яктан уйлый һәм язарга атлыгып торган драматургның иҗатын бутавы белән киләчәктә репертуар кытлыгы булып әйләнеп кайтты Әйе, шул чорда бит инде шәп драматурглар да вакытлы гына, шул чорда гына билгеле бер роль уйный ала торган цирк, концерт балаган алымнары катнашмасыннан торган театр алымнарын үзләренә мәңгелек канун итеп кабул иттеләр һәм иҗат эзләнү фәлсәфи уйлану кебек иҗаттагы төп коралларын үтмәс хәлгә төшерделәр. Газапсыз, ансат кына, хәйләләп кенә туган иҗат соңрак үч ала диләр Алга куелган кечкенә бурычлар эшнең нәтиҗәсен тагын да кечерәйтә Әгәр драматург әфәнде һәр яңа әсәре белән йокысы качарлык, тынычлыгы югалырлык проблемаларны күтәреп чыкмаса, шуларны сәхнә теле белән сөйләү бурычы куймаса — ул инде әйдәп баручыдан ярдәмчегә генә әйләнә

Мәскәүдәге Югары театр курсларыбызда укучылар белән очрашуга бик күп драматурглар чакырыла иде Без яратып биргән сораулар арасында. «Сезне яңа әсәр иҗат итүгә ни этәрә? Төп этәргечне атый алмассызмы?» — дигән «мәкерле» сорау да була иде Розов, Арбузов, Зорин Горин кебек танылган драма осталары һич көтмәгәндә иҗатка ярдәм итүче төп этәргечләрдән берсе итеп акчаны да атыйлар иде Шуннан безнең режиссерлар арасында тавыш куба иде «Ничек инде ул акча төп этәргеч булсын? Ә ватан ә милләт кайда? Драматург гел акчага туя белмәде! Мәңгелек даны гына җитми микәнни?»

Дан казанган драматургларның «Дан дан урынында, даның булу үзең теләгәнчә язу хокукы бирә, һәрхәлдә танылган драматургның пьесасын укып та тормый кайтарып бирмиләр. әмма дан берничек тә акчаны алыштыра алмый», диюләрендә хаклык та бар Әйтик, драматург торгынлык чорында бер пьеса язса, 3 мең сум ала иде Айлык эш хакы уртача 150 сум булганда, бу — 20 айлык эш хакы дигән сүз Аннары драматург спектакльнең уңышына карап берничә ел буена ай саен, кимендә, бер хезмәт хакы алып бара иде Шул арада драматург үзенә яңа пьеса язарлык мая да туплап өлгерә иде Әнә шулай итеп, тормышының очын-очка ялгап бара ала иде Ә хәзер нәрсә инде? Билет бәяләре коточкыч түбән Аңа ничек яшәргә? Үземне мисалга китерә алам Театрдан инде бер ай эш хакы ала-алмавым аркасында бүген — туган көнемдә — оят булса да әйтми булмый (уйлашканда ул да кирәк) кибеткә барып ипи дә алып кайта алмый утырам

Хөкүмәтебезнең драматургларны үз көннәрегезне үзегез күрегез дип ярдәмсез калдыруы да артык иртә булды

Бу мәкалә бүлмәдә ягъни кабинет түшәменә карап утырып кына язылмады Театрның әдәби бүлегендә 14 ел эшләү чорында тормыш аның төрле яклары белән очрашканда туган уйларыма нигезләнеп язылды Мәкаләмне очлап куйганда да, шул алымга тугры калып тагын да үз башымнан узган бер вакыйга белән тәмамлыйм

Репертуарны баета торган яңа әсәр төрле шартларда туа Аны заказ биреп кенә яздырып булмый Әйтик драматургиябезнең йөз аклыгы булган «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы язылуда Академия театрының турыдан-туры катнашы булмады Туфан абый Югары әдәби курсларда чакта язылды ул Үземне бу әсәрнең иң беренче тыңлаучысы идем дип тә әйтә алмыйм әмма икенче булганымны яхшы хәтерлим Чөнки Туфан абый «Тыңла, Юныс, мин бу әсәрне фәлән шагыйрьгә укыган идем — ошатмады» — дип миңа укып чыкты Беренче булып тыңлаучы булмасам да, беренче булып мактаучы үзем икәнен ышандырырлык итеп әйтә алам Кайнарланып «Әлмәндәр миңа бик ошады. Сез үсештә Туфан абый» — дидем (Миңа әсәрне мактау һич авыр булмады Чөнки көнләшә белмим Көнләшә белсәм күптән инде рәтле генә бер драматург булып китәр идем дә театрның күзенә мескен генә карап утырудан котылган булыр идем) Туфан абыйның күңеле күтәрелде портфелемә ысланган колбасалар төяде Хәтерем ялгышмаса, бер айга җитте Тулай торактагы режиссер малайларны сыйлагач та бит әле (бусы инде сүзне ныгытыр өчен өстәлде) Үзен мактый да белмәгән ачык авызга Туфан абый шулай расходланыр идеме? Мәскәү буенча җәяүләп диярлек чыгып киткәч Туфан абый көрсенеп кенә әйтеп куйды «Менә Академия театры минем белән бөтенләй кызыксынмый нәрсә язам ни эшлим — аларга барыбер. күрәсең» — диде Моны бит инде «Азат» «Миләүшәнең туган көне» «Ир-егетләр» «Диләфрүзгә дүрт кияү»не язарга өлгергән автор әйтте Бусы алдагы фикерне куәтләп әйтелә Театр һәр яңа спектакль булып туасы әсәргә алдан ук ярдәм кулы сузып тора алмый Ягъни репертуар төзүдә очраклылык дигән нәрсә дә зур урын тота Әмма «Әлмәндәр» язылган икән — шундый «Әлмәндәр»не дөнья шаулатып куярлык театр булганга язылган! Анысы бәхәссез! Театрның 70 яшенә олы бүләк булган иде ул 90 еллыгына яңа «Әлмәндәр» язылырмы? Язылмас дип әйтергә тел әйләнми Шәт иншалла, язылыр һәм куелыр дип, күп нокталар тезәм

Фоат ГАРИФУЛЛИН фоторәсемнәре.

● «Биюче». Вандолино — Радик Бариев, Фелисьяна — Люция Хәмит.

ХӘТЕР КАЙТАВАЗЫ

Кави ЛАТЫЙП

МӘТӘМ МОҢНАРЫ

Фронтовик, шагыйрь һәм язучы Кави Латыйпның бу яңа әсәре — тәгаен вакыйгаларга, конкрет хәлләргә нигезләнгән автобиографик әсәр. Сугыш елларының, сугыш чоры яшьләренең язмыш юллары турында ул. Әлеге әсәрдән бер өзек тәкъдим итеп, без дә әнә шул ачы яшьлек хатирәсе алдында баш иярга телибез.

Бәхәсләшә, үртәшә, шаяра-көлә авылга кайтып җитүебезне сизми дә калдык. Үзебезнең урамда миңа абыемның яшьлек дусты, фронттан яраланып кайткан, кәрт уйнап «Очко» кушаматы алган Зыя очрады.

— Йә, энекәш годенмы? — диде ул.

— Годен!

— Нинди гаскәргә җибәрергә булдылар?

— НКВДга, — дидем мин эре генә.

— Димәк, син, туган, йә тере Сталинны, йә үле Ленинны саклаячаксың.

— Кем белә?..

— Әйтте диярсең, шулай булачак. Миндә сиземләү хисе көчле. Хатын да шулай ди. Шикләнәсеңме әллә?

— Алдан кычкырганның башы таз...

Зыя көлеп үшен салды:

— Таз, имеш, катынлы була торып, гармунчы Зыя абзаңа күрше авыл кызлары да гашыйк. Чәч нинди куе — бармак түгел, тарак та керми... Солдатка китү көнең билгелеме?

— Юк... Иртәгә таңнан Татар Тимәшенә китәм. Балалар зарыгып көтәдер. Армиягә китәмен дип, күңел ачып йөрисем килми...

Ноябрь уртасына кадәр укыттым мин, аннары армиягә китәргә дип, туган авылдан ат белән килеп алдылар. Бөтен класс, утыз баладан утызы да диярлек, елый-елый Была елгасына кадәр озаттылар. Апакайлары арасында минем сөйгән кызым Гөлендәм дә бар иде: кара кашлы, кара күзле, алсу йөзле, тыйнак-сабыр холыклы, сугыш башлангач, Мәскәүдән күчеп килгән кыз. Ул миңа чигүле кулъяулык бүләк итте, юлга өч йөз сум акча бирде...

Икенче көнне әнием, ике энем, бабай, күршеләр, кыскасы, туган авыл белән саубуллашып, унбер яшьтәш, чаналарга утырып, хәрби комиссариатның җыелу пунктына юл тоттык.

...Ниһаять, команда бирелде: «Частькә алып китүчеләр килгән, эшелон көтә.. Вагоннарга!» Караңгы бина эчендә һавага, суга, икмәккә зарыгып-тилмереп ятучылар өчен сөенеч иде бу!..

Безнең эшелон көнбатышка таба кузгалып киткәч, сулышым иркенәйгәндәй булды. «Озату пункты» дип аталган соры бинада унөч көн, унөч төн иза чиккәннән соң, урысча «телячий», ә татарча «бозау»ныкы дип йөртелгән вагонда «буржуйка» миче янында урын таптым мин үземә... Аста салам булса, баш очында әлеге биштәр: сохари төме борынга керә. Вагон ишегенең баш бармак сыярлык ярыгы бар, ябылып ук бетми. Булачак фронтовикларны кышкы ачы җил бәрәм-бәрәм «кытыклап» карый. Өстемдә — фуфайка, башымда — куян бүрек, аякларда — армиягә китәр алдыннан әнием бастырткан киез итекләр. Туры килсә, киез итекләрне әниемә кире җибәрергә исәп. Язган булса, миңа күн итекләр бирәчәкләр... «Буржуйка» аяк очында гына булганга, киез итекләрне салып, яланаяк килеш, җылыга күрәме, яткач ук йокыга киткәнмен һәм, үзем дә сизмәстән, сул аякның үкчәсен пешергәнмен. «Буржуйка»ны, чиратлашып, дневальный итеп билгеләнгән чакта ягабыз. Вагондагы кырык кешенең һәркайсы «аучы», берәр станциядә эшелон тукталган арада, вагоннан сикереп төшәбез дә, бомбага тотылган вокзалның коймасын каерабыз. Интендант-тәэминатчы урнашкан вагоннан коры паекларны дневальный алып кайта. Ә бүлүчесе, өләшүчесе — взвод командиры ярдәмчесе... Хәер, ярам тәзәлүгә ышанамын, әмма күбрәк бер урында утырамын. Егетләр миңа «мулла» кушаматы тактылар... Алдымда сөлге — бабам ядкаре, саубуллашканда бирде: «Гомер юлың шушы сөлгедәй озын вә пакь булсын иде, йә Хода!» — диде ул. — Син сугыштан әйләнеп кайтканчы үлеп китсәм, тәсем итеп сакларсың». Икмәк валчыклары коелмасын дип, тамак ялгаган чакта, сөлгене аз гына сүтеп, тезләремә куям. Туклангач, пөхтә итеп төрәм дә, аны биштәргә урнаштырам. Ә куен кесәсендә — яраткан кызым бүләк иткән кулъяулыкка: «К + Г» дип, ефәк җеп белән ике хәреф чигелгән. Урыным вагон ишеге каршында.

Көнчыгыштан — көнбатышка, көнбатыштан көнчыгышка киткән эшелоннарны, ишек ярыгыннан күреп кенә түгел, ә санап-барлап барам. Хәер, көндезен аларны мин үз күзләрем белән күрсәм, караңгы төшкәч, тәгәрмәчләре тавышыннан таныйм. Көнчыгышка китүче эшелоннарны бармак белән дә санап булса, көнбатышка юл тотучылары бихисап. Тагын шул: көнбатышка баручы вагоннарның тәгәрмәчләре җәһәтрәк әйләнеп зыңгылдаса, көнчыгышка таба баручы поездларның тизлеге акрынрак булганга, зың колакка тупасрак ишетелә...

...Гомель шәһәренә җиткәч, эшелон Сож елгасы аша ясалган күпердән бик тә акрын вә сак үтте. Күпер вакытлыча, агачтан салынган иде. Искесен шартлатканнар.

Көнбатыш Украина җиренә җиткәч, мин йокыга киткәнмен. Ә таң тишегеннән мине яңгыравыклы тавыш уятты:

— Тиздән соңгы станция! — диде ул.

Күп ара үтмәдек, эшелон туктады. Ике якта да кара урман иде.

— Вагоннан чыкмаска!

— Нәрсә булды икән?

Тынлык күңелгә шом салды...

— Диверсантлар бездән алда баручы эшелонның өч вагонын шартлатканнар, — диде сержант «Таяк-генерал». — Үлүчеләр дә бар икән. Безнең эшелон начальнигына рация аша хәбәр бирелгән. Тимер юл вакытлыча ябык. Рельслар буйлап җәяү атларга туры килер... Взвод, тыңла минем команданы!.. Вагоннан чыгып, сафка басарга!

Биштәрләр аскан егетләр бәреләсугыла сафка тезелде.

Егерме чакрымга якын җәяү атлагач, безнең арттан поезд килеп җитте һәм без, буш вагоннарга утырып, Сарныга таба юл тоттык. Ниһаять, егерме бер тәүлектән соң, безнең эшелон соңгы станциягә — Сарныга килеп җитте. Вагон ишегеннән папахалы бер кешене күреп алдым.

— Бригада командиры полковник Яхимович, — диде безнең «Таяк-генерал». — Үзенең штабы белән мине һәм сез — яшь солдатларны каршы алырга килгән...

Ләкин алай булып чыкмады.

— Эшелон начальнигы майор Денисов, срочно минем янга! — дигән боерык яңгырады.

— Эшелон начальнигы майор Денисов, срочно полковник Яхимович янына! — дип кабатлады икенче берәү.

Майор эшелон буйлап җәһәт кенә атлап килде дә рапорт бирде:

— Иптәш полковник, 1170 нче эшелон тулы составы белән билгеләнгән [illegible]

— Исәнме, майор! — диде комбриг, кул биреп. — Килеп җитүегез белән. Озакладыгыз.

— Егерме бер тәүлек килдек.

— Бәхетле сан... Хәер, хисап — соңыннан.

Без вагоннардан төшеп сафларга тезелдек.

— Кемнең белеме бер класс, бер адым алга!

Белемнәре бер класслылар бер адым алга атлап, сафка бастылар.

— Кемнең белеме ике класс — ике адым алга!

Ике класслылар ике адым алга атлап, сафта үрә каттылар.

— Өч класслылар — өч адым алга!.. Кемнең белеме — дүрт класс — дүрт адым алга!

Өч класслылар вә дүрт класслылар, белемнәренә күрә, аерым сафлар тәшкил иттеләр. Белемнәре биш, алты, җиде, сигез, тугыз класслылар да шул процедураны узды.

— Кемнең белеме ун класс — ун адым алга!

Ун класс белемле бер мин булып чыктым...

... Иртән торып сафка баскач, Головач авызыннан «ЧП» дигәнне ишеттем.

— Чрезвычайное происшествие, — диде сержант кабатлап. — Постта торучы безнең отделение солдаты Хәмидулла Зартдинов, айнзатц дип, дивизия штабында эшләүче бер өлкән сержантны атып үтергән.

— Минем авылдаш Хәмидулла Зартдиновмы?..

— Әйе, ул. «СМЕРШ» киләсен көт тә тор.

— Ни дип килә ул?

— Анысын синең белән миннән сорамыйлар. Командование кирәк, дип тапкан икән, әйдә казынсын.

Икенче көнне таң тишегеннән «СМЕРШ»ның оперуполномоченные казармага килеп тә җитте һәм без — сугышчыларга бер-бер артлы сораулар бирде: «Хәрби вә сәяси яктан үрнәк булган өлкән сержант ничек һәм нинди шартларда атып үтерелгән? Зартдинов атканын үз күзләрегез белән күрүче булмадымы? Атып үтерүче айнзатцлар заданиесен үтәмиме? Казармадан югалып йөрмиме? Советлар властена, даһи Сталинга каршы сөйләмиме? Кулак токымыннан түгелме?..» Сораулар бездән, ә җавап үзенеке: «Рядовой Зартдинов гаепле!» Ул шулай дип әйтә икән, солдатлар да, сержантлар да, офицерлар да аның дәлилләренә каршы дәлилләр куя алмыйлар. Сизгер күңелем белән килешеп үк бетмәсәм дә, авызга су капкандай, мин яши бирәм. Ә менә Хәмидулла кораллар склады янында сакта торганда кешене атып үтергән: ялгышмы, язмышмы?..Хәмидулланы төрмәгә утырттылар микәнни? Ә бит ул өч тапкыр: «Тукта! Кем килә?» — дип кисәтү ясагач кына, кат-кат пропуск белән парольне сорагач кына билгесез кешегә аткан. Үзе шулай ди. Аклану өченме, дөресе шулаймы?..

Йокы ястык сорамый... Бу тәгаен солдат йокысы хакында әйтелгән. Салам белән тутырылган матрацны каз мамыгыннан эшләнгән йомшак түшәктәй хис итәсең.

— Рядовой Зартдинов, сине сержант Головач чакыра! — Дневальный тавышына уянып киттем дә, Хәмидуллага төрттем:

— Уян!

— Кем кычкыра, «СМЕРШ»мы?

— Юк, ул түгел, сержант Головач.

Шактый вакыт узгач, Хәмидулла кире әйләнеп килде.

— Винтовканы пирамидага куйганда затворын ябып калдырганмын, — диде ул. — Головач шуңа чакырткан. Гауптвахтага утыртам, ди.

— Борчылма, авылдаш. Присяга кабул итмәгән солдатны гауптвахтага

утырта алмыйлар.

«Тревога-а-а!» Йокыдан уянып, тиз генә киендем дә, пирамидадан винтовканы алып сафка бастым: «Нәрсә булды икән?»

— ЧП! — диде борчуы йөзенә чыккан Головач. — Рядовой Зартдинов югалган. Дневальный әйтүенчә, ул ишек алдындагы бәдрәфкә чыккач, казармага кире әйләнеп кермәгән. Без аны җир тишегеннән булса да эзләп табарга тиешбез! Исән икән, ул үзе кайтыр. Кем белсен, бәлки кайта да алмас. Үзегез дә беләсез, әле кайчан гына зенитчы кызларда мәтәм булган иде. Мәрхүмә каберенең өстенә яңа кар да яумаган...

Безнең отделение, ике төркемгә бүленеп, хәбәрсез югалган солдатны эзләргә керешә. Бер төркеме үзенең билгеләнгән юнәлеше белән китте, ә без алты гаскәри, әлеге Головач җитәкчелегендә, телеграф баганалары буйлап урманга юл тоттык. Шом салып тимер чыбыклар шаулый, баганалар гүли, алар, әйтерсең лә, Хәмидулланың югалуы турында тревога бирә, тирә-якка хәвефле хәбәр тарата.

«Хәмидулла табылмаса, әнисенә ни дип кенә язармын икән?..» Уйлана-уйлана урманга керүебезне сизми дә калганмын. Һәр агач шикле, кемдер атып җибәрер дә, күкрәкне тотып, җир өстенә егылырсың-аварсың кебек. Шуңар җирдәге чыбык-чабыклар сынмасын дип, фашистлар синең аяк тавышыңны ишетмәсен дип, саклык белән атлыйсың. Ай бер калка да бата, тагын калка да тагын бата.

— Ай чыкты, — диде биш чакрымнан артык ара узып бер генә сүз әйтмәгән Головач.

— Чыкты...

Күрәсең, яктылыкка бер мин генә түгел, ә командир да, коралдашлар да сөенә иде.

— Зартдиновны әйтәм, бәлки, табылыр? — дидем мин.

— Кем белсен? — диде Головач.

— Табылсын гына инде, Зартдинов минем авылдашым да бит.

— Ул үзе качмадымы икән? — диде чуваш Кибек. — Бәлки, Зартдинов дезертирдыр?

— Бер казаннан ашаган иптәшеңә шулай әйтергә ничекләр итеп синең телең бара? — диде Сираҗи Имамов.

Әзли-әзли аяктан егылырга җитеп урманда йөрдек, сазлыкларда фашистларның берничә шалашы да табылды. Күңелләр төшенке иде, беркемнең дә гәпләшәсе килмәде. Безнең белән радист та бар иде, частьтән: «Кайтырга!» — дигән фәрман килде.

Кайтырга чыктык, аякларның тыңлыйсы килми, гүя чандыр гәүдәле Хәмидулла үзенә таба аркан белән арттан тарта иде. «Армия сафларына алынгач, күз алдында тазарып киткән егетне фашистлар бөктеләр микәнни, ә? Ышанасы килми, юк, килми!» Кора-

лдашларымнан алдарак бара идем, күзләремә җир өстендә яткан бернәрсә чалынып китте. «Бүрек түгелме соң бу? Әйе, бүрек!» Теләр-теләмәс кенә бүрекне иелеп алдым. Солдат бүреге, каян, ничек, кем ташлаган? Җентекләп карарга керештем. «Х З » дип, ак җеп белән җөйләнгән ике хәрефне укыгач, «Хәмидулла!» — дип, бер тавышка кычкырып җибәрдем.

— Ни булды? - диде Головач.

— Менә! -- дип мин кызыл йолдызлы бүрекне сержантка тоттырдым.

— Нинди бүрек?

— Күрмисезмени, солдат бүреге.

— Каян килгән?

— Анысын әйтә алмыйм, ә менә бүрекнең эчендә «Х.З.» дип ике баш хәреф җөйләнгән.

— Димәк, рядовой Зартдиновны әлеге айнзатцлар — диверсантлар урлаганнар?! — диде Имамов.

— Качканда бүреген төшереп калдырган булса, нишләрсең? — диде Кибек.

— Рядовой Зартдинов шушы тирәдә булырга тиеш, — диде сержант, бүрекне кулында әйләндергәләп. — Ул йә урманда, йә хуторда. Юк, рядовой Зартдиновны эзләп тапмыйча кайтмыйбыз! — диде Головач һәм кәгазь кисәгенә язып радистка сузды.

— Хәзер үк тапшыр!

«Ике тәүлек тоткарланырга рөхсәт!» — дигән җавап алынды частьтән.

Эңгер-меңгер вакыт иде, урман аша турыдан-туры утарга киттек.

— Хатада җылынып чыккач, эзләүне дәвам итәрбез, — диде Головач.

— Бик яхшы, безнеңчә әйткәндә, добре, — диде авыл советы рәисе. — Нинди йомыш белән килдегез?

Командир аңлатып бирде.

— Сезгә мин озатучы бирә алам, — диде рәис, үз каршысында утырган озын чәчле, сакал-мыек баскан берәүне күрсәтеп. — Фамилиясе Кульбака. Бригаденфюрер СС Беккер башкисәрләреннән качкан, әнә кулында автоматы да бар.

Сөйләшә торгач, Кульбаканың абыйсын айнзатцкоманда командиры обер-лейтенант Модель үз кулы белән атып үтергәнлеге беленде.

— Нәрсә өчен? — диде Головач.

— Боерыгын үтәмәгән өчен... Тонлә белән полицайлар ярдәмендә Модель башкисәрләре кызыл погонлы бер солдатны урлап кайттылар: өстендә шинель, аягында обмоткалы ботинка, яланбаш... Бүреген төшереп калдырган белми дә калдык, диделәр айннар. — Обер-лейтенант солдаттан сорау ала башлады: «Частьтә ничә солдат бар? Кораллар нинди?..» Модель күпме сорау бирсә дә, солдат авызына су капкандай дәшмәде. Инде яхшылык белән телен ачтыра алмагач, Модель хлопецны үтерергә кыйнады, аннары тагын сорау алырга кереште. Ә хлопецның җавабы бер булды: «Белмим!» Модель полицай абыйга солдатны җәзаларга кушты.

— Нинди җәза иде соң?

— Әйтсәм, кеше ышанмаслык җәза! Беләсезме, нинди җәза: солдатның күзләрен сукырайтырга боерды абыйга фашист Модель.

— Димәк, сез качканда теге хлопец исән иде? — диде сержант.

— Әйе, исән иде.

Урман аркылы Дубовка дигән утарга килдек, куе наратлык башланды. Кульбака әйтүенчә, агачларның төбендә бункерлар эзләп табарга мөмкин. Аларда кораллар һәм ашамлыклар, шнапслар-эчемлекләр саклана икән, кораллар аерым, әлбәттә. Ниһаять, Дубовка утары күренде, урман кырыенда гына акшар белән агартылган бер йорт тора, аннан йөз метр чамасы читтәрәк салам түбәле сарай һәм келәт иде.

— Әнә, мине шул келәткә ябтылар да инде, — диде Кульбака.

Без тиз генә келәтне һәм йорт белән сарайны чолгап алдык. Головач кушуы буенча, Кибек һәм Кульбака — хатага, Князев сарайга юнәлде, ә без — сержант, мин һәм тагын ике солдат — карт имән төбендә ятып калдык, минем кулда — винтовка, ә кесәдә — ракетница иде. Котмәгәндә генә кемнеңдер тукылдатканы ишетелде.

«Тук! Тук! Тук! Та! Та! Та!» Нәрсә бу тукран тукылдатамы әллә айннармы? Юк, тукран тукылдатмый пулемет белән автомат очереды бу!

— Айнзатцлар! - дип атылып чыкты Князев сарайдан.

Безнең янга Кибек белән Кульбака йөгереп килдә.

— Хуҗалар хата эчендә ире дә хатыны да, - диде Кульбака.

— Хәзер үк икесен дә чакырып кил — диде командир.

— Ярый

Килгәч, Головач хуҗалардан ничә фашист яшеренгәнен сорады.

— Белмим, - диде ире.

— Ә син беләсеңме? — дип сержант инде хатынынан сорады.

— Белмим

Командир тагын иренә мөрәҗәгать итте:

— Бар, әйт, бирелсәләр, исән калачаклар.

Хуҗа сарайга кереп китте, күп тә үтмәде «Ба-бах-х-х!» мылтыктан аткан тавыш яңгырады.

— Хуҗаны аттылар булса кирәк? — диде Имамов.

Карчык та шулай уйлады, карты янына ашыкты.

— Ярамый, — дидем мин, карчыкка безнең яныбыздан китәргә рөхсәт итмичә.

— Китсен, — диде Головач, миңа ишарә ясап.

— Берәр хәл булса, әби, безгә рәнҗемә

— Рәнҗемим

Карчык, укына-укына, сарай эченә кереп югалды. Тирә-як кабер тынлыгына чумды. Кинәт һава ярып сарайдан аттылар. «Ба-бах-х-х! Ба-бах-х-х!»

— Аталар, әйдәгез җавап бирик! — диде Имамов.

— Сабырлык, — диде Головач, — сарайдан карчык чыксын

— Бәлки, ул чыкмас та? — диде Кибек.

Тагын аткан тавыш ишетелде. «Ба-бах-х-х!»

— Нәрсә көтәбез, әйдәгез, ут ачыйк, — диде сержант. — Акыл белән эш итәргә кирәк. Без монда алты бөртек кенә. Тагын бер кат әйтәм, акыл белән эш итәргә кирәк.

Бу сүз мине дәртләндереп җибәрде һәм, үзем дә сизмәстән, ракетницаны кесәдән алдым.

— Нишләмәкче буласың? — диде Головач.

Мин дәшмәдем, сөйләшәсем түгел, ә хәрәкәт итәсем килде.

— Юк, ярамый, — диде командир. Барыбыз да Кульбакага текәлдек. Кульбака теләр-теләмәс сарайга юнәлде.

— Әйт, исән калырга телиләр икән, бирелсеннәр! — диде сержант

— Гут, — диде Кульбака.

— Немец телендә сөйләшә булса кирәк, — дидем мин.

— Ипилек-тозлык маташтыра,— диде сержант, ул хакта аның белән гәпләшеп алдым.

Шул чакта сарайдан аткан тавышлар ишетелде. «Ба-бах-х-х!»

Айнзатцлар белән безнең арада көчле атыш башланды. Сарай исә дөрләп яна бирде, кинәт көчле шартлау булды. Көчлә ут ялкыны керфекләрне кәйдерде. Фашистлар сарайдан аты лып чыкты. Әмма чыккан берсе бернечә метр узган саен җир өстенә тәгәрәде. безнең утлы һөҗүмнән дөмекте. Сарай ишеге алдында рядовой Зартдиновның гәүдәсен күтәргән берәү күренде. Без тынып калдык. «Кем булыр бу?»

— Атмаска! — дигән команда бирде сержант

— Полицай Остап булам мин

— Модель кайда?

Полицай дәшмәде

— Әйт телеңне йоттыңмы әллә?

— Модельның кайда икәнлеген төгәл әйтә алмыйм. ә сарайда фрицлар бар

Остап безне сарай эченә алып керде

Салам белән капланган бер урынны төртеп күрсәтте полицай

— Менә монда алар нәүрәттә

Минем нәүрәт капкачын ачуым булды автоматтан аттылар. Җиргә тезләндем

— Ни булды? — диде Головач, бәләкәтен тотып

— Нәрсәдер күкрәккә тиеп китте

— Имамов, рядовой Хатыйповны сарайдан алып чык, — диде командир

Сарайдан чыккач, Сираҗи Имамов минем изүне ычкындырып җибәрде.

— Авыртамы?

— Белмим. — дидем мин

Озак вакыт үтмәде, минем янга ике кешене китереп салдылар.

— Кемнәр алар? — дидем мин

— Берсе — Хәмидулла Зартдинов, ә икенчесе Кульбаканың абыйсы, — диде Имамов. — Икесе дә мәет

Мине саклык белән генә арбага күтәреп салдылар янымда Головач белән олаучы иде. Икенче арбада Хәмидулла белән өлкән Кульбака мәетләре һәм исән-аман радист. Олау артыннан әсиргә алынган өч айнзатц, ике полицай һәм конвой белән аларны озата баручы минем яудашлар атлый

Еракта паровоз кычкырткана ишетелде

— Тимер юлга килеп чыктык, — диде сержант, куанып. — Станца моннан ерак микән?

— Ике чакрым чамасы, — диде олаучы.

— Поездны туктатырга кирәк, — диде Головач. — Яралы кешегә минуты да кадерле!

Головач, олаудан сикереп төште дә, поезд килгән якка йөгерде, кулында ракетница иде

— Үткен кеше, — диде олаучы

— Милләттәшең, — дидем мин

— Әйе, хохол сынатмас!

Һавада ракета уты күренде, аның артыннан тагын берсе ялтырады. «Головач ракеталары, поездны туктатырга сигнал бирә!»

— Поезд туктадымы? — дип сорадым мин олаучыдан.

— Юк. Ишетмисеңмени, әнә нинди пышылдап килә, мунча ташына су салган сымак

«Та-та-та!» автомат тавышы ишетелде. Ни булды, монда да айнзатцлармы әллә?

Головач йөгереп килде

— Поездны туктаттым, — диде ул

— — Кайда, күренми ич?

— Урман эчендә автоматтан атып туктаттым — Әйдә атыңны чаптыр! — диде Головач олаучыга. Олаучы ат ны йөгертә башлады

— Туктат! диде сержант

— Ни булды?

— Рядовой Имамовны үзебез белән алырга кирәк диде командир — Ул сине озата барыр

— Әсирләр качмасмы? — дидем мин

— Качсалар бирелмәсләр иде — диде сержант һәм Сираҗи Имамовны чакырып алды

— Утыр арбага

— Тыңлыйм иптәш сержант

— Инде чаптырсаң да була, — диде сержант

Олаучы атны салмак кына юыртты арбада яралы кеше булгангамы җан фәрманга чаптырырга кыюлыгы җитмәде

— Тизрәк! Тизрәк! - диде безне күреп алган машинист расписаниедән чыгам

— Товар поезды икән ә мин пассажирныкы дип уйлаган идем — диде Имамов

— Монысына шөкер итик, туктатмый гына, — диде Головач

— Кайда гелисең, шунда туктатырга ат түгел ул ә паровоз — диде олаучы

— Яралыны кайсы вагонга урнаштырыйк? — диде Головач

— Өченче вагонга, — диде машинист

Күтәреп керделәр дә мине вагон идәненә салдылар

— Йә хуш — диде Головач поезд кузгалышлый вагоннан сикереп — Сине мин Сарны госпиталеннән эзләп табармын

Вагонда Сираҗи Имамов кына калды командир кушуы буенча, мине ул госпитальгә кадәр озатырга тиеш иде Головачтан аерылгач миңа бик тә күңелсез булып китте ул минем командирым гына түгел ә якын кешем дә икән. әлек моны мин ничектер сизмәгәнмен

— Яраң бик сызлыймы? — диде Сираҗи

— Сызлый Сираҗи син карап бар без Сарныны узып китмик

— Узмабыз минем күзләрем үткен. көндез йолдызларны күрә

Тагын күпмедер ара узгач Сираҗи

— Килеп җиттек! — дип кычкырды

Поезд туктагач ул

— Борчылма, мин хәзер әйләнеп киләм — дип вагоннан сикерде

Өч кеше вагонга сикереп менде берсе Сираҗи. ә икенчесе машинист иде ә өченчесен танымадым

— Командирың кайда? — диде машинист

— Ул поезд барганда вагоннан төшеп калды

— Разбойник с большой дороги вот кто твой командир — диде машинист

— Юк, ул — чекист — дидем мин

— Хәер иптәш комендант аларның үз законы — диде офицер — ә мин баш ватам

— Им чекистам как с гуся вода, поэтому и жалобу не хочется писать — диде машинист

— Минем хәлдә үзең булсаң, болай сөйләмәс идең, — дидем мин

— Дөрес әйттең, — диде Имамов

— Менә адвокат та табылды — диде машинист — Хәер ул үзе дә чекист

Носилка күтәргән ике санитар-солдат вагонга менде

— Кем яралы? — диде аларның берсе

— Әнә ул. — диде офицер м... а күрсәтеп

— Иптәш начальник яралыны вагоннан зинһар тизрәк алып чыгыгыз вакыты бик тә кадерле

— Хуш туган. көрәшә алмасак бәхил бул! Кыскасы урыслар әйтмешли йә грудь в крестах, йә голова в кустах Килгәләрмен мин синең яныңа

— Ә менә Хәмидулла килә алмас инде

СӘХНӘ БИЕКЛЕГЕНДӘ КАЛУ

Иҗаты — эш, эше иҗат булды



Мәсгут Имашевның опера һәм балет театрында эшләгән еллары иде Мин театр каршындагы трамвай тукталышында басып торам Минем янда гына ике ханым сөйләшә; ханымның берсе. тавышын бераз сагайта төшеп:

— Әнә. Мәсгут Имашев бара, — дип, театр ягыннан урамны кисеп чыгып баручы бер ир-атка ымлап куйды Икенчесе

— Кем соң ул Мәсгут Имашев? — дигәч, тегесе:

— «Кыр казлары артыннан» дигән спектакльне караганың булса, аны менә шул язган инде. — дип, якынаеп килүчене тагын күзли башлады (Ханым бераз ялгышты. әле генә искә алынган спектакльнең музыка авторы иде ул)

Үз вакытында халык тарафыннан бик тә сөелеп, яратылып каралган, Илдар Юзеев язган бу лирик драма инде болай да кайбер җырлары белән танылып килә башлаган үзешчән музыка язучының исемен популярлаштыруда, һичшиксез, зур роль уйнагандыр. мөгаен

Мәсгут Имашев Пермь өлкәсе, Барда төбәгенең Урал итәкләрендә мәһабәт куе урманнар эчендә камалып, таулы-чокырлы урында җәелеп урнашкан гүзәл табигатьле Каенавылның саф чишмә сулары төмен татып. чын мәгънәсендә авыл тәрбиясендә хисләнеп акылга, зиһенгә, тән тазалыгына ия булып, җитлегеп. музыка дөньясына өметләр баглап, 1958 елда Казанга килә һәм консерваториядә җыр буенча белем ала башлый.

Мәсгут кечкенәдән үк музыкага сәләтле бала булса да, һәрчак җырдан аерылмый яшәсә дә, музыка белеме алырга бик соңара. Ул вакытта инде аңа утыз яшен тутырырга да күп калмаган була.

1964 елны ул, вокал классын уңышлы тәмамлап, опера җырчысы дипломын ала һәм, республика партия җитәкчеләренең мәҗбүрияте «ярдәмендә», Әлмәт каласына яңа музыка училищесы оештыру өчен җибәрелә. шунда директор булып хезмәт итеп, коллектив тарафыннан ихтирам-хөрмәт казанып, озак кына еллар эшли; ә 1976 елны аны Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры директоры итеп билгелиләр.

Мәсгут Имашев эшләгән елларда театр бик зур үзгәрешләр кичерде. Труппаны көр тавышка ия булган яшь опера җырчылары белән ныгытырга вакыт җиткән иде Бу катлаулы эшләрне башкарганда театр җитәкчесенә шактый күп валидол йотарга туры килгәндер, мөгаен.

Мәсгут Имашев 1981 елда Казан театр училищесына директор булып күчте.

Мәсгут Имашевның җырлар яза башлавы аның заводта эшләү елларына туры килә. Аның Нури Арсланов шигыренә язган «Көймәдә» дип аталган җыры бик тиз арада халыкка таралып, популяр җыр булып китә .Бу халык җәүһәрләренә тиң җыр әле дә үз кыйммәтен югалтмаган. Күп кенә җырлар берничә елдан ук «тапталган» җыр исәбенә кереп йөри, ә менә «Сарман»нар. «Арча»лар һаман да шау чәчәктә. Нидә соң хикмәт?! Минем уйлавымча, төп хикмәт — сүз белән көйнең тәңгәлләшүендә, халык көйләре дәрәҗәсенә ирешүендә Профессиональ кимәлне дә шул үлчәүләр билгели инде.

Автор моны беренче җырын язган вакытларында ук яхшы аңлаган, күрәсең. Инде басым ясап шуны әйтәсе килә. Мәсгут Имашев шигырьне һәрвакытта уйлап сайлый белде һәм җыр көйләрен математик төгәллек белән җиренә җиткереп эшләүче иҗатчы булды Ул берсеннән-берсе ягымлы һәм йөрәккә ятышлы җырларын тыңлаучыларга һәрдаим бүләк итә тора. «Саубуллашу вальсы», «Туган ягым каеннары», «Өзелә үзәкләрем», «Туй күлмәге», «Тәрәзәләр язга елмая» һ.б. Болар барысы да халык җырлары дәрәҗәсенә җиткерелеп чарланган, «пешеп» җиткән, дип әйтергә була. Халык көйләре дәрәҗәсенә җиткереп көй язу бик җиңел эш түгел. Композиторлар моны яхшы беләләр. Шуңа күрә, ахрысы, чарланып җитмәгән җырларның гомере дә кыска була. Халык көйләренең яшәүчәнлеге дә, минемчә, күмәкләшеп иҗат ителүе белән бәйләнгән. Халык көен чарлауда һәм аның төрле вариантларын тудыруда Сарман яки Арча халкы гына катнашмый бит, җырның көе, сүзләре башка төбәкләрдә дә чарлана, камилләшә. Җыр иҗат итүчеләр, моңнардан нәтиҗә чыгарып, үзләре өчен мондыйрак гыйбрәт алырга тиешләр: шигырьне, көйне бик озак, ашыкмыйча күп вариантлар аркылы җиренә җиткереп чарлап бетерергә кирәк икән шул.

Мәсгут Имашев кебек, җиренә җиткереп эшли белә торган авторлар күп очракта популярлык казаналар. Ни әйтсәң дә, халык матурлыкны ярата, «профессиональ төгәллек»не дә бик яхшы сиземли.

«Күзлек кигән» кайбер «озын борынлы» профессионалларның, ягъни укымышлы композиторларның, гади матурлыкка, хис байлыгына ия булган, эчкерсез йөрәк җырларының бик популярлашып китүенә эчләре поша. Арада халык өчен язучы иҗатчыларга таяк тыгучылар да табылгалый.

Әзме бездә «Гөлшат Зәйнашева шагыйрьмени?» диючеләр, көнчеләр, дөньяга сыеша алмаучылар? Бу уңайдан Рөстәм Яхинның үзешчән композиторлар турында әйткән фикерләре искә төшә: «Имашевны союзга алырга вакыт җитте дә бит, Мәскәү союзының кагыйдәләреннән тыш, үзебезнең профессионаллар да бит әле каршылык күрсәтәләр», — дип көрсенеп сөйләгән иде ул.

Югыйсә, хәзерге көндә Татарстан Композиторлар берлеге, мөстәкыйльлек алган берлек буларак, әгъзалыкка кабул итү буенча яңа кагыйдәләр дә чыгарган-чыгаруын. Аерым очракта, махсус композиторлык белеме булмаган кайбер авторларны да берлеккә алырга мөмкинлек бар икән. Шулай булса да, бүгенге көнгә чаклы әле бер генә танылган үзешчән автор да союзга әгъза итеп алынмаган. Үзешчәннәргә кырын карамаган Ренат Еникеев та хәтта: «Композитор махсус белемгә ия булырга тиеш», — дип язып чыкты. Бу жанр ирегән кысумы, әллә халык белән санлашмаумы? Һәрбер авторның үз дөньясы, үз жанры булуын онытып җибәрәләр, ахрысы. (Ирексезләп, иҗатчыдан опера яки симфония яздырып булмый бит инде.)

Гомере буе административ эштән башы чыкмаган Мәсгут Имашев үзенең яраткан жанрында эшләвен әле дә дәвам итә.

Кызганыч, аның кайбер уңышлы җырлары әлегә кадәр үзенең башкаручысын таба алмый интегәләр. Аннары гаеп авторның үзендә дә юк түгел, ул — артык тыйнак, нота әләшеп йөрми, сорасалар гына бирә.

Мәсгут Имашев иҗатының беренче баскычы җыр булса, икенчесе — театр өчен көй язу. Ул инде эрерәк формаларда да сыналган иҗатчы булып исәпләнә. Аның «Минем кайнанам» дигән музыкаль комедиясе яңа вариантта зур сәхнәгә чыгу алдында тора. Ул әсәр Казан тамашачыларын бик күп мәртәбә сөендерер әле дигән ышанычта калабыз.

Мәсгут Имашевның иҗаты, халык иҗаты кебек үк, безнең көннәр өчен бик гыйбрәтле иҗат. Заман чире сәнгатьне дә читләтеп узмый. Сүз уңаенда музыка дөньясында еш кына булып тора торган ямьсез күренешләрне дә әйтми калу ярамас.Кайбер үзешчән авторлар, тәнкыйтьнең югалуыннан файдаланып, сәхнәдән сәнгати кыйммәте булмаган мәгънәсез, әйтер идем, тозсыз һәм тәссез җырлар «яңгыры» сибә башладылар. Бәлки, бу демократик хокукларның шартлы булуыннан да киләдер.

Бозылу куркынычы алдында торган музыка сәнгате, бигрәк тә җыр сәнгате, пакьлек, сафлык һәм жанрларда әдәпле булуны таләп итә.

Якын көннәрдә халык җәүһәрләренә тиң җырлар авторы — Мәсгут Имашевның бенефисы булачак. Ул 14 ноябрь көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында үткәрелә. «Һәвәскәр» мәшһүр композиторыбызны шушы гүзәл бинага җыелып котларга, рәхмәтебезне белдерергә мөмкинлек бар!

Марс МАКАРОВ,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

ТАРИХ САБАКЛАРЫ

Булат ХӘМИДУЛЛИН

Аерылганны аю ашый

Шушы елның җәендә республика матбугатында татар халкының борынгы һәм урта гасыр тарихына кагылышлы кайбер мәсьәләләр буенча бәхәсләр булып алды Танылган тарихчылар Б Солтанбеков «Республика Татарстан» газите, 1995 ел 1 июнь) белән Р Фәхретдинов («Молодежь Татарстана» газите. 34 нче сан) мәкаләләреннән күренгәнчә, «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» дигән уку китабының беренче кисәге һичбер фәнни тәнкыйтьне күтәрә алмый.

Иң әүвәле китап авторлары тарафыннан әйтелгән бер фикергә махсус тукталып узасым килә «XYI гасырда татарлар халык буларак бик нык какшаган була. — дип язалар алар — Торгынлык чире аның барлык өлкәләренә дә үтеп керә » Ап-ачык ки. әлеге китапны язган авторлар М Худяковның шушы мәсьәләгә карата булган фикере белән яхшы таныш Урыс галиме үзенең «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» дигән хезмәтендә болай дип яза «Урыс халкының гаҗәеп тиз һәм куәтле үсеше белән чагыштырганда, болгар-татарларның вәемсыз һәм тыныч тормышында торгынлык сизелә . Әле яңа гына халык булып формалаша башлаган великороссләр эшчәнлекләрен үстерә барган бер чорда алар пәйда булганчыга кадәр үк Идел буенда төпләнгән болгар-татарлар инде шактый көчсезләнеп өлгерәләр » М Худяков үзенең бу хезмәтен 1923 елда бастыра һәм табигый ки. ул. XIX гасыр- XX гасыр башындагы тарихи белем дәрәҗәсенә туры килә Моны М Худяковның Көнчыгыш Аурупа тарихының кайбер катлаулы мәсьәләләрен шәрехләүдә билгеле бер дәрәҗәдә беркатлылык күрсәтүе турында академик М.Усманов инде 1990 елның августында ук язып чыккан иде. Урыс галиме яшәгән чордан соң инде җитмеш ел вакыт узып китте Шул дәвер эчендә бик күп яңа тарихи материал тупланды бит.

Аерым алганда, этник коллективларның яшәеш кануннарын өйрәнә торган этнология фәне дә бик алга китте. Әлеге фәнгә булган ихтыяҗ фәкать XX гасырның икенче яртысында гына туды Җәмгыять белеме фәне дә чагыштырмача күптән түгел генә барлыкка килде Бу ике фән бер-берсенә бик якын торсалар да, алар арасында күп төрле аерма бар Беренчесе җәмгыять үсешенең биологик кануннарын өйрәнсә, икенчесе аның социаль кануннарын өйрәнә Чонки тарихның этник характеры кешелек дөньясының социаль үсеш ритмнарыннан бик нык аерылып тора.

Инде этносларны өйрәнүнең хәзерге алымнары нигезендә XYI гасыр болгар-татарларның нинди этногенетик үсеш кимәлендә торуларын карап узыйк Болгар-татарлар бу чорда чыннан да картая баручы этнос булганмы, әллә юкмы? Юк булса. нигә?

XIII гасыр башында Кече Азиядә һәм Көнчыгыш Аурупада Торкия. Кырым, Латвия Русия һәм Балтыйк буе, шулай ук Кара диңгез янындагы далаларда пассионар ыргылыш булып ала Л Гумилев фикеренчә, «яңа кешеләр — пассионарлар XIY гасыр ахырында тарихи көчкә әвереләләр Шулай итеп, XIY гасыр ахырында Көнчыгыш Аурупада пассионарларның гомуми саны шактый арта Нәкъ менә шушы хәл Дмитрий Донской идарә иткән чорда Мәскәүнең, Туктамыш хан идарә иткән чорда Алтын Урданың көчәюенә сәбәпче була Шул ук пассионарлык алга таба Алтын Урдадан нугайлар династиясе башында торган Идегәй Кырым ханлыгына нигез салган Дәүләт Берди кебек көчле ихтыярлы, батыр һәм дан-шөһрәт яратучы тарихи шәхесләр җитәкләгән урдаларның аерылып чыгуына китергән дә инде. Әлеге урдаларның аерылып чыгуы нәтиҗәсендә XY гасыр уртасында Алтын Урда тәмам таркала.

1445 елның көзендә бүлгәләнеп беткән Бөек Болгарны алыштырган Казан дәүләтенә Урда ханы Олуг Мөхәммәт Мәхмүт хакимияткә килә. Казанны алганда җирле хаким үтерелә. Халык бу үзгәрешкә сөенә генә. Ник дигәндә, ул яңа хакимне урыс баскыннарыннан саклаучы итеп күрә. Бу чорда Бөек Болгарның дәвамчысы — Казан ханлыгы яңарыш чорына аяк баса һәм Идел буе татарларының этник үсешенә нигез булып тора.

Бер карашка, бердәм этник илә̄т булмаган. аз санлы Урда гаскәрләре (3 меңгә якын сугышчы) Казан дәүләтендәге этник хәлгә җитди йогынты ясый алмый кебек. Әмма, алда ук әйтеп үткәнемчә, әлеге Урда гаскәре югары пассионарлыкка ия булган көчле ихтыярлы, батыр һәм дан-шөһрәт яратучы сугышчылардан торган бит. Күрәсең, бу җирле халыкның рухи күтәренкелегенә йогынты ясагандыр. Менә шушы этник үсеш җирле халыкның пассионарлык потенциалы үсүенә китерә һәм, нәтиҗәдә, Казан дәүләте чикләре киңәя, элекке Бөек Болгар чикләре торгызыла Казан ханлыгының хәрби-икътисади куәте бермә-бер арта Ул инде урыс яуларына каршы тора алырдай бай һәм көчле дәүләткә әверелә.

Казан ханлыгында уңай үзгәрешләр башлангач. Алтын Урданың төрле төбәкләреннән күченеп килүче кешеләр саны да арта башлый. Әмма шулай да читтән килгән этник төркемнәр сан ягыннан җирле халык белән чагыштырганда (1-2,5 млн чамасы кеше) бик аз булалар

Урда төркемнәре, акрынлап җирле болгар-татарлар белән катышып, тәмам ассимиляцияләнә.

Шулай итеп, XYI гасырдагы Казан татарларының картайган этнос булуы турындагы фикер белән һич тә килешәсе килми. Казан ханлыгының урыс баскыннарына каршы актив көрәш алып баруы, шул исәптән 1552 елда Явыз Иван явына көчле каршылык күрсәтүе болгар-татарларның картая баручы этнос булудан бигрәк, һәр өлкәдә — икътисадта, мәдәнияттә, сәнгатьтә булсын — чәчәк атып килүче халык булганлыгы турында сөйли. XYI гасырда Казан татарлары һәм урыслар үсеш ягыннан бер дәрәҗәдәрәк торганнар, дип уйлау дөресрәк булыр кебек.

Алайса, Явыз Иван Казан ханлыгын ничек буйсындыра алган соң? Урыс дәүләтенең хәрби-икътисади һәм сәяси яктан көчсезләнүе аның Көнчыгыштагы һәм Көнбатыштагы күршеләре өчен файдалы булмый. Мәскәү бу форсаттан бик оста файдалана, «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән принципны алга сөреп, Көнчыгыш Аурупадагы төрки дәүләтләрне басып алу сәясәтен башлап җибәрә. Кырым, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары, Нугай Урдасы, калмыклар һәм казаклар арасындагы таркаулык, ниһаять, үзенекен эшли: урыс дәүләте тиз арада сәяси һәм икътисади яктан гаять куәтле дәүләткә әверелә.

Казан халкы икътисади яктан шактый нык үскән һәм зур сәяси абруйга ия булган дәүләтләр рәтендә торса да, биләмәләре һәм халык саны буенча Мәскәүдән бик күпкә калыша. Тарихчылар фикеренчә, ул чорда ук инде урыс дәүләтендәге халык саны Казан ханлыгыныкыннан дүрт тапкыр күбрәк булган һәм, табигый ки, моннан чыгып, ике якның гаскәр санын да күзалларга мөмкин.

Казан ханлыгының тар-мар ителүенә андагы халыкның этносоциаль төркемнәре арасындагы таркаулык та сәбәпче була Дәүләтнең үзендә Мәскәү сәясәтен алга сөрүче фиркаләр булуы, аларның һәм кайбер татар феодалларының ачыктан-ачык дошманга хезмәт итүләре исә аны акрын-акрын гына эчтән таркатуга, көчсезләндерүгә юл ачкан

Унөченче бит

Әйе шул, килде-керде, кул биреп исәнләште дә, каршыма ук килеп утырды.

— Ну, тетмәсен теттем, издем-сыттым, башларын бетердем! — дип, кулы белән һаваны ярды. — Андый үтергеч мәкалә дөньяда юк. Сезгә апкилер идем дә, ну, сез аны бастырмыйсыз. Ну, түлке, шеп мәкалә!

Эшнең тыгызрак чагы иде, агайга әйттем:

— Язмагызны алып килегез, шеп икән — гәзиткә бастырабыз, — дидем.

Агай кулын гына селкеде:

— Юк, бастырмыйсыз. Башкалар да бастырмый — куркалар. Ну, түлке — тәнкыйть ул мәкаләмдә! Ну инде сатира, минсиңәйтим! Юк,бастырмыйсыз. Элек коммунистларны күпме сүгеп яздым. Эттән алып эткә салдым. Басылмаган мәкаләләрем — бер капчык!

— Язмагызны алып килегез, агай, укып чыгарбыз, уйлашырбыз.

— Әһә, әйтәм бит, бастырмыйсыз, дип! Уйлашырбыз, имеш. Уйлашырга калгач — бетте инде ул! Уйлашмыйча бастырсаң гына!

— Агай урындыгын якынгарак тарта төште, үзе пышылдауга ук күчте. — Ә син, беләсеңме соң, анда бит тегеләргә дә эләкте...

— Кемнәргә? — дип түшәмгә карадым мин, агайның бармагы югарыга таба төбәлгәнен күргәч.

— Тегеләргә! — диде агай һәм тавышына янә дә мәгънәле пышылдау өстәде. — Хәтта үзенә дә!

— Кемнең үзенә?

Агай кинаяле итеп баш чайкады:

— Соң... үзенә инде — Президентка да! Аңладыңмы инде?! Әһә, әйтәм бит, бастырмыйсыз, дип! Шүрлисез, патамушты. Ә үзегез. җитмәсә әдәби гәзит булып йөрисез! Менә шул энекәш минем басылмаган мәкаләләр теге елларда да бер букча иде..

— Агай алып килегез мәкаләгезне, бастырабыз! — дидем мин гәзит өчен үртәлеп, һәм бармагымны түшәмгә таба төрттем — Шүрләмичә бастырабыз Аларга гел эләгеп тора инде, тагын бер эләккәннән генә...

— Юк, бастырмыйсыз... Бик зур ул, бер биткә генә сыеп бетәрлек түгел. Ну, теттем тетмәләрен, түлке! Ну, шеп мәкалә, бастырмыйлар гына...

— Агай! — дидем мин, инде шактый тынычлана төшеп — Ике санга бирербез өч санга — озын булса Бастырабыз мәкаләңне китер давай!

Агай бераз тын горды Аннан соң әкрен генә урынынннан күтәрелде

— Беләм мин аларны бер мәкалә язсаң, бәйләнеп гецкәгә тияләр Теге елларда күпме сүктем мин аларны Күпме мәкаләмне бастырмадылар.

Шулай диде дә агай чыгып китте

Бер ай үткәч мин әлеге агайны «Шәһри Казан» гәзитендә күрдем Дөресрәге ачык ишектән аның таныш тавышын ишетеп калдым

— Чуртым да бастырмыйсыз! Шүрлисез чөнки Үт-терчески мәкалә бит ул! Мин ул мәкаләмдә бөтенесен фаш иттем Ә сез тәнкыйтьтән куркасыз Әнә «Мәдәни җомга» да бастырмады сез дә бастырмыйсыз! — дип зарлана иде ул

Менә шул Мин үзем әле һаман аның «Үт-терчески» мәкаләсен китергәнен көтеп йөрим Китерсә нишлибез? Бастырабызмы юкмы җәмәгать?!

Нияз АКМАЛ.

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Бастырабызмы, җәмәгать?

(**«Килде-керде, кул биреп исәнләште»** дигән шөлкемнән).

Тәш

Гәпсәхи күп акча түләп, паспортын алмаштырып кайтты. Паспорттагы «татар» сүзе урынына «булгар» дип яздыртты да кайта-кайтышлый ук күршесе Мишук янына керде:

— Вәйт, сасит, ты минә көн саен «әшерелгән татар» дип кыйный идең. Мин хәзер татар түгел! — дип кычкырды Гәпсәхи.

— Чо-о! — дигән тавыш ишетелде.

Гәпсәхи кухняда аракы эчеп утыручы күршесенә паспортын сузды. Мишук бер паспортка, бер Гәпсәхинең чыраена карап-карап торды да:

— О-хо-хо, вот это да! — дип күршесенә кочагын җәйде.

Мишуктан самагун, сарымсак, дуңгыз кыртышы, бакча тәмәкесе, тир һәм шовинизм исе бөркелде. Гәпсәхи укшып алса да, түзде. Бик тә чыдам ул Гәпсәхи дигән бәндә, түзә, чөнки ул чын интернационалист.

— Ты мне друг! — дип Мишук күршесенең аркасына сугып алды. — Значит, син татар да, поганый да түгел икән, син кем инде хәзер?

— Булгар! — дип күкрәгенә кагып алды Гәпсәхи. — Булгар!

Мишук стаканны көмешкә белән тутырып, Гәпсәхигә сузды. Эчте Гәпсәхи. Аннан соң Мишук үзенә салды. Ул да эчте. Бераз исерә төшкәч, Мишук тагын сорады:

— Ничек дидең әле син... а, да, булгарин! О-о, я люблю булгаринов!

— Да, мин булгар хәзер! Син бит мине поганый татар булганым өчен гел-гел кыйный идең, хәзер син мине кыйный-алмассың, брат!

— Чо?

— Не смеешь патамучто!

— Но ты, сука-а! — дип акырды Мишук. — Куда ты денешь свою вот эдакую твою татарскую морду!

Эшләре катлаулана төшеп, Мишук белән Гәпсәхи арасында тагын сугыш чыкты. Сугыш чыкты дип инде, Мишук кыйнады, Гәпсәхи түзде, түзә ул, чөнки чын интернационалист.

Мишук күршесен рәхәтләнеп тукмады. Гәпсәхи түзде, түзем ул Гәпсәхи. Мишук Гәпсәхинең кәләпүшен салдырып, эченә тәрәт итте. Барыбер түзде Гәпсәхи. Мишук шул кәләпүшне башына батырып кигезгәндә дә сүз әйтмәде Ул бары тик шешкән иреннәре белән

— Мин бул... гар... я не татарин! — дип мыгырдады.

Шешләре кайткач, Гәпсәхи тагын паспортын алмаштырырга китте. «Милләте» дигән урынга ул «русский» дип яздыртты

Чыннан да моннан соң Мишук аңа башкачарак карый башлады, ахрысы кыйнаудан туктады. Киресенчә алар бергә эчеп иң башта урамда татарча сөйләшкән җегетләрне тукмап кайттылар. Аннан соң «Болгар әл җәдид» җегетләрен сагалап торып әйкәләделәр Ләкин бу дуслык та озакка бармады бергәләшеп эчә торгач, исерек саташу вакытында Мишук дусты Гәпсәхине үз өендә суеп чыкты Бу җинаятьне эзләтүче дә. эзләүче дә булмады Шул килеш калды. Таныш-белешләре күршеләре аптырашта иде. Бу Гәпсәхине соң кайсы зиратка җирләргә икән? Татар зиратына җирләр идең, ул үзен урыс дип игълан итте урыслар каберстанына җирләр идең, чүтеки ул мөселман анадан туган бәндә. Шуннан уртак бер фикергә килделәр Гәпсәхинең мәетен моргта яндырдылар да, көлен бер банкага тутырып. кадакка элеп куйдылар Ләкин мәеттән калган бер уч бу көлне килеп алучы җирләргә теләүче табылмады. Бераз вакыттан соң көлне язгы ташуга чыгарып ташладылар

АЛТАТАР.

Кирам САТИЕВ

13 саны инсаны

Бүген айның 13 нче көне. Йокымнан сикереп торып, юынып-кырынып, кызыбызны 13 нче гимназиягә укырга озаттым. Хатынны уятып, аның җыенганын сәгать ярым чамасы көтеп, дога кылып, юлга чыктык. Ул эшкә бара, ә мин — уйнарга: Көнбатыш Себердәге бер шәһәр юбилеена — гастрольгә. Такси көтеп торганда, 13 нче трамвай килеп җитте. Утырдык. Күпмедер барганнан соң, тукталышта төшеп калдык. Ул да булмады, бер танышым машинасы белән килеп туктады. Номеры 13 тә 13 иде. Ул безне театр бинасы каршына, Горький урамы, 13 нче йорт янына илтеп куйды. Үзем куркам, үзем йолкам, дигәндәй, күңелем тыныч түгел. Сиздермәскә тырышам. Театр янында төялеп аэропортка юнәлдек. Арадан бер артист «Мәдәни җомга» гәзитен укып утыра. Ни күрим: 13 нче октябрьдә басылган 13 нче сан. Иртәдән үк, мин әйтәм, гел 13 саны, нәрсә булды соң, нәрсә ярамады?

Ниһаять, 13 ендә басылган 13 нче санлы «Мәдәни җомга» минем дә кулга эләкте. Кызык өчен генә 13 нче биткә күз салдым. Касыйм ага Тәхауның шигырьләре белән танышып утырам. Юри генә саныйм: барысы 13 куплет!

Сургут шәһәре безне яхшы каршы алды. Алмаска соң, бүген бит 13 е! 13 ләр күренмәсен дип, автобуста күзләремне йомып утырам. Ачып җибәрсәм: Столовая, ул. Магистральная, 13, дип язылган.

...Инде күңелемнән кунакханәнең дә 13 нче бүлмәсенә урнаштырырлар, дип уйлап торам. Юк, булмады. Анда башка мөсафирлар урнашкан икән инде. Ул бүлмәне даулап йөрмәдем. 13 санын яратучылар дөньяда мин һәм Каспаров кына түгелдер... Әнә, аның бөтен язмышы «13» белән бәйләнгән. Дөньяның 13 нче чемпионы да ул бит

Әйе, кемгә ничек. 13 саны ул, кем әйтмешли, кешесенә карап туры килә Йә уңасың, йә туңасың. Әнә бит, патша Русиясенең 1913 нче елын әле хәзер дә сагынып искә алалар Димәк, лаеклы ул аңа. Минем әткәм дә шул елны дөньяга килгән Нәкъ 13 елдан соң әнкәм туган. Тукаебызның үлгән елы да 13 нче ел...

... Миңа, ятим балага, моңсу да, ямансу да булып китте Күзләрем яшьләнде... Аларның якты истәлегенә, рухларына багышлап, дога кылыр өчен, Сургут мәчетенә таба атладым... Менә шул, мин — 13 санының инсаны.



Кем идарә итәр?

Үзәк клиник шифаханәдә дәвалану чы Президент Б Ельцинның сәламәтлеге яхшыру яхшырмау турында төрле гәзитләр төрлечә яза Шуңа бәйле рәвештә **«Известия»** гәзите (31 10 95) Президент авырып үз вазифасын башкара алмаса ил белән идарә итү кемгә йөкләнә дигән сорау куеп шуңа җавап бирә Русия Федерациясе Конституциясенен 92 нче маддәсенең өченче өлешендә билгеләнгәнчә Президент үз вазифасын үти алмаган барлык очракларда аның вазифаларын вакытлыча Русия Хөкүмәте Рәисе башкара

Метро да кабер була ала

Матбугатта хәбәр ителгәнчә Баку шәһәре метросында чыккан янгын нәтиҗәсендә 289 кеше һәлак булган 300 кеше төрле дәрәҗәдә җәрәхәт алган Янгын сәбәбе ачыклана Монын диверсия нәтиҗәсе булуы да мөмкин

Казанда эшсезләр арта бара

Казанда эшсезләр күпме һәм кемнәр алар? Бу сорауга **«Аргументы и факты»** атналыгының (№44) Татарстанда чыга торган кушымтасы. 1 октябрьгә дип яза. теркәлгән 5471 эшсезнең 4701е — хатын-кыз Яшь ягыннан караганда алар 30 белән 50 яшь арасындагы кешеләр Күбесе югары яки махсус урта белемле Тагын да төгәлрәк әйтсәк алар — инженер яки икътисадка бәйле һөнәрне үзләштергән белгечләр Хәзер конструкторларга технологларга. программист химикларга ихтыяҗ юк дәрәҗәсендә

Әлбәттә эшсезләр арасында эшче хатын-кызлар тегүчеләр. пешекчеләр ЭВМ операторлары контролерлар байтак Эшсез ирләр арасында да инженер-техник хезмәткәрләр һәм машина йөртүчеләр күпчелекне тәшкил итә

* * *

Русия Федерациясе Дәүләт Думасы Чечняны Русия икътисадын бөлдерүче «тишек» булыр дип исәпли

(«Российская газета»).

* * *

Татарстан Республикасының Дәүләт Советына депутатлыкка элекке кандидатлар Анатолий Васильев белән Морат Сираҗин «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясен үзләренең намусын. дәрәҗәсен пычратуда гаепләп судка биргәннәр иде Моның өчен алар телерадиокомпаниядән 2 миллиард сум түләүне таләп итәләр Казанның Бахитов районы суды аны һаман карый алмый дип яза **«Вечерняя Казань»** гәзите (№174) судның килечәк утырышы 13 ноябрьгә билгеләнгән ул булырмы юкмы?

Иш янына куш

Борис Ельцин Үзәк клиник шифаханәдә дәваланып ятканда минималь пенсияләрне һәм эш хакларын күтәрү турындагы федераль законга кул куйган Шуның нигезендә Русия Федерациясендә картлык буенча минималь пенсия һәм минималь айлык эш хакы түбәндәге күләмнәрдә булачак

1 ноябрьдән 57750 сум.
1 декабрьдән 60500 сум.
1 гыйнвардан 1996) 63250 сум

Шуңа бәйле рәвештә барлык пенсияләр 1 ноябрьдән 1 октябрь аендагыга караганда 1 05 тапкырга. 1 декабрьдән 1 1 ә 1996 елның 1 гыйнварыннан 1 15 тапкырга артачак Бу өлләнең зур булмаса да иш янына куш булыр әле

Мәктәп шартлатып өй салмакчы булган

Чаллыдагы 45 нче мәктәпнең шартлау ихтималы турында бишенче сыйныф укучысы Артур Ю милициягә шалтырата Аңа миллион сум акча бирсәләр бу хәл булмаячак. ди Ә икенчесе 100 миллион сорый Акчаны капчыкка тутырып шәһәрдән авылга чыга торган җирдәге тукталышта калдыруны таләп итә Аны үтәмәгәндә мәктәп яки балалар бакчасы шартлатылачагын кисәтә Аны да эзләп табалар Авыл фельдшеры була ул Террор юлы белән табылган акчаны үзенә йорт салуга тотарга хыяллана Бу хакта **«Известия»** гәзите (№208) хәбәр итә

Тәртип сакчысы — гаепле

Ике ел буена барган тикшерүләр нәтиҗәсендә милиция сержанты Хәбир Идрисов гаепле дип табылды Ул «Итил» хоккей командасы (хәзер «Ак



барс») яшь хоккейчысы Владимир Старостинның аркасына атып, аның умыртка баганасын зарарлаган иде. Сержантны нибары ике елга ирегеннән мәхрүм иттеләр. ә хоккейчы гарип булып калды Бу хакта **«Известия»** гәзите (28 10 95) бөтен дөньяга хәбәр салды

«Нур»ның нуры

Кыргызстанда яшәүче татарлар өчен «Нур» журналы чыга башлауга ике ел тула Аны «Туган тел» татар-башкорт иҗтимагый-мәдәни үзәге оештырган **«Татар иле»** гәзите (№38) аның мөхәррире Хәйдәр Габдрахман белән әңгәмә урнаштырган

Асыл бер зат

«Заман-Татарстан» гәзите «Асыл бер зат турында хикәят» дигән баш белән (№60) төрки халыкларның күренекле шәхесләреннән берсе. атаклы дин галиме җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Муса Яруллаһ улы Бигиенең туууна 120 ел тулуны олы хөрмәт белән билгеләп үтә

Өмет канаты

Татарстан Республикасындагы инвалидларның социаль-иҗтимагый оешмалары ассоциациясе һәм РФ пенсия фонды бүлеге чыгара торган **«Выбор»** гәзите (№20) үзенең бер битен татарча язмаларга багышлый Анда Франклин Рузвельт турындагы «Күренекле инвалид-президент» дигән язма игътибарны үзенә җәлеп итә

Гәзит шулай ук «Ветеран» коммуналь-сәүдә предприятиеләре каршында мохтаҗларга тотылган киемнәрне бушлай бирү бүлеге ачылуын һәм андый киемнәрне тапшырырга телләүчеләргә Казанда кайсы кибетләргә мөрәҗәгать итәргә (№750, Тынычлык урамы 33 №752 — Мәүлетов урамы, 17 №753 — Восстание урамы. 83, №757 Һади Такташ урамы 77) кирәклеген күрсәтә

Собчак кызы җәтмәгә эләгә һәм... котыла

Петербургның типтереп яшәргә яратучы яшьләре Мәскәү белән чагыштырганда күпкә «крутойрак» икән Купгән түгел җирле омончылар шәһәрнең иң дәрәҗәле төнге клубларына һөм дискотекаларына «ау» оештырган Аның нәтиҗәләре һәрвакыттагыча тәнге хәятне яратучылар өчен күңелсез тәмамлана. чөнки тәртип саклаучылар алар белән алай нәзакәтләнеп тормыйлар

«Марсталл» клубында ОМОН егетләре наркотик эзләп. танылган «Агата Кристи» төркеменең кыйммәтле музыка коралларын ватып бетерәләр. «Планетарий» клубында исә петербурглыларга гына түгел, ә бирердә кәеф-сафа коручы голландларга. алманнарга да бик каты эләгә Тәртип саклаучылар, аларны идәнгә яткырып, бик каты тәпләп ташлыйлар

Петербург мэры Анатолий Собчакның дискотекага баштан-аяк гашыйк кызы да. наркотиклар кулланучы шикләнелеп. бер тапкыр ОМОН егетләренә эләгә Әмма «кыю егетләр» кулларына кем килеп капканын белгәч, кызны да, дусларын да тизрәк җибәрүягын карыйлар Бәласеннән баш-аяк, янәсе.

«Московский комсомолец».

Ярославль «маугли»е

Ярославльдә алты яшьлек Андрюха Пушкин биш ай буена эт оясында яши Динка кушаматлы овчарка аны үз ана сыннан да яхшырак карый

Эт оясында яшәү урамда көн күрүдән яхшырак — җил-яңгыр тими Немец овчаркасы корсагына сыенсаң, бөтенләй җылы була Берара Андрюхага әлеге зур эт чыннан да әнисе кебек булып тоела Биш ай бергә яшәү чорында Динка аңа ник бер тапкыр өрсен, ырылдасын Дөрес, аяз салкын көннәрдә моңаеп улаштыра Динка, мондый чакта аның йонлач муенын кочаклаган Андрюха да нечкә бала тавышы белән аңа кушыла Ач бала этнең имчәкләрен суыра

Иртән хуҗалары әткә ашарга салгач, сәякләр ташлагач, Динка «әйдәшен» онытмый, сәякне аңа да алып килә Андрюха кәндезләрен оядан чыкмый, тотып исерек анасына кайтуларыннан курка Ул әнисе янына килгән исерек ирләрдән һәм психик авыру абыйсы Колядан күргән җәберләргә түзә алмыйча әнә шулай чылбырдагы зур эт янына килә

Гадәттә, малайларны ырлап куркыта торган эт бу юлы аны үз янына сыендыра Аның кулларын ялый

Малай төннәрен генә, кешеләр сизмәсен дип, дүрт аяклап, эт оясыннан чыга һәм йомышларын йомышлый, эт савытында калган ашны ашый Эт кебек ырларга, дүрт аяклап йөгерергә өйрәнә, акрынлап үзенә ашарга эзләп урамга да чыга Шундый «ау» вакытында Рената ханымга очрамаган булса, ул тагын күпме шунда яшәгән булыр иде, билгесез Мөлаем ханым аңардан сораштыра башлагач, малай барын да сөйләп бирә Аннан соң бу шәфкатьле хатын тырышлыгы белән малай Ярославль тимер юл балалар йортына урнаштырыла, әнисе суд карары белән ана булу хокукыннан мәхрүм ителә. Бу хакта **«Комсомольская правда»** (№1202) гәзите хәбәр итә.

Гыйбрәт алыгыз, кешеләр

Остин, Техас. Хатынын гел рәнҗетеп, кимсетеп яшәгән Ральф Биклер коточкыч җәзасын алган: сүгенеп ачылган авыз ун ел инде ябылмый!

Күршеләре әйтүенә караганда, Ральф — бик әшәке телле, хатыны белән исәпләшмәүче кеше. Хәзер аңа куе, каты ризыклардан баш тартырга туры килә Сөйләшә алмый, кәгазьгә язып аралаша, хәтта әске иренен ялау өчен дә шактый көч кунярга туры килә. Ральф инде 17 операция ясаткан, әмма файдасы тимәгән, авызы һаман ачык.

Иремне бу кыяфәттә күрү бик газаплы, — ди рәнҗетелсә дә хәләлен авыр хәлдә ташлап китмәгән хатыны Милли, — нишлисең, өлешеңә тигән кәмешең. Язмыштан узмыш юк, бәлки, бер дәвасы табылыр дип сабыр итәбез.

41 яшьлек тәзүче сөт. шулпа, солы боткасы, коктейль кише тагам белән көн күрә Бәхетсезлек котмәгәндә, 1985 елның июль аенда килә.

Йомыркалы бифштекс бик озак пешә, дип өстел артында сабырсызланып утырган Ральф. «Нәстә мыштырдыйсың анда, фәлән-фәсмәтән! дип җидә бабамны, аларның кабер такталарын искә төшереп сүгенә башлады Анңары кинәт тынып калды, — ди миссис Милли. — Борылып карасам, иремнең авызы киң итеп ачылган, йөзе ачулы, ә үзе бер сүз дә әйтә алмый! Кыскасы, ул әлегә сүрәттәгечә авызын ачып каткан Мин аны хастаханәгә алып бардым, лакин авызын япгыра алмадылар.

Шуннан соң да табиблар уколлар ясап, яңак мускулларын йомшарту өчен нинди генә дарулар бирмәгән Ральф Биклерны дөньяның иң атаклы белгечләре карый, күбесе аны бушлай, дан өчен дәвалый Аңа 17 операция ясыйлар, тик берсененң дә ярдәме тими Операцияләрдән соң Биклерның авызы азга гына (иң күбе 6 сәгатькә) ябылып тора да яңадан элекке хәленә кайта Күп белгечләр бу авыруны дарулар һәм операция ярдәмендә дәвалап булмый,дигән фикердә тора

— Бу психоматик авыру булырга тиеш, — ди доктор Хенрик Бауэр — Хикмәт яңак мускулларында, авызда түгел, баш миендә булырга тиеш Хатынына, гомумән, хатын-кызларга булган коточкыч ачу бетмичә, Биклерның авызы ябылмаячак

Вакыт уза, гомер үтә, Биклерның киң ачылган авызы, ачулы күз карашы миннән гыйбрәт алыгыз, кешеләр, дигәндәй кисәтеп тора...

(«Всемирные новости»).

Язмаларны матбугатка Заһид ШӘФИГЫЙ әзерләдә

Саклəбилəр патшасына

әл-Мөктәдирдән илче булып барган Әхмәд ибне Фазлан китабы

(Борынгы текстны СОЛТАН ШӘМСИ эшкәртте һәм тәрҗемә итте)

(Дәвамы. Башы 16 нчы санда).

Аннан без Хувар әр-Рәйга юнәлдек, анда өч көн кунгач, Симнәнгә, Симнәннән әд-Дәмнанга юл тоттык. Анда без көтмәгәндә Ибне Каранны очраттык, бу адәмнән качып тиз генә кәрван эченә кереп яшерендек[4]. Бары тик Иранның иң зур шәһәрләренә кергән Нәйшәпурга килеп җиткәч кенә тынычланып калдык. Бу вакытта Иран армиясе башлыгы Ләйлә ибне Ногман үтерелгән иде инде, һәм без анда Харасан гаскәре башы Хәммәвәйһ Күсәне очраттык. Аннан соң юл безне Сирахс, Мәрв, Кушмәһәнгә китерде. Кушмәһән — Әмул сахрасының[5] бер читендә урнашкан икән.

Сахрага аяк басканчы, дөяләргә ял булсын дип, өч көн анда тордык. Аннан Амул каласына (хәзерге Чарджоу каласы) чаклы чүлне аркылы чыктык та Җәйһун елгасын кичтек һәм Әфирабр рабат Таһирә ибне Галигә килеп җиттек. Соңгысы чик сызыгында урнашкан, үзе ныгытылган, кәрван-сарае да булган бер чик саклау ноктасы икән. Аннан без Бәйкәндкә юнәлдек, аннары Бохарага кердек һәм әл-Җәйһани[6] хозурына килдек. Бу кеше Харасан әмиренең төп таянычы, аның барлык эшләрен алып баручы иде. Аны биредә изгелеге-миһербанлылыгы өчен «шәех-таяныч» дип тә йөртәләр икән. Ул озакка сузмыйча иң элек безнең өчен торак хәстәрен күрде һәм, махсус кеше билгеләп, аңа ни теләсәк шуны эшләргә, ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерергә боерды. Шулай итеп, без аңарда берничә көн ял иттек.

Соңрак ул әмир Наср ибне Әхмәдтән безне кабул итүен сорады һәм без аның хозурына кердек. Әмир 16-17 яшьлек әле сакал да чыкмаган яшүсмер булып чыкты. Шулай да без аны олылап әмир сыйфатында сәламләдек, ул исә безгә утырырга кушты. Аның беренче сүзе:

— Мөэминнәр әмире, минем мәүланымны нинди хәлдә калдырдыгыз? Аллаһ аның гомерен озын кылсын, үзенең, якыннарының, яраннарының, хезмәтчеләренең күңелен шат әйләсен! — булды.

Без аңа:

— Исән-имин калды, — дип җавап бирдек.

Ул безгә:

— Аллаһ аның иминлеген арттырсын, — диде.

Аннары без аңа элекке вәзир Ибне әл-Фуратның эш башкаручысы Әл-Фадл ибне Мусаән-Насранидан Арсасушмисан утарын тартып алу һәм аны Әхмәд ибне Муса әл-Харәзмигә тапшыру хакында хат укыдык. Шул ук хатта безне Харәзем хакименә озату, аннан Баб әт-Төрек аша үткәрү[7] өчен язылган хатны сакчылар белән озата бару, юлда очраган кыенлыкларны алып ташлау, безнең иминлегебезне кайгырту кирәклеге турында да сүзләр бар иде.

Моңа каршы ул:

— Әхмәд ибне Муса үзе кайда соң? — дип сорады.

— Без аны Мәдинәт әс-Сәламиндә калдырдык, биш көннән соң юлга чыгарга тиеш иде, — дидек.

Ул:

— Алайса, мөэминнәр әмире, минем мәүланымның боерыгына буйсынам, Аллаһ аның гомерен озын кылсын! — дип җавап бирде.

Бу хактагы хәбәр әл-Фадл ибне Мусаән-Насранигә — ибне әл-Фуратның эш башкаручысына — да килеп ирешкән һәм ул Әхмәд ибне Муса эше тирәсендә ятьмә үрә, тозаклар кора башлады. Ул Харасан юлында урнашкан Сирахс каласыннан Бәйкәндкә чаклы арада эш алып барган полиция башлыкларына, Әхмәд ибне Муса әл-Харәзминең тышкы кыяфәтен тасвирлап, аны кәрвән-сарайларда һәм башка күзәтү урыннарында сагалап торырга кушып хатлар җибәрде. Әгәр дә берәрсе аны тота-нитә калса, бездән хат килеп җиткәнче сак астында тотсын, хатта күрсәтелгәнчә эш итсен, дип боерды.

Нәтиҗәдә, Әхмәд ибне Муса әл-Харәзми Мәрв каласында кулга алына һәм ябып куела. Без исә Бохарада егерме сигез көнгә тоткарландык. Әл-Фадл ибне Муса ән-Насрани Башту углы Габдулла һәм башкалар белән алдан ук сөйләшеп куйганга, тегеләр:

— Әгәр монда калсак, кинәт кыш киләчәк һәм без Харәземгә барып өлгерә алмаячакбыз, Әхмәд ибне Муса үз эшләрен бетергәннән соң безне барыбер куып җитәчәк, — дип бездән юлга чыгуны таләп итә башладылар.

Мин Бохараның төрле төстәге дирһәмнәрен күрдем, шул исәптән әл-гыйтрифи дип йөртелгәннәрен дә. Аларны Харасан хакиме Гыйтриф ибне Ата хөрмәтенә шулай атап йөртәләр икән. Алар бакыр, кызыл һәм сары бакырдан сугылган. Шундый йөз дирһәм бер көмеш дирһәм бәясе тора.

Хатыннары өчен калым-мәһәр түләү аларда түбәндәгечә эшләнә. «Кемнеңдер углы кемнеңдер кызына фәләнчә мең дирһәм гыйтриф бәрабәренә өйләнә», дип игълан ителә. Аларда күчемсез милекне һәм колларны сатып алу да шул ысул белән башкарыла. Аларда башка төрле дирһәмнәр кулланышта йөрми. Моннан тыш, аларда сары бакырдан гына сугылган дирһәмнәр дә бар. Андый дирһәмнәрнең кырык данәсе бер дәнәкә көмеш бәясе йөри, бу дирһәмнең алтыдан бер өлешен тәшкил итә. Тагын аларда сары бакырдан сугылган Сәмәркәнд дирһәмнәре дә бар. Алтысы бер дәнәкә бәясе йөри.

Шулай итеп, Габдулла ибне Башту һәм башкалар авызыннан бу якларда кышның кинәт килүе хакында ишетү белән без Бохарадан чыгып киттек. Моның өчен безгә елга артына кире кайтырга[8] һәм Харәземгә чаклы кораб яллаган җирдән Харәземгә хәтле юл ларга туры килде. Без кораб ял ике йөз фәрсахтан[9] да артык булып чыкты. Шуңа күрә берничә көн барырга туры килде. Елга буенча сәяхәт безнең өчен бик мәшәкатьле булды — көннәр суык торды.

Харәземгә барып җиткәннән соң без шәһәр әмире хозурына килдек. Ул өлкә хакиме Мөхәммәд ибне Гыйрак исемле кеше булып чыкты. Ул безгә хөрмәт күрсәтте, бүләкләр бирде, әйбәт итеп урнаштырды. Өч көн үткәч, үзенә чакыртып алды да, безнең белән ничек итеп төрекләр җиренә үтеп керү мәсьәләсен тикшерә башлады. Ул болай диде:

— Мин сезгә юлыгызны дәвам итәргә берничек тә рөхсәт итә алмыйм, бер үк вакытта сезне куркыныч астында калдырырга да хакым юк. Мин беләм, бу хәйләле эшне сезгә Тәгин углан оештырган, чөнки ул элек бездә торган иде һәм мин аны каферләр илендә тимер сәүдәсе белән шөгыльләнгән чагыннан ук беләм. Надыйр әл-Хурамины ул алдаган һәм аны саклəбиләр патшасы хатын мөэминнәр әмиренә тапшырырга күндергән. Бөек әмирнең, ягъни Харасан әмиренең, саклəбиләр илендә мөэминнәр әмере файдасына вәгазь сөйләүне җайга салу хокукы күбрәк тә иде. Чөнки сез еракта, Мәдинәт әс-Сәламиндә яшисез, сезнең белән саклəбиләр иле арасында ят диндәге меңләгән кабиләләр, кавемнәр тереклек итә. Һәм мин моны әмиребезгә карата гаделсезлек дип саныйм. Димәк, сезгә шуны киңәш итәм: иң әүвәл бөек әмиргә хат язарга кирәк, ул үз чиратында хат аша хәлифә хәзрәтләре белән элемтәгә керер, Аллаһ аңа ярдәм итсен, ә сезгә исә җавап хаты килгәнче биредә калып торырга туры киләчәк.

Шулай без аннан бернигә ирешмичә чыгып киттек. Икенче көнне кабат килдек, аңа ничек тә ярарга тырыштык, безгә китәргә рөхсәт итүен үтендек. Без болай дидек:

— Менә алдыгызда мөэминнәр әмиренең боерыгы — аның хаты. Кабат элемтәгә кереп торудан ни мәгънә?

Шул сүзләрдән соң ул ризалыгын бирде.

Шулай без Харәземнән әл-Җөрҗәниягә[10] барып җиттек, су юлыннан аларның арасы илле фәрсах тирәсе булыр.

Миңа Харәземдә киселгән, кургаштан сугылган, бәясе төшкән, авырлыгы кимегән бакыр дирһәмнәр күрергә туры килде. Авырлыгы дүрт дәнәкә ярым торган дирһәмне алар «тазиҗә» дип атыйлар. Акча ваклаучылар анда сәяктән ясалган уен шакмаклары, бөтерчекләр һәм дирһәмнәр саталар. Харәземлеләр шактый тупас табигатьле халык. Сөйләшүләре сыерчык чыркылдаганны хәтерләтә. Харәзем өлкәсендә әл-Җөрҗәниядән бер көнлек юлда Әрдәкү дигән авыл бар. Халкын кәрдәлиләр дип йөртәләр. Аларның сөйләшүе нәкъ бака бакылдаган кебек. Алар мөэминнәр әмире Гали ибне Әбу Талибтан намаз укыган саен ваз кичәләр, Аллаһ алардан разый булсын.

Шулай без әл-Җөрҗәниядә озакка тоткарланып калдык. Җәйһүн елгасы башыннан алып ахырына кадәр туңды, бозның калынлыгы унҗиде карышка җитте. Атлар, качырлар, дөяләр һәм арбалар аның өстеннән юлдан йөргәндәй чыгалар, ул нык тора, һич кенә дә сыгылмый, һәм чатнамый. Өч ай дәвамында боз шул көенчә сакланды. Без анда шундый бер ил күрдек — ул суыклар иле Әз-Зәмһәририне хәтерләтә, гүя күк капусы аның өстендә ачылган диярсең. Анда кар да гаять көчле ачы җил белән ява. Әгәр дә бу илдә яшәүче берәр кешенең икенче берәүгә яхшылык эшлисе килсә, ул аңа: «Әйдәле, миңа керик, сөйләшеп утырырбыз... Миндә учак яна», — дип әйтә. Шулай ул аңа зур ихтирам һәм илтифат күрсәтә. Утын мәсьәләсенә килгәндә, Аллаһ аларга мәрхәмәтле булган — бу илдә утын бик арзан. Бер арба саксаул утыны ике дирһәм генә тора.

Бу илдә өйгә килеп кергән фәкыйрьләр ишек катында гына көтеп тормастан түргә үк узалар, җылыну өчен янган учак янына килеп утыралар. Бераздан соң «пакәнд!» дип әйтәләр — бу «икмәк» дигәнне аңлата. Хуҗа кеше аңа ашарга берәр нәрсә бирә, бирмәсә — теләнче чыгып китә.

Безнең әл-Җөрҗәниядә торуыбыз шундый озакка сузылды ки, рәҗәб, шәгъбан, рамазан, шәүвәл айларын без анда үткәрдек. Болай тоткарлануыбызга үтә зәһәр салкыннар тору сәбәп булды.

(Дәвамы бар).

● Борынгы төркиләр. Кәнәфи НӘФЫЙКОВ рәсеме.

---

[4] Таулы Табаристан феодалы Ибне Каран хәлифәнең дошманы була.

[5] Әмул сахрасы — Көньчыгыш Караком чүле.

[6] Әбу Габдулла Мөхәммәт ибне Әхмәд әл-Җәйһани саманыйлар дәүләтендә министр вазифаларын башкарган

[7] Баб әт-Төрек — Төрекләр капкасы. Харәзем чигендәге саклау урыны Аны үткәннән соң төрек-угызлар җире башланган.

[8] Сүз Аму-Дәрья елгасы турында бара.

[9] Фәрсах — 6 — 7 чакрымны тәшкил итә.

[10] Җөрҗәния — Иске Үргәнеч элек шулай аталган

ЫШАНСАҢ — ЫШАН, ЫШАНМАСАҢ — ЮК

Күптән түгел Мөхәммәтнур Муллануровның «Менә бу савыктыручы ичмаса» дигән китабы дөнья күрде.

Анда халыкара «Планетаны яңарту» ассоциациясе вице-президенты, халык табибы, халыкара информатика академиясе академигы Рафикъ Миңнекәев турында сүз бара.

«Минем савыктыручы булырмын дип уйлап та караганым юк иде. Язмыш кушкандыр инде: 1991 елның октябрь-ноябрь айларында Вятка Аланында яшәүче сеңлем Рәйсә үзе белән бергә эшләгән хатынның Галәм белән элемтәгә керә алуы турында сөйләде һәм озакламый шушы система буенча укыту курслары булачагын әйтте. Мин үзем бу системага ышана торган кеше түгел идем, шулай булса да, каршы килмәдем.

Курсларда ике көн укыгач, миндә кеше организмын кул белән тою сәләте барлыкка килде. Аннары, Мәскәүгә, «Планетаны яңарту» ассоциациясенә укырга киттем. Аны әйбәт кенә тәмамлап, 1992 елның мартында халыкара дәрәҗәдәге дипломга лаек булдым»,— дип яза Рафикъ әфәнде үзе турындагы китапка сүз башында.

Бу китапта аның ничек итеп илаһи көчкә ия булып китүе, ничек итеп кешеләрдәге төрле авыруларны дәвалавы, бу юлда нинди каршылыкларга очравы, нинди уңышларга ирешүе турында сөйләнә. Китапта Миңнекәев сеансларына йөреп сихәтләнгән кешеләрнең рәхмәт хатлары да урын алган.

Бу сәхифәдә без укучыларыбыз дикъкатенә Рафикъ Миңнекәевнең бер ярдәмчесенең ничек итеп халык табибы белән аралашып китүе, шунда күңел күзе ачылып, аның ярдәмчесе булып бергә эшли башлавы турындагы язмасын тәкъдим итәбез

Уй белән дәвалаучы

Мин Шәмсиева Рушания Әхмәтвафа кызы булам. Белемем буенча — педагог. Соңгы ун елда директорның укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары булып һөнәр училищесында эшлим.

Ничек итеп үтәли күрә башладыммы? Бу сорауга җавап бер генә — ул Рафикъ әфәнде Миңнекәев белән бәйле.

Җәйнең аяз, кояшлы иртәсе. Без күршебез, хезмәттәшләрем белән бергә табигатьнең иркен кочагына җиләк җыярга дип юл тоттык.

Ашыгабыз. Тик җиләкләребез бездән качалар. Иптәшләрем икенче аланга чакыралар. Китәсем генә килми бит басып торган урынымнан! Кызлар инде югала башладылар. Кузгалырга уйлыйм. Чү, миңа җиләкләр «Без монда бик күп, канәгать бул, китмә!» — дип пышылдадылар. Шулчак чәчәкләрдән генә торган аланым җиләкле аланга әйләнеп куймасынмы! Аһ! иттем. Иптәшләремне чакыра башладым. Ышанмадылар. Кояш артык кыздырды, ахры, әкияттә генә агачлар, чәчәкләр кеше белән сөйләшә, дип елмаеп куйдым. Җырлый-җырлый җиләк җыя башладым. Киткәндә бик ямансу булды, ачуланмагыз инде, рәхмәт сезгә, дип иптәшләрем артыннан йөгердем. Килеп җитсәм, кая җиләкләрегез? дим. Үземнекеннән өлеш чыгармакчы булам. Ә җиләкләрем: «Ышанмадылар бит, ышанмадылар», — дип пышылдадылар. Янә елмайдым. Янәсе — әкият! Ә бу могҗизаның башы гына булган икән.

Өйгә кайткач, кояшта кызган гәүдәм, бераз ял итеп алыйм, дигәндәй, кәнәфигә юнәлде.

Шулай утырам кәнәфидә. Мөлаем йөзле, нурлы карашлы бер кеше кулына ике балык тотып өйгә керә. Нинди зур балыклар, авырдыр бит, дим. Балыкны миңа суза бу, буе — безнең бүлмә кадәр, үзе авыр да түгел. Балыклар күбәя башлады. Бүлмә тулы балык. Уянып киттем. Әллә ниләр керә инде төшкә, дим. Ләкин шул көннән башлап җиләккә, гөмбәгә барсак та, иелүдән башымның авыртмавына сәерсендем. Җиткән икән минем дә сәламәтләнәсе көннәр, дим! Арыдым бит инде анальгин ашап. Кан басымы 200дән артып китә иде. Хәзер инде, мин әллә элек авырмадым да микән, дип аптырый башладым. Шулай көн артыннан көн узды. Ял вакыты булса да, табель тутырырга дип училищега чакырдылар. Хезмәттәшем дә әйткән иде, экстрасенс килә, дип. «Юк!» — дидем катгый гына. Хәтта өстәп куйдым: «Туйган ул шарлатаннардан!»

Кинәт башым үзеннән-үзе бүлмәнең телефон аппараты урнашкан өстәл артындагы кешегә таба борылды. Кая күрдем соң бу кешене? Кинәт башка сукты: теге балык биргән кеше түгелме соң бу? Әйе, шул үзе бит!

Һәм мин, кырыс кына, юк, дип әйтүче, шундук урындык алып, үземнең эш эшләргә килүемне дә онытып, Актлар залына кереп киткәнмен.

Сеанс тәмамланды. Чыккач, Рафикъ абыйга рәхмәт әйтеп, өйгә киттек. Рафикъ абыйның йөзе гел күз алдында. Күргән төш белән бу училищеда очрашу очраклы гына түгел, дип уйлыйм. Без җиләк җыйганда Рафикъ абыйның Наҗия апа белән бергә безнең якларда сеанслар биреп йөргән чагы булган һәм Рафикъ абый миңа читтән торып ярдәм иткән. Бер белмәгән-күрмәгән кешегә! Һәм бүгенгесе көнгә хәтле минем дару капканым юк, Аллага шөкер

Мөлаем йөзле, тыйнак, үтә гадел, шәфкатьле, сабыр, юморга бай — Рафикъ абый бүгенгесе көндә зур көчкә ия. Аллаһы Тәгаләбез биргән зур түземлек һәм сабырлык белән ул кешеләрдә мәрхәмәт, әдәп, тыйнаклык, вәгъдәңдә тору, гаделлек, тырышлык, татулык кебек сыйфатлар тәрбияли. Шуның ярдәмендә гасырлар буена җыелган, Җир-анабызны инде һәлакәткә китереп җиткергән явызлык, кан коюю, тупаслык, саранлык, көнчелек, хыянәт, икейөзлелек һәм башка бик күп яман сыйфатларны кеше үзендә бетерү дәрәҗәсенә ирешкәч кенә кешелекне

саклап калып булыр.

Мин үземне бик бәхетле кеше дип исәплим. Үзем укытучы булсам да, безгә тормыш сабакларын төшендерүче, безне һәр эшебезне уйлап эшләргә өйрәтүче Укытучым Рафикъ абый алдында баш иям. Табигать ничек кенә матур булса да, оҗмах дигәннәре туялмый һәм тагын да күбрәккә омтылып, башкаларны уздыру бәйгесендә беренчелекне бирмәскә дип чаба да чаба. Ә бәлки ул чабудан туктап, упкын читенә килеп җиткәнеңне аңлап, үткән тормышыңа борылып карап, нәтиҗә ясарга да кирәктер?!

Балалар өчен яшибез инде, дибез. Бу кечкенә җөмлә бик олы мәгънәгә ия. Баласын ашатып-эчертеп, өстен-башын карап, тормышында матди ярдәм күрсәтү дип кенә аңлый күп кеше моны. Балаларың өчен яшәү ул — үз гөнаһларыңны, нәзерләреңне аларга калдырып китмәү, дигән сүз. Шул чакта гына дөньяга сәламәт балалар туар, авырулар саны көннән-көн азаер. Кеше гәүдәсен каплап торган кара бозыклык (нәселдән килгән) юкка чыгар.

Һәр эшләгән эшеңә, көн тәмамланганда анализ ясап, Аллаһы Тәгаләнең барын да күреп торуын күп тапкырлар, аңлатып бетермәслек дәрәҗәдә соклангычрак. Аны сүз белән генә аңлатып бетереп булмый. Хәер, без Җирдәге табигатькә дә күңел күзе белән карый белмибез. Агачлар сындырудан сыкрыйлар, җәнлекләр ату тавышын ишеткәч үксеп җылыйлар. Ә кешеләр күзләре йомык хәлдә җимерәләр, ваталар, үтерәләр, таркалашалар, чөнки аларда нәфес, көнчелек, явызлык өстенлек итә. Ул ялгышларны кабатлый-кабатлый кеше тома сукыр, саңгырауга әйләнә бара. Үз күзлегеннән, үз каланчасыннан гына бәяләп яңа келәмгә, яңа дачага, машинага, дәрәҗәгә сөенеп онытмыйча, гөнаһлы эшләр эшләүдән куркып-тыелып яшәү ул — балалар хакына яшәү. Үзем әби-бабаларыма, әти-әниемә чиксез рәхмәтлемен, чөнки Рафикъ абый читтән торып ярдәм күрсәткәч, организмымда төзәлү процессы 40 кына көн барды. Бу әле үзең ничек яшәсәң дә ярый, дигән сүз түгел, чөнки үзең инде балаларыңның, хәтта оныкларыңның киләчәген әзерлисең. Менә шундый, беренче карашка бик гади генә тәрбия эшләрен Рафикъ абый сеанс саен дәвам итә.

Үзем күргән космик дөньяны якыннанрак тасвирлыйсым килә. Сеанс вакытында без Рафикъ абыйның зал тулы ак бабайлар белән бергә Аллаһы Тәгалә рөхсәте белән чиксез күп операция башкаруын карап утырабыз. Ул минутларда аның ни эшләгәнен күреп, кеше хәтта аңын югалтырга мөмкин. Рафикъ абыйга көч исәпсез килеп тора. Һәр кеше янында — бабайлар. Берәү янында — 2, икенчесе янында — 5, өченчесе янында — 10... Алар авыр-авыр операцияләрне Рафикъ абый кушу белән башлыйлар. Һәм, бер минут та үтми, сәхнәдә басып торган, корсет кигән, сколиоз, кифоз белән чыккан авыруларның, хәтта урынымда карап кына утырабыз бит дигән кешеләрнең дә умыртка баганалары турая... сырхау бер авыртусыз, тиз, җәйсез сәламәтләнә. Нинди бәхетле мизгелләр! Кеше күзләрендә рәхмәтле күз яшьләре чагыла. Рафикъ абыйның күзеннән тәгәрәп төшкән яшь бөртекләрен бары без — үтәли күрүче ярдәмче кызлар гына күрәбез. Һәм Рафикъ абыебыз белән бергә күз яшьле шатлык мизгелләре кичерәбез. Рафикъ абыйга ике яклап микрофоннан сораулар бирәләр. Күпме сорау! Ничек түзә икән, дисең кайвакыт. Бит сорау артында кеше язмышы, ә ул кеше тагы туганнарын, якыннарын уйлап утырса, бер сорау эчендә мең сорау барлыкка килә. Һәм Рафикъ абыебыз белән бабайлар үз эшләрен дәвам итәләр. Кемдер үзен космоска менгезүләрен сорый. «Шунда менәсем килә», — ди ул Рафикъ абыйга. Рафикъ абый елмая. Ә без, ярдәмчеләре, җавап бирәбез: «Юлны яптылар». «Ни өчен?» — дип аптырый халык. Ничек инде? Ә кылган гөнаһлар, үтәлмәгән нәзерләр кая китсен? Гафу үтенергә кирәк. Ә юк, гафу ку

ктәгеләр тарафыннан җиңел генә кабул ителми. Шулчак Рафикъ абый, үзенә бирелгән көчтән файдаланып, кешене авыр хәлдә калдырмаска тырыша. Ул аңа аш уздырырга куша. Ләкин аш кабул булсын өчен таләпләрне онытмаска кирәклеген искәртә. Дин әһелләреннән дә Коръәнне дөрес, чиста күңел белән уку сорала; ашта утыручылар сүз йөртмәсен, зарланмасын, уфтанмасын. (Ничек инде моңарчы әчеп, кеше кыерсытып, малга табынып йөргән мулла-абыстайлар ашны күктәгеләр таләп иткәнчә җиренә җиткерә алсын!) Ә инде аш вакытында кеше турында гайбәт сөйләү — зур гөнаһ. Кешенең чын күңеленнән өзерләнгән ашын юкка чыгару була

табиб

бит бу. Димәк, уйланырга кирәк: кемне һәм ничә кешене чакырырга?

Менә тагын бер үтенеч. Һәм Рафикъ абый авыруны бина өстендәге аппаратка тапшыра. Кеше үзен очып йөргәндәй хис итә башлый, аны Рафикъ абый тиеш дип санаган вакыт эчендә операция ясап кире кайтаралар. Авыру елмая, берни булмагандай торып китә, авыртуны сизми, хәттә биеп күрсәтә. Могҗиза! Әйе, Рафикъ абый — могҗиза иясе. Сораулар агыла да агыла. Берәү дә җавапсыз, җылы карашсыз калмый. Ә күңеле белән чистарак кешеләр үзләренең дә эш башкаруларын тоя башлый. Тәннәрендә авырткан җирләре кузгалып китә. Менә бер хатын-кыз кычкырып-кычкырып гафу үтенә. Әйе, гафу үтенә, Аллаһы Тәгаләдән, Рафикъ абыйдан, ак бабайлардан гафу үтенмичә авыртулар кимеми. Гаебеңне тану сәламәтләнү процессын бик күпкә тизләтә.

Сораулар чиксез. Шул сораулар аша Рафикъ абый, инде күзләрегезне йомыгыз, уйларыгызны юкка чыгарыгыз, дип әйтә. Залда кинәт тынлык урнаша. Һәркем чәчләреннән шпилька, кулдан сәгатьләрен салып, аяк-кулларын кушмыйча сихри галәмгә юнәлә.

Инде үземнең дә галәмгә күчүемне тасвирлап китәм. Рафикъ абый күзләрне йомдырырга, гәүдә бер хәрәкәт кичереп ала да (физик тән кешеләргә югалган булып күренми), бер тышча кебек утырып кала, ә чынлыкта гәүдә (астраль тән) күккә күтәрелә башлый.

Елгалар, таулар... Менә бер илаһи көч алып менә. Ак, зәңгәр, җирдә без күреп бетерә алмаган һәр төс төрле төсмерләргә керә башлый. Күк йөзе җиде генә кат түгел, чиксез.

Менгән саен фәрештәләр, ак бабайлар төрле бүлмәләргә керергә рөхсәт итәләр. Бүлмә чиста, нурлы, төсләрне безнең буяулар белән генә биреп бетереп тә булмый. Нинди генә төс булмасын, ул нур чәчеп тора. Күбрәк ак, сары, зәңгәрсу, яшел төсләр. Алар ак — чисталык, сары — җылылык, тынычлык, яшнәү — яшәрү төсләре.

Ак бабайларга уй белән генә рәхмәт әйтәсең. Рәхмәт үзеннән-үзе агыла. Әйткән саен әйтеп торасы килә.

Рәхмәт әйткән саен икенче ишек буйлап үтәсең. Нинди генә агачлар, нинди генә җәнлекләр, нинди генә кошлар юк анда!

Яңадан ак бүлмәгә керәсең, анда утырталар, булган авыруларыңны әкрен генә сыпырып куялар да, син җиңеллек тоеп уянып китәсең. Әгъзаларыңны сөт кебек куе суда юдырып алалар. Һәм кире урнаштырып куялар. Рәхмәт әйтүгә, терраса кебек җирдән чәчкәле бүлмәгә күчәп, өстәлдәге ризыкларга карыйсың. Нинди генә . җимешләр юк!.. Аны тотып карасаң да тамак туяр кебек...

Менә шулай ишек саен яңа ачыш. Һәм ул — чиксез кебек. Берсе дә бер-берсен кабатламый, яңалык өстәлә бара. Җәннәт шул инде ул, дип әйтәсем килә минем.

Җәһәннәм... Бу сүзне ишетүгә тәннәр чымырдап китә. Әйе, әйе, шулай бер сеанста утырганда ниндидер ачыргаланып кычкырган, ыңгырашкан тавышлар ишетелә. Нәрсә булыр бу, дип, китәм тавыш килгән якка.

Иксез-чиксез упкын. Бер яктан икенче якка сузылган күктә асылынып торган кыяфәттә кешеләр хәрәкәт итә. Мин дә киттем. Шулчак алдагы кешенең югалуы мине бик нык тетрәндерде. «Юк, юк, теләмим, ярдәм итегез!» дип кычкырам. Шулчак кул барлыкка килде. Кем? Рафикъ абый кулы йолып алды мине үлем тырнагыннан һәм шулай ук җәһәннәм газабыннан коткарды.

Кара көчләр... Кара көчләр турында балачакта әкияттә генә ишеткән бар иде. Ә бүген аларның чыннан да булуы бернинди дә шик уятмый.

Ничек итеп күрдем мин аларны? Утырабыз шулай сеанста. Бер хатын микрофоннан сорау бирә. Рафикъ абый: «Карагыз әле, кызлар, кем бар анда?» — ди. Шулчак әлеге хатын-кызның муеныннан эләктереп тоткан, җанварга да, ир кешегә дә охшаш албасты басып тора. Ул хатынны артка таба өстери. Шулчак артка карап куйдым (микрофон артта иде). Микрофонга чиратта тагын бер хатын-кыз басып тора. Әллә ялгыш күрәмме, дип, кабат алга карыйм: теге адәми-җанвар китә башлады. Бу — Рафикъ абый эшли башлады, дигән сүз. Коточкыч күренеш. Җанвар китәргә теләми. Ләкин Рафикъ абыйга бер кара көч тә каршы тора алмый.

Кара көчләрнең мөмкинлекләре дә, затлары да бик күп төрле. Бер карыйсың — алар кеше кебек, икенче карыйсың — җәнлек кыяфәтендә. Шул ук җанвар матур чәчкәгә әверелеп тә алдалый ала. Ихтыяр көче нык булмаган кешене алар шундук үзенә буйсындыра. Тулы бер төркемгә дә әйләнүләре мөмкин, чөнки алар җирдәге барлык җаннар кебек үрчиләр. Эчкечелек белән мавыккан, тәмәкесеннән, начар гадәтләреннән арына алмаган кешеләрдә алар бик күп төрле. Кара көчләр кешене аулап ала һәм аның белән турыдан-туры идарә итә башлый. Әгәр дә алар фәкать үз теләкләре белән сеанска килеп йә китап аша Рафикъ абый әйткән һәр сүзгә игътибар белән гафу сорап утырсалар, гаепләрен танысалар, Рафикъ абый аларның ихтыяр көчләрен ныгыта ала. Кара көчләр хәтта күкнең 12 нче катында да була.

Рафикъ Миңнекәев феноменын фән кешесе ничек аңлата?

Язучы Саимә ИБРАҺИМОВА халык табибы Р.Миңнекәевнең савыктыру сеансларына йөргән биология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт медицина университетының фәнни хезмәткәре Е.Щеглова белән әңгәмә үткәрде.

— Елена Геннадьевна, халыкара «Планетаны яңарту» ассоциациясе вице-президенты, халык табибы Рафикъ Миңнекәевнең эшләгән эшен, фәнни күзлектән чыгып караганда, Сез ничек аңлатыр идегез?

— Алган белемемнән чыгып, кайбер нәрсәләргә шактый объектив бәя бирә аламдыр, дип уйлыйм.

Беренчедән, мин умыртка баганасының тураюын, умырткаларның үз урынына урнашуын, күтәрелгән яки төшкән калак сөякләрен үз урынына урнаштыручы мускулларның хәрәкәтен үз күзем белән күрдем.

Икенчедән, шул хәлләрне күзәтеп торучы буларак, рак, бавыр циррозы ише үтә җитди диагнозлар белән килгән кешеләрнең урыннарыннан торып, йә хәлләре җиңеләйгән, яисә бу авырудан бөтенләй арынганнары өчен әледән-әле табибка рәхмәт укуларын өзлексез күзәтеп тордым. Рак яисә шуның ише башка яман авырудан котылдым, дип, кеше кызык өчен генә әйтер иде микән?!

Өченчедән, физик булмасам да, шушы мәсьәләгә кагылышлы әдәбиятны күзәтеп баручы буларак, матдәнең лептон төзелеше ноктаи назарыннан чыгып караганда, Р.Миңнекәев тарафыннан эшләнә торган гамәлләрнең нәтиҗәле булуы бик тә мөмкин хәл. Лептон — тереклекнең иң вак кисәкчәсе. Лептон — дәрәҗәсендә образлар туа. Физиклар бу дөньядан китеп баручы җанның лептон массасының авырлыгын үлчәделәр. Кешенең уй эшчәнлеге тарафыннан тудырылган образның нигезе булып лептон структура тора. Шартлы рәвештә лептоннарны уңайга һәм кирегә бүләләр. Кеше начар уйласа, материаль булган уй аша лептон структура «туа». Һәм бу — структураны хасил итә торган шартлы — кире лептон болыт була. Әгәр дә югары энергетикага ия кеше дәвалаучы булса, ул бу очракта кешедә уңай образ тудырып, аның хәлен, кәефен, лептон структурасын (җанын) яхшырта ала. Моның исә кайберәүләр тарафыннан «аура» дип атала торган нәрсә булуы да ихтимал

— Медицина белән Миңнекәевнең үзара хезмәттәшлеге нинди юнәлештә булырга мөмкин? Алар бер-берсенә ничегрәк ярдәм итә алалар?

— Рафикъ әфәнде үзенә Галәм тарафыннан чиксез зур энергетик мөмкинлекләр бирелүе турында сөйли. Эшләгән эшләре чыннан да сүзләреннән аерылмый. Аның әлеге сәләтен нәфис структураларны өйрәнә торган физиклар гына аңлатып бирә ала. Медицина исә, диагнозлары төрле булган бер төркем авыруларны җыеп, Р.Миңнекәев сеансларын алганнан соң, рентгенограмма, УЗИ һәм башка методик мәгълүматлар ярдәмендә, табибның аларга клиник тәэсирен өйрәнә ала.

Күрәсең, Рафикъ Миңнекәев уй ярдәмендә организм һәм әгъза дәрәҗәсеннән хромосома, ген, молекула дәрәҗәсенә кадәр булган норма, зурлык, структура образын тудыра. Һәрхәлдә, ул үзе шулай ди. Әгәр аңа шулкадәр көчле энергия бирелгән икән, авыруга яисә үзгәргән әгъзага карап ул аның элекке нормаль хәлен яисә хәзергесен күз алдына китерә «күләгәсе» буенча шул лептон структураны төзи яисә яңарта, шул рәвешле, әгъзага яңадан «әйләнеп кайтырга» «яңарырга», күзәнәкләрне яңадан торгызырга нигез бирә ала. Әгәр дә ул лептон дәрәҗәсендә, хәттә тагын да югарырак дәрәҗәдә фикерли яисә аралаша ала икән, бу очракта табиб җитешмәгән әгъзаны барлыкка китерә, аны алыштыра, әгъзаны яисә аның өлешен, мәсәлән, лептон структурасын (ягъни образын) уй белән юкка чыгарып, шешне яисә полипны алып ташлый ала. Калганы инде организм эшетеге яки бу механизм ярдәмендә эшне эшләп бетерү өчен төзәлү вакыты гына кирәк була. Мәсәлән, фагоцитоз мисалында ул менә болай була:

1/. лейкоцитлар (фагоцитлар) организмдагы чит күзәнәкләрне юк итә ала;

2/. шундый ук фагоцитозны койрыклы чукмарбашның койрыксыз бакага әйләнүендә күзәтергә мөмкин. Моны тикшерү — галимнәр эше, әмма иң әһәмиятлесе — принципта бу мөмкин хәл.

Шушындый ук күрсәтмәне бөтен бер залга, күпсанлы кешеләргә бирергә була, һәм организм бөтенләе белән үзенең нормаль лептон структурасына яраклаша, тулысынча дәвалана, ә инде ашыккан яисә вакыт җитмәгән очракта (мәсәлән, рак булганда яки күкрәк баласының үпкәсе ялкынсынганда һ.б.) конкрет әгъзага конкрет күрсәтмә бирергә дә мөмкин.

— Медицина белән бәйләнешле кеше буларак, Сезне аеруча нәрсә шаккатырды?

— Мине барыннан да элек Рафикъ әфәнденең табибларга үз сеансларында катнашырга, аларга үз карамакларына бер төркем авырулар алып, сеанслардан соң аларның диагнозларын расларга тәкъдим итүе гаҗәпкә калдырды.

— Шулай да Рафикъ әфәнде башкарганнарның иң әһәмиятлесе дип нәрсәне саныйсыз?

— Иң әһәмиятлесе, миңа калса, аның кеше җаны, кеше күңеле турында кайгыртуы. Кешенең җаныннан, күңеленнән ул бөтен явызлыкны алып ташларга омтыла. Фәнни телгә күчереп әйткәндә, бу — үзеңнең уең белән кире лептон образлар тудырмаска, ә Рафикъ әфәнде теле белән әйткәндә — гөнаһ эшләмәскә, нәзерләреңне үтәргә, башкаларга явызлык теләмәскә, явызлык эшләп, үзеңнән соң килә торган буыннарны җәзага дучар итмәскә, дигән сүз.

Дөньяда экстрасенслар, ягъни гадәти кагыйдәләргә туры килми торган кешеләрнең булуы һәркемгә дә мәгълүм. Әйберләрне күз карашы яисә уй белән бер урыннан икенче урынга күчерү, үтүкне күкрәккә ябыштырып тоту күренешләре һ.б. күптән инде пленкага язылып, Мәскәү телевидениесеннән күрсәтелде. Бу тәҗрибәләр галимнәр күзәтүе астында үткәрелде. Кеше сөякләре дә — шундый ук әйберләр, аларны да бер урыннан икенче урынга күчерергә мөмкин. Медиклар бу тәҗрибәләрне җентекләп өйрәнсеннәр иде дә, уңай нәтиҗә биргән очракта, аны чынбарлыкны кабул итеп, Р.Миңнекәевкә сәламәтләндерү үзәге булдырырга фатиха бирсеннәр иде.

Фәнис ЯРУЛЛИН

Ни кирәк сиңа, алкаш?

(Бер пәрдәлек комедия)

Катнашалар:

Сатучы кыз — Сары чәч.
Сатучы кыз — Кара чәч.
Ир кеше.
Әхмәт Имаевич — кибет директоры.

Артык зур булмаган ашамлыклар кибете. Пәрдә ачылганда ике сатучы кыз берсеннән-берсе уздырып сагыз чәйни.

Сары чәч. Гуля, Гулечка! Знаешь, кичә, когда эштән кайтып барам, артымнан берәү килеп остановился?

Кара чәч. Потом, потом? Нindирәк типчик иде?

Сары чәч. О-о, пальчики оближешь, шәп экземпляр!

Кара чәч. Говори, говори: комплектациясе нindирәк? Буе озынмы?

Сары чәч. Озын? Биш метр бардыр.

Кара чәч. Ты что, Сонечка, биш метрлы кеше буламыни?

Сары чәч. Ә кем сиңа әйтте, биш метрлы кеше, дип. Мин бит, машинасы биш метрлы, дидем.

Кара чәч. Ә күзләре нинди төстә иде?

Сары чәч. По-моему, зәңгәр. Короче, машинасы зәңгәр иде, значит күзләре дә зәңгәр булгандыр. Андыйлар бит үзләренең күзләренә карап покупают машинаны.

Кара чәч. Везет сиңа, Сонечка. Биш метрлы машина диген, ә?

Сары чәч. Эчендә рәхәтләнеп сузылып ятарлык.

Кара чәч. Ә миңа разный халявчиклар гына очрый. Беркөн шулай, зәңгәр төтеннәр таратып, бер паршивый «Запорожец» килеп туктады. Утырыгыз, подвезу, диган була. Үзенә дә кирәген әйттем.

Сары чәч. Ну, ну, говори, нәстә әйттең?

Кара чәч. Синең инвалид бабаңнан калган драндулетыңа утырганчы, лучше мин ишәккә утырам, дип әйттем.

Сары чәч. Здорово әйткәнсең, молодец.

Кара чәч. Язык бар ул бездә. Не купленный.

Сары чәч. Нәрсә белән бетте соң бу приключениеләрегез?

Кара чәч. Нәрсә белән дип. Авызын ерып торган була. Имеш, «Запорожец» хәзер импортный машина. Кара әле, Сонечка, нишләп ул алай әйтте икән?

Сары чәч. А черт его знает.

Кара чәч. Әллә «Запорожец»лар Америкада чыга микән алар?

Сары чәч. Все возможно.

Кара чәч. Если это так, то напрасно утырмаганмын. Еще мин аңа, ишәкләр дә импортный хәзер, дидем.

Сары чәч. Ә үзе нindирәк иде соң?

Кара чәч. Машинасы шундый булгач, үзен кем караган инде аның.

Сары чәч. Ладно, кайгырма, Гулечка. Мин белешермен әле ул «Запорожец»ларның кайда чыкканын. Әзенә төшәрбез.(*Көлешәләр*).

Кибеткә 35-40 яшьләр тирәсендәге бер ир кеше керә. Аның киемнәре гади: ак күлмәк, соры чалбар. Киеменә карап кына кем икәнлеген белерлек түгел.

Ир. Исәннәрмесез, кызлар!

Сары чәч. Исән булмасак, доктор түгелдерсең бит?

Ир. Доктор түгел-түгелен, тик сәлам биреп керү әби-бабалардан калган гадәт бит.

Кара чәч. Сәламеңне әбиеңә әйт алайса.

Кызлар бер-берсенә карашып, ярыштан сагыз чәйнәргә тотыналар. Ир кибеттәге әйберләрне караштырып йөри.

Кара чәч. Соня, ә, Сонечка. Теге биш метрлы иномаркаң турында сөйли башлаган идең бит. Ничегрәк бетте?

Сары чәч. Дөнья күрмәгән кебек сорашып торасың. Шул ше кебек сорашып торасың. Шул инде ул: өстән тоталар, астан йоталар.

Кара чәч. Яңадан очрашырга сөйләштегезме соң?

Сары чәч. А как же?! Хатыным бар минем, дип крутиться итә башлаган иде, это меня не касается, зато минем ирем юк, дип тиз генә артына утырттым мин аны.

Кара чәч. Син каптырсаң, лимон урынына сыкмыйча ычкындырмыйсың инде анысы.

Сары чәч. Опыт кирәк, хитрость. Шунсыз яшәп булмый хәзер.

Ир кеше тамак кырып куя.

Ир. Кызлар-туташлар. Бәлки сүзегезне өегезгә кайткач сөйләшергә калдырырсыз. Ялгышмасам, бу бит кибет, ә сез эш урыныгызда.

Сары чәч. Сиңа нәрсә кирәк соң, алкаш? Бездә бит аракы сатмыйлар, бәбәкләреңне ачыбрак кара. Бу — ипи кибете.

Ир. Бәлки, миңа ипи кирәктер.

Кара чәч. Алайса, нигә монда багана кургән милиция сыман акаеп торасың, ал ипиеңне.

Ир. Ипиегез бик каткан икән.

Сары чәч. Тешләрең атныкы кебек күренә әле, кимерерсең. Катысы озаккарак җитәр.

Көлешәләр.

Ир. Ну и лексикон сездә!

Сары чәч. Лекция сөйләгән кеше юк әле сиңа, аңгыра баш.

Ир. Сагыз чәйнәү дә кибетегезнең атрибутикасына керәме?

Кара чәч. Кешенең арт ботинкасын тикшермә. Үзеңнең арт ботинкаңны кара.

Ир кеше боларның аңгыралыгын сизеп, мыек астыннан елмаеп куя.

Ир. Күренеп тора: кибетегезгә әйбәт имидж тудырасыз сез.

Сары чәч. Ха-ха, кибет имие! Кибеткә аңа ими кирәкми. Ул үзебездә дә Аллага шөкер. (*Күкрәген киерә. Кара чәч тә аның кыланышын кабатлый*).

Ир. Бик кызык булып китте әле сезнең белән, кызлар.

Кара чәч. Безнең белән бөтен кешегә дә кызык. Тик синең белән безгә кызык түгел.

Сары чәч. Что надо — бери һәм тай отсюда.

Ир. Мин менә сезнең кайсыгызны алырга дип тора идем, нишләргә икән соң инде?

Кызлар авызларыннан сагызларын тартып чыгара-чыгара көләләр.

Кара чәч. Безгә үрелергә буең кыскарак шул.

Ир. Сезгә ничә метрлы буй кирәк соң?

Сары чәч. Миллионлысы.

Ир. Ничек миллионлысы?

Кара чәч. Ничек, ничек? Бездә буйны миллион белән исәплиләр.

Ир (*аңламыйча*). Нинди миллион?

Сары чәч. Әллә син берәр карурманнан килдеңме? Нинди миллион булсын — миллион доллар!

Кара чәч. Да, абзый пелөшевич, бармы миллион долларың?

Ир. О-о, бөягез шундый кыйммәтмени?

Сары чәч. А как ты думал? Безне әллә үзегезнең авыл кызы дип белдеңме?

Ир. Юк, алай димәдем. Безнең авылда сезнең кебек кызлар юк.

Кара чәч. Безнең кебек кызлар беркайда да юк.

Сары чәч. Артык биек үрелсәң, чалбар төбәң ертылыр.

Үзләренең сүзләреннән тәгәрәшеп көләләр.

Ир. Кызык, кызык. Минем кем икәнне дә әллә каян белдегез. Үземә бер менеджер итеп алырга инде әллә сезне?

Сары чәч. Катись отсюда, абзый пелөшевич. Әкиятләреңне кайтып әбиеңә сөйлә.

Кара чәч. Образаулый булып, күзгә төтен җибәрергә тырыша ул.

Сары чәч. Без синең болай да кем икәнеңне насквозь күреп торабыз.

Ир. Алай-алай. Кем соң мин?

Кара чәч. Акылын сыер ялаган бер нәрсәдер. Кем булсын тагын!

Сары чәч. По-моему, син эчүен ташлаган алкаш.

Ир. Кызык-кызык. Нәрсәдән чыгып болай әйтә аласыз?

Сары чәч. Эчүен ташлаган алкашлар гына шулай бөтен нәрсәгә бәйләнүчән була.

Ир. Мин беркемгә дә бәйләнмәдем шикелле әле.

Сары чәч. Ипиегез каты дип, бәйләнүеңне онытттыңмени? Ул ипине өч көн сатабыз инде, беркемнең дә каты дигәне юк иде әле.

Кара чәч. Соня, Сонечка, минемчә, бу типның кесәсендә ике бакыр тиене дә юк. Психушкадан кумылган мәхлук бу. Точно, шулай.

Сары чәч. Юк, Гулечка, бу кимереп ыргытылган сөяк.

Ир. Бик шаян кызлар икәнсез.

Сары чәч. (*Кул селтәп*). Туйдыра башладың. Тай әле моннан.

Кара чәч. Бар, бар, бывший алкаш. Кирәгеңне ал да, сыпырт.

Ир. Хәзер-хәзер. (*Торт янына килә, кайчан чыкканын карый*).Бу тортны алырмын диган идем. Вакыты чыккан икән.

Сары чәч. (*Түземсезләнеп*). Ошамаса — алма. Эт корсагына сары май килешми, ди.

Ир. (*Аның тупаслыгын ишетмәмешкә салышып*). Печеньегыз да бик уалып беткән икән.

Кара чәч. Чәйнәп торасы булмас. Мөгаен, хатыныңның теше юктыр әле. Рәхмәт әйтер үзеңә.

Ир. Йә, ярый, кибет эчендәге бар нәрсәне төреп бирегез алайса. Һәммәсен алам.

Сары чәч (*ахирәтенә*). Милициягә, йә психбольницага озатырга кирәк моны. (*Телефонга барып ябыша*). Алло, алло! Милицияме бу?

Ир кеше телефонның рычагын баса.

Ир. Туктагыз әле, тукта. Милиция белән шаярудан да курыкмыйсыз. Минем белән дә кайчаннан бирле шаярасыз.

Кара чәч. И-и, әйттерерсең әллә ни. Синең белән шаярып торырга безне әллә надан деревенщина дип белдеңме?

Ир. Ә-ә, сезнең чынлап сөйләшүегез шулаймыни?

Кара чәч. Бар, бар. Синдәйләрнең алдыннан арты матур. (*Ирне төрткәләп диярлек чыгара башлыйлар. Шулвакыт ишектә кибет директоры Әхмәт Имаевич пәйда була. Кызлар бер-берләрен бүлдерә-бүлдерә зарланырга тотыналар*).

Сары чәч. Әхмәт Имаевич, менә бу кимерелгән сөяк...

Кара чәч. Бывший алкаш...

Сары чәч. Сарсыган импотент...

Кара чәч. Нахал, хулиган...

Әхмәт Имаевич. Туктагыз әле, кызлар, туктагыз. Сез нәрсә сөйлисез?

Сары чәч. Ул бит безне оскорблять итте.

Елаган булалар, күзләрен сөртәләр.

Әхмәт Имаевич. Ничек оскорблять итте?

Кара чәч (*еламсырап*). Ипиегез каткан, печеньегыз уалган, дигән була, хәерче.

Сары чәч. Кайсыгызны алыйм икән, дип издеваться итә еще.

Кара чәч. Бөтен кибетегезне төреп бирегез, ди, сасы танау.

Әхмәт Имаевич. Туктагыз әле, кызлар. Ул бит дөресен әйткән (*ипине тотып карый*). Ипиегез чынлап та таштай каты.

Сары чәч. Соң, Әхмәт Имаевич, искергәнен сатып бетермичә яңасын чыгармагыз , дип үзегез әйттегез бит.

Әхмәт Имаевич (*теге ирга карап*). Күрәм, Сираҗи әфәнде, сез безнең кызлар белән танышып та өлгергәнсез.

Сираҗи әфәнде. Әйе, кайсын алырга икән дип баш ватасы булмады. Кибеткә сездән алдан керүем ярап куйды.

Әхмәт Имаевич. Менә, кызлар, бу безнең, ягъни менә бу кибетнең яңа хуҗасы Сираҗи әфәнде булыр. Таныш булыгыз.

Кызлар. Яңа хуҗа? Ничек? Ә сез?

Әхмәт Имаевич (*көрсенеп*). Заманалар үзгәрде. Так что, менә сезнең яңа хуҗагыз. Аның белән уртак тел таба алсагыз...

Кызлар берсен-берсе бүлдереп.

Сары чәч. Мин берни дә аңламыйм.

Кара чәч. Мин дә.

Әхмәт Имаевич. Нәрсәсен аңламыйсыз? Кибет кичә аукционда сатылды. 500 миллионга, мине Сираҗи әфәнде сатып алды. Мин киттем.

Сары чәч. Мине дә алыгыз үзегез белән.

Кара чәч. Мине дә, Әхмәт Имаевич.

Әхмәт Имаевич. Алыр идем дә, Гөлчирә апагыз кабул итмәс шул. Мин бит пенсиягә киттем.

Чыгып китә. Кызлар тәгәри-тәгәри үкерешеп калалар. Бераздан сикерешеп торып чәчләрен-күзләрен рәтләштерәләр.

Сары чәч. Сираҗи әфәнде. Сезгә кофе яки лимонлы чәй китеримме?

Кара чәч. Бәлки бер-ике йотым коньяктан авыз итәрсез, ә? Француз коньягы. Бик кадерле кунакларга гына тотабыз. (*Берсе чәй, берсе коньяк чыгарып утырта. Кулларына күз дә иярми. Сагызларын да Сираҗи күрмәгәндә авызларыннан алып ташлыйлар*).

Сираҗи. Мәшәкатьләнмәгез, кызлар, мин коньяк эчмим. Кофе дә.

Сары чәч. Алайса шампанский ачам.

Сираҗи. Юк, юк, берни дә кирәкми. Минем вакытым юк. Мин хәзер китәм.

Кызлар. Ә без?

Сираҗи. Сезгә иртәгә расчет бирерләр.

Сары чәч. Сираҗи әфәнде, без бит бая шаярдык кына. Егет кешә аны гына аңларга тиеш.

Кара чәч. Әйе, сезне без бер күрүдә ошаттык-та, бераз шаяртып алырга булдык.

Сираҗи әфәнде. Алай шаяра торган һөнәрегез булгач, бүтән берәр җирдә шаярып тамак туйдырырсыз. Циркта мы, башка җирдәме...

Сары чәч. (*Сираҗига сырпаланып*). Сиразчик. Алай бик кызып эш итмик әле. Син бит егет кеше.

Кара чәч. Егетнең дә сөлеге.

Сары чәч. Ә егетләр белән кызлар һәрвакыт уртак тел таба ала.

Кара чәч. Чынлап та шулай бит, Сиразчик?

Сираҗига икесе ике ягына килеп сарылалар.

Сары чәч. Аппагым минем (*сыйпый*).

Кара чәч. Йомшагым минем(*сыйпый*).

Сары чәч. Зобәрҗәтем-асылым. (*Үбә*).

Кара чәч. Кыядагы лачыным. (Үбә).

Сираҗи әфәнде (*кызларның икесен ике якка селтәп ташлый*). Җитте. Әнә ишек. Тизрәк таегыз. Юкса күңелне болгата башладыгыз.

Кызлар эшнең тозәлмәслеген аңлагач, ташлаган сагызларын яңадан алып кабалар. Һәм бөерләренә таянып Сираҗи тирәсендә әйләнәләр.

Сары чәч. Кибетеңне башыңа капла. Без югалмабыз.

Кара чәч. Россиядә яшәр өчен баш кирәкми. Бигрәк тә безнең кебек сортлы алмаларга. Гуд бай!

Чыгып китәләр.

Сираҗи әфәнде. Сортлы алмалар түгел сез, кортлы алмалар.

Тәмам.

10 июль, 1995 ел.

ИҖАТЧЫ ЯКЛАУГА МОХТАҖ

Чын сәнгать химаясез яши алмый

Иҗат. Нәрсә соң ул? Йокысыз төннәр бәрабәренә өстәлдә оелеп калган кулъязмалармы, чынга ашмаган проектлармы, тузан җыеп ятучы сәнгать әсәрләреме? Әллә инде аларны дөньяга чыгару өчен акча юллап, химаячеләр эзләп узган чакльармы?..

Әңгәмәдәшебез — Татарстан Республикасының театр әһелләре берлеге рәисе урынбасары Ирна Хафиз кызы ГАТОВА.

— Театр әһелләре берлегенең хәле ничек? — дисез алайса, — дип Ирна ханым соравымны кабатлагандай итте. Бу минутларда ул кистереп кенә, әйбәт тә, юк та, дип әйтергә кыймый иде кебек. Шуңа күрә сүзен ерак үткәннән урап башлыйсы итте.

— Русиядә театр әһелләре җәмгыяте моннан 130 ел элек химаячеләрнең матди ярдәме белән оеша. Аларның беренчел максаты актерларга иҗатларында һәм көндәлек тормышларында булышлык күрсәтү була. Еллар узу белән, бу җәмгыятькә терәк булып театр кирәк-яраклары эшләп чыгаручы фабрикалар ачыла. Мәгълүм булганча, театр әһелләре җәмгыяте эшчәнлегендә аларның матди ярдәме зур була. Казанда мондый оешма 1938 елда Русия театр әһелләре җәмгыятенең Татарстан бүлеге буларак төзелә. Әгәр аның елъязмасына күз төшерсәк, без анда байтак матур хатирәләр, күренекле актерлар, әлеге җәмгыятьнең тормышын күркәм итә алган байтак җитәкчеләр белән очрашыр идек. Бүлекчә эшен оештыруда В.Качалов исемендәге театр актеры Д.Любин башлап йөри. Татарстанда әлеге җәмгыятьнең беренче рәисе итеп күренекле актерыбыз Хәлил ага Әбҗәлилов сайлана. Аңардан соң эшләгән рәисләр дә театр күгендә якты йолдыз булып кабынган артистлар. Һәм аларның һәркайсы үз эшчәнлеген җәмәгать тәртибендә, ягъни хезмәт хакы алмыйча башкарды.

Белгәнегезчә, ун ел элек әлеге җәмгыять театр әһелләре берлеге итеп үзгәртелде. Хәзер ул үз сафына 570 кешене берләштерә. Монда актерлар да, театрда эшләүче рәссамнар да, андагы җитәкчеләр дә бар. Берлеккә күренекле актерыбыз Ринат Таҗетдинов җитәкчелек итә.

— Ни дисәк тә, аларга берлек канаты астында иҗат итү җиңелдер. Кинотеатрлар бушап калган бервакытта, театр заллары шыгрым тулы. Тамашачы бар, димәк, актерларыбызның да күңеле тыныч...

— Куанычларыбыз да бар. Актерларыбыз, театрларыбыз Бөтенрусия күләмендә уздырылып килгән дәрәҗәле фестивальләрдә катнашып, югары бәя алалар. Үзләре генә булсалар, алар андый бәйгеләрдә катнаша алыр идеме икән?

Хәзергә чаклы Татарстан театр әһелләре берлеген матди яктан үзәк тәэмин итеп килде. Фестивальләрне, үзара иҗади очрашуларны да без үзәк белән бергәләп үткәрә килдек.

Тамашачыларыбызның актив булуы да безнең өчен шатлык, әлбәттә. Кызганыч ки, ул шатлыклар зур чыгымнар, актерларыбызның олы хезмәте бәрабәренә килә. Билет бәяләре шулкадәр түбән, ул спектакльне сәхнәгә чыгаруга тотылган чыгымнарның бик аз өлешен капларга гына җитә. Ә бәяләр һаман үзгәреп тора бит. Айлар дәвамында эш хакы алмаучы, түбән хезмәт хакына эшләүче кешеләребез тамаша залына ничек керерләр?! Безне бу да нык борчый.

— Әйе, базар шартларында яшәү беркемгә дә җиңел түгел. Кыен хәлдән чыгу юлын һәркем үзенчә эзли. Театр әһелләре берлегендә дә кул кушырып утырмыйлардыр, дип беләбез...

— Сүз дә юк, җиңел, димәс идек. Элек, хәтта патша заманында да, җәмәгать оешмаларыннан салым түләтмәгәннәр. Әгъзалар кесәсеннән кергән, йә булмаса, химаячеләр биргән акчадан салым тотып каласыңмыни?! Ә без икеләтә, өчләтә салымга дучар ителгәнбез. Инде быелның июлендә Татарстан Министрлар Кабинеты иҗат берлекләре һәм җәмгыятьләре белән бәйле 431 нче санлы карар кабул иткәч, эчкә бераз җылы кергән иде. Ләкин ул да тулысынча үтәлми әле. Хөкүмәтебезнең иҗат берлекләренә булган ярдәмен ныграк тоясы иде...

Матди хәлебезне ныгыту өчен безгә коммерция белән дә шогыльләнергә, иҗади очрашу кичәләрен файдалы һәм керемле итеп үткәрү хакында да уйларга туры килә. Берлек урнашкан Актерлар йортын шул максатларда тулырак файдаланырга тырышабыз. Элекке 250 урынлы тамаша залыбыз яңа төсмер алды. Хәзер анда төрле бәйрәм, эшлекле очрашу, кино, концерт карау кичәләрен иркенләп, өстәл артына утырган килеш тә уздырабыз. Ә анда ял итәргә килүче тамашачылар Актерлар йорты кафесында әзерләнгән ризыклардан авыз итә ала. Шул ук вакытта кафеда туган көннәр, туйлар үткәрү матур традициягә әйләнер дип өметләнәбез.

Театр әһелләре берлеге башка иҗат оешмалары белән дә элемтәләрен ныгыта бара. Композиторлар, кинематографистлар белән берлектә үткәрелә торган очрашу, кичәләрне шулай ук һәр ике як өчен дә файдалы дияр идем.

— Актерлар йорты — ул театр эшлеклеләренең фикерләшү, серләшү урыны да бит әле...

— Әйе, берлекнең сайлап куелган идарә әгъзалары бар. Алар — төрле театрларның күренекле, тәҗрибәле актерлары, режиссерлары, җитәкчеләре. Бергә җыелып, без үзебезнең эшчәнлек белән бәйле мәсьәләләрне хәл итәбез. Актерлар йортында театр әһелләре, ветеран актерларыбыз да еш була. Ветераннар советы хәзер 200ләп кешене берләштерә. Күркәм традицияне саклаган хәлдә, берлек актерларыбызга рухи һәм матди ярдәм итәргә тырыша.

— Театр әһелләре берлегендә даими эшләүчеләр үзләре дә ярдәмгә мохтаҗдыр бит...

— Вахтердан башлап җитәкчегә кадәр булган эш хакы соңгы вакытларда 43—270 мең сум тәшкил итте. Бу чыгымнарны тулысы белән Русия театр әһелләре берлеге үз өстенә алып килә.

Ә республикабыздагы берлек әгъзаларыннан җыелган взнослар безнең чыгымнарның 3-5 процентын гына капларга җитә. Актерлар йортын тотуга да үзебез акча табарга тиешбез. Ә бит коммуналь хезмәтләр өчен генә дә аена берничә миллион сум акча түләргә кирәк. Салымнар кулдан тота дип, безгә кул кушырып утырырга һич тә ярамый.

— Шундый кыен шартларда, Ирна ханым, сезне театр берлеге белән нәрсә бәйли икән, дип уйлап куясын...

— Бәлки, сезне актер булмавым гаҗәпләндерәдер. Белгечлегем буенча мин, чыннан да, филолог. Әмма хезмәт юлым мәдәният белән бәйле. Югары уку йортын тәмамлагач та театрда әдәби бүлектә эшләдем, аннары Мәдәният министрлыгында. Гомеремнең 25 елы берлектә үтте. Үземне театрдан, сәнгатьтән башка күз алдына китерә алмыйм. Мондый якынлык, мөгаен, әтиемнән күчкәндер. Ул заманында театрда режиссер, администратор булып эшли. Әтием опера һәм балет театрында эшләгән чакларда безнең өйдә Нәҗип Җиһанов, Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев, Хәлил Әбҗәлилов кебек мәшһүр шәхесләр еш була иде. Аларның да миңа йогынтысы булмый калмагандыр инде.

Сугыш башланып, опера һәм балет театры коллективы таркалгач, әтиемне Актерлар йортының беренче директоры итеп билгеләделәр. Ләкин аңа бу вазифаны озак башкарырга туры килми. Башка сәнгать әһелләре кебек ул да яу кырына китә һәм 44 нче елны шунда ятып кала. Үзенә күрә мин әтием эшен дә дәвам иттерүче әле.

— Ярый ла, сәнгатьне кабул итүче, аңлап яшәүче тормыш иптәшең булса?..

— Актер, сәнгать кешеләренең гаиләләре тамашачыларны еш кызыксындыра шул. Мин әлеге хезмәттә, ә ирем — табиб, ГИДУВ профессоры, фән кешесе булганлыктан, мөгаен, безгә дә сораулы караш ташлаучылар бардыр. Ә мин еш кына иремә сокланып куям. Аның музыка, театр, рәсем сәнгате белән кызыксынуы, бу өлкәдә шактый хәбәрдар булуы таң калдыра. Сәнгать безне тагын да якынайта гына төшә. Шул чагында мин уйлап куям: кеше иң элек рухи яктан бай булсын икән, дим.

— Авыр минутларда кешегә бер җылы сүз дә җитә. Ә берлек кебек оешмага без авырлыкларны җиңеп чыгуын теләр идек.

— Рәхмәт. Без дә икътисади кыенлыклар артта калыр дип өметләнәбез. Актерлар йорты барлык иҗат интеллигенциясенең үзәге булып калыр, берлек яшәвен дәвам итәр...

Әңгәмәне **Фәния САБИРОВА** үткәрде.

Фәрит ЯХИН

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯНЕ

(Дәвамы. Башы гәзитебезнең 15-16 нчы саннарында).

Затына күрә сыйфаты бар дигәннең төшенчәсе бик тирән. Аның мәгънәсе шуннан гыйбарәт. Аллаһы Тәгалә бар! Аның барлыгы үзенә күрә, үз үзенә барлыгы белән аңлатыла. Аның барлыгы башкаларның булуы яки булмавы белән бәйле түгел. ул һичбер заттан да вә һичкемнең теләге белән бар булмады. Аның барлыгында һичкемнең катнашы юк. булырга да мөмкин түгел. Ул шулай ук һичнәрсәне вә һичкемне үзеннән тудырмады. ягъни балалары да, гаиләсе дә юк. Ул тудыру вә тудыртудан саф вә чиста. Юкка чыгуы мөмкин түгел. Аны бетереп, үтереп. түбәнәйтеп кую мөмкин эш түгел. «Иннәәна-Аллаһу!» аятендәгечә. ягъни «Дөреслектә мин Алла. мин — бар!»

Сәлибия сыйфатлары биш. дидек. Алардан беренчесе — **кыйдәм.** Бу Аллаһының яшәве вә барлыгы белән бәйле сыйфаты. Аның бар булуының башы. ягъни туган көне юк. Әгәр дә Аннан да алда берәр зат булган икән. ул Аның барлыкка китерүчесе. тудыручысы сыйфатында каралыр иде. Аллаһы Тәгалә үзе яратучы, бар кылучы. Аның алдыннан. Аннан элек һичкем вә һичнәрсә юк иде. Барчаларны Ул үзе бар кылды. ягъни. яратты.

Икенчесе — **бәка.** Бәка сыйфатының мәгънәсе, ягъни Аның барлыгының чиге юк. булуы мөмкин дә түгел. Ул мәңге яши, мәңге бар! Коръәндә әйтелгән: «Һуал-әүвәлү вәл-ахиру вәз-заһиру вәл-батыйнү», ягъни «Ул әүвәл һәм Ул ахыр һәм Ул күренүче һәм Ул яшерен». Моның мәгънәсе: «Ул бар әүвәлдәгеләрдән дә әүвәлгерәк, Ул барча ахыргылардан да ахыргырак вә мәңгелек, Ул барча билгелеләрдән дә билгелерәк. Ул барча яшереннәрдән дә яшеренрәк вә серлерәк». Аның барлыгы безнең дәлилләребезнең никадәр күп булуына бәйле түгел, бәлки. дәлилләребезнең күплеге илә акылыбыз вә йөрәгебез танып белә. Әмма Аның ниндилегенә акылларыбыз һичкайчан ирешмәс вә төшенеп бетә алмас. без белмәгәннәрне вә күрмәгән-танымаганнарны да тану вә белүдән азат түгел. Аннан һичнәрсәне яшереп калдыру мөмкин түгел. Ул — мәңгелек!

Өченчесе — **мохәлифәтүн лилхәвадиси сыйфаты,** ягъни, бар булганнар арасында һичнәрсә вә һичкем Аңа охшаш түгел, Аның сыйфатларын вә үзенчәлекләрен кабатлый алмый. Шулай ук Аллаһы Тәгалә үзе дә һичкемгә вә һичнәрсәгә охшаш түгел. Коръәндә мондый аять бар. «Ләйсә кәмисилһи шә-үн». Мәгънәсе: Аңа охшаш һичнәрсә юк! Әгәр дә охшашы бар икән, димәк, ул Аллаһы Тәгаләгә тиңдәш булыр иде. Аңа тиң күрелер иде.

Сәлибия сыйфатларыннан дүртенчесе — **кыйамүн бинәфсиһи,** ягъни.. нәфседән өстен. Чөнки Аллаһы Тәгалә барлыгында һичнәрсәгә мохтаҗ түгел. ризыкка да, яшәү урынына да, башкасына да. Аллаһы Тәгалә уңда да, сулда да, җирдә дә, күктә дә түгел, чөнки болар берсе дә юк чагында да Ул бар иде. Аларны бар итүдән соң Үзенең барлыгын бетермәде. Әмма Ул аларга мохтаҗ түгел иде. Алар Аңа мохтаҗ. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына барысы мохтаҗ, хәтта галәм, дөнья, һәммә нәрсә дә. «Валлаһул-ганиййү вә әнтүмүл-фукәа-у», ягъни Аллаһы Тәгалә сезнең Аны танымавыгыздан өстен һәм бөек, сез үзегез Аның савабына. ярлыкавына, рәхмәтенә мохтаҗ бит, әгәр дә Аны танысагыз. савабы үзегезгә, кире каксагыз, бәласе шулай ук үзегезгә. Моның белән Аллаһыга файда да, зыян да китерә алмыйсыз, барысы да үз башыгызга гына булачак.

Бишенчесе — **вәхданият сыйфаты.** Моның мәгънәсе шуннан гыйбарәт. Аллаһы Тәгалә үзенең затына күрә һәм эшләрендә бердәнбер, асылда Аның охшашлары, иптәшләре һәм ярдәмчеләре юк. Ул боларга мохтаҗ түгел. Аңа арадашчылар кирәкми. Әгәр дә сайласа, Аның ихтыярында. Бар нәрсәгә көче җитә. Аннан да бөек булу мөмкин түгел. «Кул һуа Аллаһу әхәдү», ягъни, әйт, Аллаһы Тәгалә Ул — бер, бердәнбер.

Сәбутия, ягъни раслаучы, ачык дәлил белән белдерелгән сыйфатлары сигез төрле. Шуларның беренчесе — **хәйат**, ягъни һәрдаим терек булуы. икенчесе — **гыйлем,** ягъни һәрнәрсәне белеп торуы; өченчесе — **сәмгъ,** ягъни, һәрнәрсәне ишетеп торуы; дүртенчесе — **бәсар,** ягъни. барысын да күрүе; бишенчесе — **ирадәт,** ягъни теләүдән барысын да хасил кылуы; алтынчысы — **кодрәт,** (ягъни, һәрнәрсәгә көче-кодрәте җитүе; җиденчесе — **кәлам,** ягъни сүздә булуы, сөйләве; сигезенчесе — **тәквин,** ягъни һәрнәрсәне бар кылуы, хасил итүе, яратуы. Бу сыйфатларның һәммәсенә тиешле төшенчә һәм мәгънәләр бар. аларны мәгънәвия сыйфатлары дип аерып йөртәләр, шулай булгач, алары да сигез. Сәбутия сыйфатында беренчесе хәйат булгач, мәгънәвия сыйфатында ул — **хәй,** ягъни яшәүче, икенче сәбутия сыйфаты — **гыйлем,** мәгънәвиядә — **галим,** белеп торучы; **сәмгъ, басыйр, кадыйр, мерид, мотәкәллим, мөкүн.** Боларны аерым-аерым карап үтик.

Хәй. Аллаһы Тәгалә терек, әмма тереклеге безнең кебек кан һәм җан белән түгел. бәлки, Үзенә күрә терек вә тере. Аның тереклегенең аүвәле-башы һәм ахыры юк. «Аллаһу лә илаһа иллә һуа әл-хәййүл-каййумү», ягъни, бердәнбер хаклык белән коллык ителә торган илаһи зат Аллаһы Тәгаләдән башка юк, Ул бер, Ул терек, Ул тереклегенчә яшәүче (Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи зат юк, Ул һәрвакыт терек).

Галим. Аллаһы Тәгалә барча олы-кече, зур-вак әйберләрне һәммәсен белеп торыр. Әмма Аның белүе безнең кебек акыл ярдәмендә түгел, өйрәнүдән дә килми. Аның белемнәренең әүвәлгесе дә, ахыргысы да юк. Гыйлемендә чиксез вә төпсез, ягъни никадәр икәнлеге дә билгесез. Ул борынгыны да, бүгенгене дә, киләчәкне дә белеп тора, эшләгәнне дә, уйлаганны да, яшерен һәм ачыкны да — һәммәсен дә белеп тора. «Галимүлугайби вәш-шәһадәти», ягъни, яшерен һәм билгеле-күренгәнне белүче галим Ул Аллаһы Тәгалә. Аның гыйлеменнән читтә бер генә нәрсә дә юк. «Вәәннә Аллаһа кад ахата шә-ин гыйльман».

Сәмгъ. Аллаһы Тәгалә барча тавышларны вә сүзләрне, уйларны вә фикерләрне, теләкләрне вә хисләрне ишетеп торучы зат. Әмма Ул безнең кебек колак белән түгел, бәлки, Үзенә күрә ишетү рәвеше белән барысын да ишетә. Аңа моның өчен арадашчы да, юлдаш та, фикердәшчә дә кирәк түгел. Ул моны Үзенең сыйфатлары белән башкара. Шушында мөэминнәрнең иманы башка дин тотучылардан аерылып тора. Бер-бер носари-христиан Аллаһы Тәгаләгә үз теләген яки ярлыкавын. үтенер өчен поп, монах яки башка шундый арадашчыга мөрәҗәгать итүне кирәк табып ялгыша. Шуның өчен кабатланырга мәҗбүрбез: Аллаһы Тәгалә арадашчыларга мохтаҗ түгел. Ул болай да барысын да ишетеп тора! Каты итеп кычкыручыны да, кырмысканың аяк атлавын да, җил тибрәнүен дә. «Вә хуас-самиигулә-галиим», ягъни, Ул Аллаһы Тәгалә ишетүче-белүче. Шушы аятьне хәтергә сеңдерү яхшы булыр, бәхәсләрдә яхшы делилегез итеп файдаланырсыз.

Басыйр. Аллаһы Тәгалә барчаларны күреп торучы. Әмма Ул безнең кебек күз белән түгел, бәлки, Үзенә хас күрү рәвеше белән күрә. Борынгы дини китапларда Аның күрү дәрәҗәсен караңгы төндә кара ташка басып үткән кара кырмысканың аяк атламын күрә алу дәрәҗәсендә дип белдерәләр. Ул ачыкны һәм яшертенне дә күрә ала. Качып эшләү Аллаһы Тәгаләнең күреп торуыннан азат итүгә ия түгел. Димәк, Аның карашыннан читтә калу мөмкин түгел. Шулай ук, мине күрсен әле, нинди яхшылыклар эшлим бит. дип кат-кат белдерү-күрсәтүгә дә мохтаҗлыгы юк. Ул күрә һәм күрмичә калмый. «Вә һуас-самиигулә-басыйру», ягъни, Ул Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәне ишетүче-күрүче.

Кадыйр, ягъни ирадәт сыйфаты. Аллаһы Тәгалә бар нәрсәне барлыкка китерүче. Аның моңа көч-кодрәте җитә. Ул — кодрәт иясе. Әмма безнең кебек түгел, Үзенә хас рәвештә хасил кыла. Аллаһы Тәгаләгә биек тауны барлыкка китерү яки кырмысканы хасил кылу өчен бернинди авырлык вә кыенлык юк, барысы да бер. Теләге белән барчаларны мизгел эчендә юк итә ала, мизгел эчендә кабат барлыкка китерергә сәләтле. «Бул!» — дисә, барысы булыр, «Бет!» — дисә, барысы да бетәр. Һәркайсы Аның теләгенә буйсыныр лар. Чөнки Ул галәмнең вә җирләрнең бердәнбер хуҗасы, Аннан башка бернинди хуҗа вә өмер итүче була алмый. Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә вә теләгенә бер генә нәрсә дә авыр вә кыенга килә алмый. Ул теге яки бу эшкә, затка, сыйфатка һәм башкасына көче җитмәүдән азат, гиҗаз була алмый. «Иннә Аллаһа галаа көлли шаин кадыйр», ягъни, хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәгә көче җитүче зат! Шушы аять Аллаһы Тәгаләнең кадыйр икәнлеген дәлилләп тора.

Мәрид. Аллаһы Тәгалә — теләүче. Адәм балаларының күңелендә теләкләре булган кебек, Аның да теләкләре бар. Әмма безнеңчә түгел, теләк рәвеше башкача. Безнең кебек теләмәгән эшләрен башкармый, бәлки, теләге аша хасил кыла. Аңа һичбер нәрсә үз ихтыяҗларын хасил кылу өчен кирәк була алмый, чөнки Аның мохтаҗлыгы юк. Аның һәрнәрсәдә һәм эштә хикмәтләре бар. Ул хикмәтләрен төшенеп бетерергә мөмкинлек юк. Ул нәфседән азат, ни теләсә, шуны кыла. «Фәггаалүн лима йурииду», ягъни, Аллаһы Тәгалә теләгәнен кылучы.

Әгәр Аллаһы Тәгалә теләмәсә, хәтта бер чебен дә канатларын тибрәтмәс. Барысы да Аның теләгеннән тора. Аның теләге һәрнәрсәгә вә һәркемгә җитә. Үтенсәң: «Йа Ходаем, бу дошманымның кылыч күтәргән кулы хәрәкәтсез калсын?!» — дисәң, бу теләгеңне Хак Тәгалә кабул кылса, дошманыңның кулы таш кебек катып, ихтыярсыз калыр.

Шул ук вакытта бәндәләр өчен кече теләк бар. Моны нәрсә дип аңларга? Хикмәт шунда ки, Аллаһы Тәгалә тырышлык куймыйча бәндәләргә теләгән эшләрен башкарырга мөмкинлек калдырмый, теге-яки бу нәрсәне хасил итәр өчен һичшиксез бәндәгә көч сарыф итү кирәк. Теләгенә ул шул вакытта ирешә. Әгәр дә теләгәне яхшылык белән ирешелә икән, яманлыктан азат икән, ул вакытта аңа гамәле савап булып кайта. Мәгәрем ки, теләгенә яманлык белән, усал эшләр ярдәмендә, начар гамәл белән ирешә икән, ул вакытта аңа Аллаһы Тәгалә газап бирә. Белеп торырга кирәктер, Җир йөзендә һәркемнең үз теләге вә үз нияте бар. Алар һәркайсы моңа ирешү өчен көч түгәләр, кайвакыт теләк-омтылышлары кисешә яки туры килә. Берсе икенчесеннән уздыру нияте пәйда була. Әгәр дә шунда кайсы да берсе яманлык вә явызлык белән теләген хасил итәргә тырыша икән, белеп торсын, җавап төшерелер, көннәр үз чиратлары белән үтеп, газап табар. Яхшылык вә дөреслек белән теләгенә ирешкәннәр исә ахыр чиктә саваплы булырлар. «Иннә Аллаһа йәфгалү маа йәшаа-у», ягъни, хакыйкатьтә Аллаһы Тәгалә үзенең теләгәнен хасил итәр, кылыр. Бу аятьтән чыгып эш йөрткәндә, бәндәләр сабырлык белән коралланыр, гамәлләренең ахыры савап буласын белеп торыр.

Кәлам. Аллаһы Тәгалә сөйләүче, әмма ул адәм балалары төсле сөйләшмес, Аның сөйләве үзгәчә. Аның сөйләвен ике төрлегә бүлеп карыйлар. Беренчесе — Ул теләгәнен күңелләребезгә төрле уй вә фикер аркылы җиткерә. Әмма һәркем максатын үзенчә билгеләп, шуның белән саваплы яки җәза табарлык эш башкара. Кайберәүләр үзләренең нәфселәренә вә көнчелек хисләренә ияләр, Аллаһы Тәгаләнең аларга ирештергән теләген кабул итмиләр, аңа буйсынмыйлар. Бу рәвешле нәфсе-шайтанга иярүләре — гөнаһ, бер көнлек максатларына ирешеп, гомерлек җәзага керәләр. Шунлыктан Аллаһы Тәгаләдән китерелгән теләк белән нәфсенең саташтыруын һичшиксез аера белергә кирәк. Казага калуың бик мөмкин. Нәфсе-шәйтаннан илаһи хәбәрне аерырга теләгән кешеләр борынгылардан калган акыл вә хикмәтләргә күбрәк игътибар итсеннәр иде. Аллаһы Тәгаләнең сөйләүче булуының икенче сыйфаты шунда ки, Ул пәйгамбәрләргә үзенең гыйлемен җиткерде, аларга китаплар бирде. Муса пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләнең гыйлемен Тур тавында алды, Мөхәммәд пәйгамбәребез Аллаһы Тәгалә белән мигъраҗ вакытында сөйләште. Давыт пәйгамбәргә Зәбур ирешә. Мөхәммәд пәйгамбәребез Коръәннең мигъраҗда Аллаһының үзеннән алганнарыннан калган аятьләрен Җәбраил фәрештә аша ишетте. Болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең сөйләүче икәнлеген дәлилләп торалар.

(Дәвамы бар).

Атналык манзара TV

Дүшәмбе

13 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.40 Балалар өчен «Тамчы» 19.00 «Татарстан» 19 30 «Телебуклет» Тапшырулар анонслары 19 40 «Түгәрәк өстәл» Реформалар программасы ул нинди булырга тиеш? 20 10 «Әлли-бәлли-бәү» 20 20 «Сайлауларны каршылап» 20 50 Р Вәлиев Телевизион фильм «Яшисе килә» 2 нче бүлек 21 55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 Эфирда музыка 7 30 «КиноМеню» 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары 8.15. 11 05 «Юл патруле» Атналык йомгак 8.30. 14.45 «Даруханә» 8 40 «Сул аяктан!» (МТЖ) 9.20. 13.00 «90х60х90» 9 40 Диск-канал 10 00 «Канун» 10 30 Сериал «Один к десяти» 11 20 Атна фаразлары 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал «Мстители» 13 15 Нәфис фильм «Анна и Командор» 15 00 Телесериал «Флиппер» 15.53 «Кино музыкасы» 16 10 «Минем кино» В Лановой 16.50 «Минем тарих» В Войнович 17 35 Теледискотека 19 05 Документаль фильм «Их нельзя не любить» 19.30 «Видеомода» 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 20. 23 45 «Шәһәр» информацион программасы 20 45 «Лариса» яңалыклары» 21 15 Телеэкспресс 21 35 «Криминаль хроника тележурналы» 22 00 Нәфис фильм. «Вертихвостка» (АКШ-Австрия)

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00. 6.30. 7 00. 7 30. 8.00. 8.30 «Көн хроникасы һава торышы» 6.05. 7 05. 8.05 Спорт яңалыклары 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7.20 «Матбугат төме» 7 40 Сәламәтлек моритонингы 7 50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы 8.40 «Койрыклы бишле» 9.00. 12.00. 15 00. 18 00. 0.00 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал «Тропиканка» 10.05 «Могҗизалар кыры» 11.00 «Кеше һәм закон» 11 30 Телеуен «Коен таны» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 Сериал. «Два капитана» 4 нче серия 14 05 Сериал «Тридцать случаев майора Земана» 15 20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15.40 Балалар телевидениесе фестивале Телеспектакль «Приключения крысы Сисы» (Рига) 16.00 «Йолдызлар сәгате» 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята» 17 00 Балалар телевидениесе фестивале «Надежда-95» Музыкаль тапшыру (Баку) 17 30. 0.35 «Спортның җиде коне» 18.20 Телесериал «Тропиканка» 19 10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 Телеуен «Коен таны» 20.00 «Әгәр. » В Познерның авторлык программасы 20 45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Фантастик детектив: «Электронные жучки-7» «Уловка» 22.45 Театр һ телевидение Л.Максатова 23.30. 0 10 Сериал «Твин Пикс»

«РУСИЯ»

7 30 Эшлекле кешеләр вакыты 8.00, 11 00, 14.00, 17 00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк . » 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8 50 «Барысы да аз-азлап» 9 40 «Телегазета» 9.45 «Музыкаль экспромт» 10.00 «Үтә яшерен» 10.50 «Мөһим мизгел» 11 20 Милиция хроникасы 11 30 Академик А А.Никонов истәлегенә багышланган тапшыру 11 50 «Уеннар» 12 15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Төрле төстәге призма» 17 20 «Яңа тармак» (Волгоград, Самара) 17 30 «Минем сугыш» Д.Гранин 18.20 «Алыргамы-алмаскамы» 18.30 «Коткару-911» 19.25 «Сабый авызыннан» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 «Дүшәмбе саен детектив» «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм «Масонские тайны» (Бөекбритания) 21 45 Репортер 22.05 «Хакыйкать мизгеле» 23.30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 «299-00-00» хезмәте. 23.55 Төнге телесериал «Бремя доказательства» (АКШ) 3 нче серия

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 45, 11 45 «Тәҗрибә» 8 15 «Киңәшче» 8.45 Балалар өчен 9.15 «Гүзәллек» 10.20 «Тош юрау» 10.40 «Такмаклар» 11 15 «Коллекционерлар» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30 22 45 ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13.25 «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13 45 Мультфильм «Подушка для солнышка» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Нәфис фильм «Первая любовь» (Италия) 17 35 Өлкән классларда укучылар өчен телеуен «Кушулар, нульләр» 18.00 — Мәхәббәт тигезләшә»
22 20 «Шәһәр эшләре» 22 35 «Музыка мизгеле» 23.00 «Спорт спорт спорт » 23 15 Музыкаль шоу «Телекомпакт» 0 15 Нәфис телефильм «Валентина» (Италия) 12 нче серия

Сишәмбе

14 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.25 Документаль фильм «Миссия особого назначения» 18 50 «Идел» яраткан журналыбыз 19.00 «Татарстан» 19.30 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.35 «Авыл» Балык Бистәсе районында очрашулар 20 10 «Әлли-бәлли-бәү» 20 20 «Пульс» 20.35 Лирик концерт 20.50 Нәфис фильм «Крылья» Режиссер Л Шепитько 22.05 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10. 18.35 «Эфирда музыка» 7 30. 20 20. 0.00 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (13 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15. 11 05 «Юл патруле» 8.30. 14 45 «Даруханә» 8 40 «Сул аяктан!» 9.20. 13 00 «90х60х90» 9.40 «Диск-канал» 10 00 «Минем кино» В Лановой 10 40 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 «Атна һәлакәтләре» 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал «Спасатели Малибу» 13 15 Нәфис фильм «Послушай Феллини» 14 35 «Кино музыкасы» Л Гурченко 15.00 «Музыка һәм матбугат» «Каләм осталары» «Самоцветы» төркеме 15 55 «Современник» театрының юбилей кичәсе 18 45 Сериал «Против течения» 10 нчы серия 19 35 «Мохит һәм сәламәтлек» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Коммерция әйләнмәсе» 21 05 «Эфирда музыка» 21 15 Телеэкспресс 21 35 Нәфис фильм «Вертихвостка» 2 нче серия 0.20 Самбо буенча дөнья чемпионатында 0 35 Русия киносы коне Нәфис фильм «Сто дней до приказа»

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00. 6.30. 7 00. 7 30. 8.00. 8.30 «Көн хроникасы һава торышы» 6.05. 7 05. 8.05 Спорт яңалыклары 6 10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 15 Яшьләр өчен яңалыклар 7 20 «Матбугат төме» 7 40 «Шанс» 7 50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы 9.00, 12.00, 15.00. 18.00. 0.00 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал «Тропиканка» 10.05 «Әгәр » В.Познерның авторлык программасы 10.50 «Көлкеле манзара» Е.Петросян алып бара 11 20 Мультфильм 11 30 Телеуен «Коен таны» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 Сериал «Два капитана» 5 нче серия 14.05 Сериал «Тридцать случаев майора Земана» 15.20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15.45 Балалар телевидениесе фестивале Телеспектакль «Приключения крысы Сисы» (Рига) 2 нче кисәк 15.55 «Мультитроллия» (Мәскәү) 16 10 «Тылсымлы дөнья, яки Синема» 16 35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» (Франция) 17 00 Балалар телевидениесе фестивале «Ышаныч дулкыны» (Петрозаводск) 17 30, 1 40 «Спортның җиде коне» 18 20 Телесериал «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19 35 Телеуен «Коен таны» 20.00 «Тема» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Н.Рыбников Э.Рязановның «Девушка без адреса» кинокомедиясендә 23.25 «Мәскәү-Кремль» 23.45. 0 10 Теле-шоу «50х50» 0.50 Сериал «Твин Пикс»
Төнге канал
2 10, 3.20 Кино-цирк шоу «Бар кочәнә»

«РУСИЯ»

7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11 00, 14.00, 17 00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк » 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Телегазета» 10.50 «Мөһим мизгел» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 30 Безнең хәбәрчедән «Язмышлар» 11 50, 17 50 Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «РОСТ» компасы 16.50 «Ай готулар» 17 20 «Яңа тармак» «Өч гасырдан соңчы» 18.15 А.Гурнов «Саф инглизчә репортаж» 18.25 «Сезнең партнер» 18 40 «Әйдәп баручы фаразы» 19 10 «L» клубы 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Нәфис фильм «Призраки зеленой комнаты» 22.00 Клип-антракт М Распутина 22 10 «Губернаторлар клубы» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 23.55 Төнге телесериал Нәфис фильм «Бремя доказательства» (АКШ) 0.45 «Криминаль хәбәрләр экраны»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 40 «Чемпион» 7 45, 11 45 «Тәҗрибә» 8.15 «Әдәплелек» 8.45 «Язалар» 10 10 «Бибу-шоу» 10.20 «Тош юрау» 10.40 «Лаборатория» 11 15 «Аукцион» 12 10 «Джаз» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13.25, 15.40, 17 40 «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13.45 Мультфильм «Голубой слоненок» 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14 30 Телефильм «Мануэла» 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 Нәфис фильм «Серые волки» 1 нче һәм 2 нче серияләр 17 50 «Бөтен Русия буйлап» 18.00 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә 22 00 «Кино йорты» А Петренко. В Гостюхин. Б Окуджава. Р Чхеидзе һәм башкалар 23.00 «Спорт спорт спорт » 23.15 Нәфис фильм «Серые волки» 1 нче һәм 2 нче серияләр

Чәршәмбе

15 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 19 15 «Татарстан» 19 40 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19 45 «Сайлауларны. каршылап» 20 10 «Әлли-бәлли-бәү» 20 20 «Синә усал итеп сөйләмәм» Һади Такташ 20 35 Телесериал премьерасы «Вспышка» 2 нче серия

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7 30. 20 20 23 45 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (14 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15 Документаль фильм «Голубая планета» 9 10 «21 нче параграф» 9 40 Документаль фильм «Жак Анри Партиг» 1 нче, 2 нче кисәкләр 10.30 Мультфильм 10 40 Сериал «Один к десяти» 11 10 «Тегеләр. кемнәр » 11 30 «Атна низаглары» 12 00 Нәфис фильм «Ф как Фербенкс» 13 35 А Политковский программасы «Красноярск таянычлары» 14 25 Детектив сериал «Ночная жара» 15 25 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 15 40 «Юл патруле» 15 55 «Диск-канал Джон Леннон» 16 40 Документаль фильм «Загадка климата» 17 35 Нәфис фильм «Нос» 19 15 «Утсыз төтен булмый» 19 20 «Поза» 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Казан автосалоны» 21 15 Телеэкспресс 21 35 «Үз кешеләр» 22 10 Нәфис фильм «Живой щит» 0 25 Red Wave тәкъдим итә «Депеш Мод» төркеме

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6.00, 6 30. 7 00. 7 30. 8 00 «Көн хроникасы һава торышы» 6 05, 7 05. 8 05 Спорт яңалыклары 6.10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 20 «Матбугат төме» 7 40 «Досье» 7 50 «Монетный двор» 8.10 «Иртә» кунагы 8 20 «Стиль» 8.25, 19 05 «Сайлаулар-95» Бәхәсләр. 9.00, 12.00, 15 00, 18.00. 0.00 «Яңалыклар» 9.15 Телесериал «Тропиканка» 10.00 «Тема» 10 45 «Хайваннар дөньясында» 11 20 Мультфильм 11 30 Телеуен «Коен таны» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12.50 Сериал «Два капитана» 6 нчы серия 14 00 Сериал «Тридцать случаев майора Земана» 15.20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15.40 Балалар телевидениесе фестивале «Шулай бервакыт Раштуада» (Сыктывкар) 16 10 «Джунглилар чакыруы» 16.35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» (Франция) 17 00 Балалар телевидениесе фестивале «Кайчан да булса » (Пятигорск) 17 30, 1 55 «Спортның җиде коне» 18.20 Телесериал «Тропиканка» 19 35 Телеуен «Коен таны» 20.00 «Хәтерләсеннәр өчен » Ю Богатырев 20 45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Футбол Европа чемпионатына сайлап алу матчы Русия һәм Финляндия җыелма командалары 23.40 «Йолдыз» милли премиясе музыкаль программа тәкъдим итә 0.10 «Матбугат клубы» 1 55 Сериал «Твин Пикс»
Төнге канал
2.25, 2.50 «Хит-конвейер»

«РУСИЯ»

7 00, 9.30, 18.40, 23.55 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11 00, 14.00, 17 00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк » 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9 10 «Крестьян мәсьәләсе» 10.00 «Телегазета» 10.05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Гадәттән тыш канал» 11 30 «Безнең хәбәрчедән» «Язмышлар» 11 45 «Беркем дә онытылмаган» 11 50, 17 50 Мультсериал «Камень сновидений» 12 15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия» 16.05 «РОСТ» компасы 17 20 «Яңа тармак» «Ерак Көнчыгыш» 18.05 «Видеошигърият» П Васильев 18.25 «Эксповидео» 19.10 «Сезнең хокук» 19.25 «Үз уены» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 20.35 Телесериал «Санта-Барбара» 21 30 М.Боярский «Домино»сы 22 10 «Гадәттән тыш канал» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 0.25 Төнге сеанс Нәфис фильм «Да здравствует любовь!» (Польша)

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 40 «Чемпион» 7 45, 11 45 «Тәҗрибә» 8.15 «Киңәшче» 8.45 Балалар өчен 9 15 «Гүзәллек» 10 10 «Бибу-шоу» 10.20 «Тош юрау» 10.40 «Такмаклар» 11 15 «Аукцион» 12 10 «Спартак» 12 40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22 45 ТВ мәгълүматлары 13.10 «Яшәү стиле» 13.25, 17 10, 22.00 «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13.50 «Табиблар, фармацевтлар һәм пациентлар өчен тапшыру «Рецепт» 14 00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм «Мануэла» 15.20 Бакчачыларга киңәшләр 15.50 Нәфис фильм «Чужак»
Балалар телевидениесе
17 20 «Паутиныч яшәгән җирдә» 17 40 «Буй-буй музыка» 18.00 «Сайлаулар-95» 22 05 «Блеф-клуб» 23 00 «Спорт спорт спорт » 23 15 Юмористик программа «Золотой телец» 0.05 «Консерватор» 0.35 «Консерватор» экраны Люксембургта бер көн Телефильм (Франция)

Пәнҗешәмбе

16 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 30—8 00 «Чулпан» информацион программасы 19 15 «Татарстан» 19 40 «Телебуклет» Тапшырулар анонслары 19 45 «Сайлауларны каршылап» 20 10 «Әлли-бәлли-бәү» 20 25 ГАИ мәгълүматлары 20 30 Хөкүмәт сәгате 20 55 «Азнакай балкыйсың йолдызлардай» 22 05 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7 30 20 20 0 20 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (10 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15 10 40 «Юл патруле» 8 30 14 45 «Даруханә» 8 40 «Сул аяктан!» 9 20 13 10 «90х60х90» 9 40 Диск-канал 9 50 Юмористик сериал «Один к десяти» 10 55 «Нью-Йорк Нью-Йорк» 11 25 Детектив сериал «Ночная жара» 13 25, 16 20 Нәфис фильм «Я тебя ненавижу» 15 00 «Тегеләр кемнәр » 15 20 Ток-шоу «Мин үзем» «Мин балаларымны ирәмә бирдем» 18 15 CNN «Стиль» 18 35 «ПОСТ – музыка яңалыклары» 19 15 «Computerlife» 19 20 «Ушуайя» 19 40 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Коммерция әйләнмәсе» 21 05 «Казанские ведомости» нәрсә турында сөйләде» 21 15 «Телеэкспресс» 21 35 «Бары тик кызык өчен генә» 22 05 Нәфис фильм «Мальвиль» (Франция — Германия)

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6 00. 6 30 7 00 7 30, 8 00 «Көн хроникасы һава торышы» 6 05 7 05 8 05 Спорт яңалыклары 6 10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 15 «Яшьләр өчен яңалыклар» 7 30 «Матбугат төме» 7 50 «Монетный двор» 8 10 «Иртә» кунагы 8 20 «Ел буе яшелчә бакчасы» 8 25. 19 05 «Сайлаулар-95» Бәхәсләр 9 00 12 00 15 00 18 00 0.00 «Яңалыклар» 9 15 Телесериал «Тропиканка» 10.00 «Хәтерләсеннәр өчен » Ю Богатырев 10 45 «Сәяхәтчеләр клубы» 11 30 Мультфильм 11 40 «Төмле» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12 55 Сериал «Тайны семьи де Граншан» 1 нче серия 14 00 Сериал «Тридцать случаев майора Земана» 15 20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15 40 Балалар телевидениесе фестивале Телеспектакль «Запомни принцесса» (Санкт-Петербург) 16.35 Яшьләр өчен сериал «Элен и ребята» 17 00 Балалар телевидениесе фестивале «Песиләрнең төрлесе була» (Днепропетровск) 17 05 «Рок-дәрес» 17 30, 1 30 «Спортның җиде көне» 18 20 Телесериал «Тропиканка» 19 35 «Лото-миллион» 20 00 «Без» В Познерның авторлык программасы 20 45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Д.Чаплин К Сауранның «Выкорми ворона» фильмында 23 45. 0 10 «Музыка күзәтүе» 0.40 Сериал «Твин Пикс»
Төнге канал
2.00. 2.50 «Русский балет» Мәскәү дәүләт театры

«РУСИЯ»

7 00, 9 30 18.40. 23.55 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11 00, 14 00, 17 00, 20 00, 23 00 «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк » 8.30 «Йолдызлар сөйли» 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап» 9 10 «Крестьян мәсьәләсе» 10.00 «Телегазета» 10 05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 30 «Музыкаль экспромт» 11 50, 17 50 Мультсериал «Камень сновидений» (Бөекбритания) 12 15 «Яңа тармак» 12 30 14 20 «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16 30 «Көнгерә» 17 20 «Яңа тармак» «Сүнгән йолдыз?» 18.15 Клип-антракт А.Губин һәм И Салтыкова 18.25 «Сезнең партнер» «Русиянең тимер юллары» 19 10 «Кипрас Мажейка» «Параллельләр» 19 25 «Русча караоке» 20 25 «Бәйнә-бәйнә» 20 35 Телесериал «Санта-Барбара» 21 30 «Битлек-шоу» 22.10 Хоккей МХЛ чемпионаты «Динамо» (Мәскәү) · «Химик» (Воскресенск) 3 нче период «Лужники» стадионыннан тапшыру 23.30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте 0.25 «Эшләпәдә калыгыз» 0.55 «Криминаль хәбәрләр экраны» 1 05, 1 35 «Сәүдә йорты «Ле Монти»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 40 «Чемпион» 7 45. 11 45 «Тәҗрибә» 8.45 «Язалар» 9 15 «Гүзәллек» 10 10 «Бибу-шоу» 10 20 «Төш юрау» 10.40 «Лаборатория» 11 15 «Аукцион» 12 10 «Джаз» 12 40 «Кунак» 13.00 15.30 22 50 ТВ мәгълүматлары 13 10 «Яшәү стиле» 13 25 «Музыка мизгеле» 13 30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13.45 Мультфильм «Чудесные лекарства» 14 00 «Ашыгыч ярдәм» 14 30 Телесериал «Мануэла» 15 20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15 45 Нәфис фильм «Дон Кихот» 17 25 Мультфильм «Малахитовая шкатулка» 17 45 «Бөтен Русия буйлап» 18 00 «Сайлау-95» 19 00 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә
22 00 Видеофильм премьерасы «Театр имени меня» Е Шифрин 23.05 «Спорт спорт спорт » 23 15 Нәфис фильм «Тайна папоротников» (Үзбәкстан)

ҖОМГА

17 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 30—8 00 «Чулпан» информацион программасы 19 15 «Татарстан» 19 45 «Видеоспорт» 19 55 «Татарстан Дәүләт Советында» 20 25 «Әлли-бәлли-бәү» 20 30 «Җомга көн кич белән» Альманах 21 10 Яп концерты 21 25 Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М Сәлимҗанов турында документаль фильм 21 55 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7 30 20 20 23 40 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 «Телеэкспресс» 16 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 15 11 05 «Юл патруле» 8 30 14 45 «Даруханә» 8 40 «Сүл аяктан!» 9 20 12 45 «90х60х60» 9 40 Диск канал 10 00 «Красноярск таянычлары» 10 30 Юмористик сериал «Один к десяти» 11 20 15 50 «Спорт атнасы» 11 50 «Валюта бәясе» 12 00 Детектив сериал «Ночная жара» 13 00 Нәфис фильм «Порочный круг» 15 00 «Тегеләр кемнәр » 15 20 Сериал «Мелочи жизни» 16 20 Мультфильм 16 50 Нәфис фильм «Древо желания» 18 40 «Суперспорт» 19 00 Нәфис фильм «Корабль любви» 19 50 «Кыюлар һәм матурлар» 20 45 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 20 55 «Экология хәбәрчесе» 21 00 «Җәнлекләр турында хикәятләр» 21 15 Телеэкспресс 21 35 Нәфис фильм «Музыку не оставить» (АКШ) 0 05 Джентльмен-шоу 0 35 «Эротека Венеры» телепрограммасы

1 НЧЕ КАНАЛ

Иртә 6 00 6 30 7 00 7 30 8 00 «Көн хроникасы» Һава торышы» 6 05 7 05 8 05 Спорт яңалыклары 6 10 «Иртәнге физик күнегүләр» 7 10 Мультфильм 7 20 «Матбугат темә» 7 40 «Гаибәтләр» 7 50 «Монетный двор» 8 10 «Иртә» кунагы 8 20 «Нечкәлекләр» 8 25 19 05 «Сайлау-95» Бәхәсләр 9 00 12 00 15 00 18 00 0 00 «Яңалыклар» 9 15 Телесериал «Тропиканка» 10 00 «Без» В Познерның авторлык программасы 10 40 «Таң йолдызы» 11 25 «Бар да өйдә чакта» 12 10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары 12 55 Сериал «Тайны семьи де Граншан» 2 нче серия 13 55 Сериал «Тридцать случаев майора Земана» 15 20 Мультсериал «Виджит спешит на помощь» 15 40 «Яңа чынбарлык» 16 10 Фильм-әкият «Варвара-краса длинная коса» 17 30 1 50 «Спортның җиде көне» 18 20 Телесериал «Тропиканка» 19 35 «Кыргый кыр» 19 55 «Могҗизалар кыры» 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Сериал «Приключения королевского стрелка Шарпа» 23 00 «Караш» 23 45 «Спорт программасы «Трасса» 0 10 Триллер «Плохое влияние» (АКШ)

Төнге канал

2 20 «Ялта-Мәскәү Транзит-95» эстрада җырларын яшь башкаручыларның 10 нчы халыкара телевизион конкурсы 3 50 4 30 «Көлкеле манзара» Е Петросян алып бара

«РУСИЯ»

7 00 9 30 18 40 23 55 «Сайлаулар-95» Дәүләт Думасы 7 30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8 00 11 00 17 00 20 00 23 00 «Хәбәрләр» 8 25 «Кирәк кирәк » 8 30 «Йолдызлар сөйли» 8 35 Сәүдә йорты «Ле Монти» 8 50 «Ритмика» 9 05 Клип-антракт Р Чернавина һәм Б Киров 9 10 «Крестьян мәсьәләсе» 10 00 «Телегазета» 10 05 Телесериал «Санта-Барбара» 11 20 «Милиция хроникасы» 11 30 «Музыкаль экспромт» 11 45 Мульти-пульти «Приключения капитана Врунгеля» 12 15 17 20 «Яңа тармак» 12 30 14 20 «Эшлекле Русия» 16 05 «Шау-шулы яңалыклар» 16 20 «Көн дә бәйрәм» 16 30 «Озынайтылган көн» 16 50 «Ай тотучы» 17 35 Клип-антракт В Царикати 17 40 Нәфис фильм «Зорро» 31 нче һәм 32 нче серияләр 19 10 «Бию-экспресс» 19 25 Вертикаль «Хөкүмәтнең эш көннәре» 20 25 «Бәйнә-бәйнә» 20 35 Телесериал «Санта-Барбара» 21 30 «Үз үзенә режиссер» 22 10 «К-2» тәкъдим итә «Иван и Дыховичный «Уловка-22» программасында 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 «299-00-00» хезмәте 0 25 Нәфис фильм «Кто знает или Пуля для генерала» (Италия) 2 25 2 55 «Ералаш»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 40 «Чемпион» 7 50 11 45 «Тәҗрибә» 8 15 «Киңәшче» 8 45 «Балалар өчен» 9 15 «Гүзәллек» 10 10 «Би бу-шоу» 10 20 «Төш юрау» 10 45 «Такмаклар» 11 15 «Коллекционерлар» 12 40 «Кунак» 13 00 15 30 22 45 «ТВ мәгълүматлары» 13 10 «Яшәү стиле» 13 25 15 40 22 00 «Музыка мизгеле» 13 30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13 45 Мультфильм «Подушка для солнышка» 14 00 «Ашыгыч ярдәм» 14 30 Телесериал «Мануэла» 15 20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15 45 Мультфильм «Разбойники и музыканты» 16 00 Нәфис фильм «Тайны папоротников» Балалар телевидениесе 17 10 «Әкият арты әкият» 18 00 «Сайлаулар-95» 18 30 Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә

22 05 «Шәхси эш» 23 00 «Спорт спорт спорт » 23 10 Нәфис фильм «Джо» (АКШ)

ШИМБӘ

18 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8 00 «Чулпан» информацион программасы 16 50 Мультфильм 17 00 Хоккей МХЛ чемпионаты «Нефтехимик» (Түбән Кама) — «Ак Барс» (Казан) Түбән Камадан трансляция 19 35 «Татарстан» 20 05 «Әлли-бәлли-бәү» 20 15 «7 нче стиль» 20 50 «Гадәти шимбә» 21 30 Р Мөхәммәдиев Телевизион фильм премьерасы «Истәлек өчен Гыйлемханга » 1 нче бүлек «Кайту» 22 50 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда музыка» 7 30 20 20 23 45 «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс 17 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8 10 «Коммерция әйләнмәсе» (14 ноябрь көнендәге тапшыруны кабатлау) 8 30 «Видеомода» 8 50 «Лариса» яңалыклары» 9 20 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 9 30 «Мохит һәм сәламәтлек» 9 45 «Үз кешеләр» 10 20 «Поза» 10 50 «Казан автосалоны» 11 20 «Эфирда — музыка» 11 30 «Атнага бер тапкыр» юмористик тапшыруы 12 00 Шимбә сериалы «Флиппер» 12 55 Хәрби телевидение 13 25 «Сез шаһит» 13 50 Сериал «Мелочи жизни» 14 25 Нәфис фильм «И снова Анискин» 15 35 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 15 50 «Юл патруле» 16 05 Мультфильм 16 20 Телесериал «Детективы на полставки» 17 15 «Яшерен йомыш» 17 40 «Дублик» 18 00 «Исәнмесез!» 20 45 «Мавыгулар дөньясы» 21 15 Телесериал «Тропическая жара» 22 10 Нәфис фильм «Орландо» (Бөекбритания) 0 10 Нәфис фильм «История «О» 1 50 «Эротека Венеры» телепрограммасы

1 НЧЕ КАНАЛ

7 45 9 10 «Уяныгыз» телеканалы 8 45 «Пастырь сүзе» Митрополит Кирилл 9 00 18 00, 0 00 Яңалыклар 10 10 Балалар өчен телеүен «Оттырма» 11 00 «Иртәнге почта» 11 30 «Төмле» 11 50 Телесериал «Живопись великие имена — Лотрек» 12 25 «Бомонд» 12 50 Мультфильм 13 00 «Кеше һәм закон» 13 25 «Хатирәләребез фильмнары» «Исправленному верить» 15 20 «Автомобиль һәм мин» 15 50 «Хайваннар дөньясында» 16 30 «Европага тәрәзә» Д Киселев алып бара 17 00 «Шулай бервакыт » 17 10 «Бәхетле очрак» 18 20 Кинематографъ 16 05 «Алтын серия» 1968 ел «Трембита» 20 45 «Тыныч йокы нәниләр» 21 00 «Вакыт» 21 50 Сериал «Приключения королевского стрелка Шарпа» (Бөекбритания) 22 40 «Русиянең иң яхшы мультипликациясе» «Происхождение видов-2» «Сон смешного человека» 23 10 «Брейн-ринг» 0 10 С Параджанов фильмы «Тени забытых предков»

Төнге канал

1 50 «Ялта-Мәскәү Транзит-95» эстрада җырларын яшь башкаручыларның 10 нчы халыкара телевизион конкурсы 3 15 4 20 Телевизион фильм «Чужая жена и муж под кроватью»

«РУСИЯ»

8 00 14 00 20 00 23 00 «Хәбәрләр» 8 25 «Йолдызлар сөйли» 8 30 «Вовкулакия яки Доктор Никодимның табышмагы» 8 45 «РОСТ» компасы «Өмет стартлары» 9 00 Нәфис фильм «Одиссея» (Канада) 9 25 «Алтын ачкыч» 9 45 «Әдәплелек» 9 55 «Клип-антракт» В Светлов 10 00 «Парламент атнасы» 10 45 «Винил джунглилары» 11 15 «Мәскәүгә кадәр ерак» 12 00 Пилигрим Русиянең сәяхәтләр бюросы 12 45 НБАның иң яхшы уеннары 13 45 «Каинар Уңлык» 14 20 «Де факто» 14 35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Мегрэ и невезучий инспектор» 15 20 «Сезне Лариса Рубальская чакыра» 16 15 «Дөнья экраны йолдызлары» 16 45 «Футболга чикләр юк» 17 30 «Хатирәләребез театры» В Смехов программасы 18 00 Документаль фильм «Невозможный Бесков» 19 00 «Йолдызлы яңгыр» 20 25 Нәфис фильм «Курица» 21 40 «Киноафиша» 22 00 «Үтә яшерен» 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40 0 40 «299-00-00» хезмәте 23 55 «Аваз юлы»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8 55 Музыкаль-шоу «Телекомпакт» 9 55 «Яшәү стиле» 10 10 «Хатирәләребез җырлары» А Петров 10 25 Балалар өчен нәфис фильм «Магия черная и белая» 11 40 «Исән калырга өмер» 11 55 «Рандеву» Ю Надервель 12 25 Жорж Брассанс Телефильм «Я пришел на свидание с вами » (Франция) 13 30 Табиблар фармацевтлар һәм пациентлар өчен тапшыру «Рецепт» 13 40 «Теледоктор» 14 00 «Эшкә урнаштыру телевизион хезмәте» 14 15 Нәфис фильм «День ангела» 15 30 «Тарихи альманах» 16 05 Документаль фильм «Цивилизация Мальцева» 16 25 «Гыйбадәтханә» Балалар телевидениесе 16 55 «Алтын ачкыч» 17 10 «Ырғыт өйдә» 17 55 «Музыка мизгеле» 18 00 Видеофильм премьерасы «Матильда»

21 55 «Оранж» телевидениесе «Телемәсәң — карама» каналын тәкъдим итә 22 45 ТВ мәгълүматлары 23 05 Оранж ТВ тәкъдим итә «Навигатор» 23 20 Нәфис фильм «Скрытое оружие» АКШ) 0 30 «Бәллүр ачкыч» музыкаль клиплар фестивале 0 50 Нәфис фильм «Франкенштейн 90» (АКШ)

ЯКШӘМБЕ

19 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8 00 «Чулпан» информацион программасы 19 00 «ТОН» (атналык телекүзәтү) 19 35 «Автокалейдоскоп» 19 50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 20 00 «Әлли-бәлли-бәү» 20 10 Р Мөхәммәдиев Телевизион фильм премьерасы «Истәлек өчен. Гыйлемханга » 2 нче бүлек «Йөзлекләр» 21 15 «Бәйрәм белән, дуслар!» Авыл хуҗалыгы һәм азык эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көненә карата 22.45 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7 00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау) 8.30 «Шәһәр» информацион программасы 8.55 «Коммерция әйләнмәсе» (18 ноябрь тапшыруын кабатлау) 9 15 «Бары тик кызык өчен генә» 9 45 «Дублик» 10.05 «Ушуайя» 10.25 «Суперспорт» 10 45 Самбо буенча дөнья чемпионатында 11 00 «Мавыгулар дөньясы» 11 30 «Computerlife» 12.00 Мультфильм 12.20 Телесериал «Подводная «Одиссея» команды Кусто» 13 10 «Каләм осталары» «Самоцветы» төркеме 14 00 Нәфис фильм «Мистер Икс» 15.35 «Атнага бер тапкыр» 16.05 Нәфис фильм «Бриллиантовая рука» 17 50 Телесериал «Детективы на полставки» 18 45 Сериал «Спасатели Малибу» 19 45 «Тамаша залы» («КиноМеню») 20 15 «Җирле вакыт» Информацион программа 20.45 Нәфис фильм: «Молодой Джо забытый Кеннеди» 20 35 «Исәнмесез!» (18 ноябрь тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7 50 «Спортлото» тиражы 8.00, 9 10 «Уяныгыз!» телеканалы 9.00, 15.00, 18.00, 0.00 Яңалыклар 10.30 «Бар да өйдә чакта» 11 00 «Иртәнге йолдыз» 11.50 «Турыдан-туры» 12 00 «Русиягә хезмәт итәм» «Армия кибете» 12.30 «Уйна гармун» 13.00 «Н» шәһәрендә 13.25 «Пи» билгесе астында 13.55 Телесериал «Мой друг — лошадь» 7 нче фильм 14 25 Көлкеле манзара Е.Петросян алып бара 15.20 «Опера турында хикәятләр» 16 10 «Сәяхәтчеләр клубы» 16 55 «Эшле кеше» 17 15 Мультфейерверк «Легенды острова сокровищ», «Погончики динозавров» 18.20 Футбол күзәтүе 19 05 «Җыр-95». 20.00 «КВН-95» Икенче ярымфинал. Санкт-Петербург университеты һәм «Гусарлар эскадроны» командалары 22.00 «Якшәмбе» 22 55 Сериал «Приключения королевского стрелка Шарпа» 0 10 «Бер күрүдә ярату» 0 45 Документаль фильм «В будущем году в Иерусалиме».

Төнге канал

1 40 Богдан Титомир «Коч» 2.30, 2.55 Джаз дөньясында

«РУСИЯ»

8.00, 14 00 20.00 23.00 Хәбәрләр 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30 «Мазай бабай кунакханәсе» 8.45 Балалар өчен сериал «Одиссея» (Канада) 9 10 Клип-антракт С Беликов 9 15 «Хроно» Авто һәм мотоспорт дөньясында 9 45 «Хәерле иртә» Чемпионнар өчен иртәнге аш» 10 15 «Беренче нөсхә». 10.25 «Аты-баты » 10.55 Сәүдә йорты «Шарп» 11.00 «Сәгать унберге хәбәрләр». 11 15 «Рус лотосы» 12.00 «Хайваннар дөньясында» 12 55 «Зур хоккей» 13.35 «Китап киштәсе» 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык» 14 35 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм «Мегрэ и невезучий инспектор» 15.25 «Безнең бакча» 15.55 «Ак карга» 16 25 «Алтын шпор» 16.55 «Тапшырулар тартмасы» 17 10 «Өч баһадир». 18 00 Мультфильмнар «Чокнутый», «Новые приключения Винни Пуха» 18 55 «Зур низаг» 19 25 «Ксюшада кунакта» 20 25 Нәфис фильм «Гамлет» 22 50 Клип-антракт Т Овсиенко белән кофе эчкәндә 23 30 «Вакыт елгасы» 23 35 «Автомизгел» 23 40, 0 55, 1 10 «299-00-00» хезмәте 23 55 «Примус» 0 25 «Аниматека»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8 00 «Бу сезнең көнегез» 8.30 «Шифалы сүз» 9 00 Музыкаль-шоу «Парадлар парады» 10 00 «Яшәү стиле» 10 15 Мультфильм «Голубой слоненок» 10 30 Нәфис фильм «Франкенштейн-90» (АКШ) 12 00 «Якшәмбе лабиринты» 13 10 «Хыяллан» студиясе 13 20 «Музыка мизгеле» 13 30 «Страсти-мордасти» 13 45 «Янган кульъязмалар» Голицин китапханәсе 14 10 «Классика-5» Б Эйфман 15 30 Депутатларга сүз бирәбез 16 10 «Наобум» Ю Антонов 16 25 Футбол буенча Италия чемпионаты

21 05 Нәфис фильм «Бедный богач» (Италия) 22 45 ТВ мәгълүматлары 23 10 «Адәм алмасы» тәкъдим итә «Һоу смокинг» 23 55 «Адәм һәм Хава плюс»

Һәркөнне 8.00 (якшәмбедән тыш), 19.00, 9.00 (шимбә), 10.00 (шимбә, якшәмбе) сәгатьләрдә — Мәскәүдән информацион һәм аналитик программалар трансляцияләнә.

ДҮШӘМБЕ, 13 НОЯБРЬ

6.00, 19.10 Соңгы хәбәрләр 6 15 Иртәнге дулкында 6.48, 20.28 Татарча өйрәнәбез 6.53, 7 58, 20.33 Һава торышы 6.55, 7 50 Белдерүләр 7 00 Информацион-музыкаль программа 7 45, 20.33 Тапшырулар программасы 18 20 «Уйныйбыз да, җырлыйбыз да » 18 48 «Дүшәмбедән — дүшәмбегә» Мәдәният-сәнгать яңалыклары 19.40 Һәвәскәр башкаручылар концерты.

СИШӘМБЕ, 14 НОЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.00, 19 10 Соңгы хәбәрләр 6 15 «Иртәнге дулкында» 6.48, 20 28 Татарча өйрәнәбез 6.53, 7.58, 13 15, 20 33 Һава торышы 6.55 7.50 Белдерүләр 7 15 Концерт 7 45, 12.30, 20.33 Тапшырулар программасы 12.25—14.35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12.35 Башкортстан артистлары концерты 13 05 Республика газеталарына күзәтү 13.20 «Юллар чатында» информацион программасы 13.35-14.35 «Русия Федерациясе федераль җыелышының Дәүләт Думасына сайлауларга карата» 18.20 «Яшьлек» студиясе 18 48 «Көн темаларына» Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.40 Татарстан Композиторлары Берлеге пленумы яңалыклары.

ЧӘРШӘМБЕ, 15 НОЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.10, 19 10 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында» 6.48, 20.28 Татарча өйрәнәбез 6.53, 7.58, 13 10, 20.33 Һава торышы 6.55 7 50 Белдерүләр. 7 15 Концерт. 7 45, 12.25, 20.33 Тапшырулар программасы. 12.30—14.35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12 35 Концерт «Без Татарстан җирендә яшибез» 13 15 Республика газеталарына күзәтү 13 35-14 35 «Русия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына сайлауларга карата. 18.20-18 40 «Кеше һәм закон». 19.40 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 16 НОЯБРЬ

6.00, 7.00, 13.10, 19.10 Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.48, 20.28 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7 58, 13.30, 20.33 Һава торышы. 6.55, 7.50 Белдерүләр. 7 15 Концерт. 7.45, 12.35, 20.33 Тапшырулар программасы. 12.35—14.35 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.40 «Балалар җырлый». 13.15 Республика газеталарына күзәтү. 13.35-14.35 Русия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына сайлауларга карата. 18.20 «Казан һәм казанлылар» (шәһәр радиочелтәре буенча). 19.40 Симфоник музыка концерты. Дирижер Ф.Мансуров.

ҖОМГА, 17 НОЯБРЬ

6.00 «Балкыш» 6.48 Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.30, 20.33 Һава торышы. 6.55, 7 50 Белдерүләр. 7.00, 13.10, 19.10 «Соңгы хәбәрләр» 7 15 Концерт. 7.45, 12.30, 20 33 Тапшырулар программасы. 12.30—14.35 «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.35 Г.Ибушев, Л.Хәсәнова концерты. 13.15 Республика газеталарына күзәтү 13.35-14.35 Русия Федерациясенең Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына сайлауларга карата. 18.30 «Чишмәләр» (чуваш теленде) 19.40 «Музыкаль очрашулар» Әңгәмә-концерт

ШИМБӘ, 18 НОЯБРЬ

6.00, 7 00 Соңгы хәбәрләр. 6 15 Авыл эшчәннәре өчен концерт 6.58, 7 58, 9.55, 14 05 Һава торышы. 7 15 Иртәнге концерт 7 45, 9 55, 14 05 Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8 10 «Сезнең хатларыгыз» 8.20 «Мәсьәләгә бер караш» 8.35 «Көмеш кыңгырау» 8.55 Шагыйрә Л Шакирҗанова белән очрашу 9.25 «Кардәшлеккә чикләр юк» 10.20 «Алай түгел, болай ул » Язучы Т Миңнуллинга 60 яшь. 11.20 «Әбугалисина» клубы 11 50 «Танышу» 12.20 Татар халык көйләре 13 15 Яңалыклар эстафетасы 13.35 «Яшьлек» студиясе.

ЯКШӘМБЕ, 19 НОЯБРЬ

6.00 «Татарстан дулкынында» 6.48, 7.50, 13 00 Тапшырулар программасы. Һава торышы 6 55, 7 55 Белдерүләр 7 00 «Хәерле иртә» 8 00 «Идел белән Урал арасында» Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы 9 10 «Мин сандугач түгел, җырлыйм өзелеп » И Юзеев шигырьләре буенча төзелгән радиокомпозиция 11 10 «Табигать дуслары» 11 40 «Тел күрке — сүз» 12 10 Яп концерты 13 05 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре» Таҗи Гыйззәтнең 100 еллыгына багышланган кичәнең язмасы

ИҖТИҺАТ

Мамонт тешеннән... сөяк шулпасы

Язучы Әхәт Гаффар белән «Казан» журналы редакциясендә сөйләшеп утырабыз. Редакция мәркәзебезнең Чистай урамында яңа гына төзелеп беткән бинага күчкән. Шуңа күрә бүлмәләрдә урнаштырылмаган җиһазлар, төрле аппаратуралар һәм китап өемнәре чәчелеп ята.

— Бер дә гаҗәпләнмә, күчкән мәлдә андый тәртипсезлек — табигый хәл, — ди миңа Әхәт. — Барысы да үз урыннарына куелгач, эшебез ипле һәм көйле барыр.

— Бирелдә ашханә эшлиме соң? — дим.

— Анысы әлегә юк. Тамак ялгарга «Пресса йорты»на йөрибез. Бүген дә эшкә нык ашап килдем.

— Ничек инде нык ашап?

— Мамонтның азау тешеннән сөяк шулпасы пешердем. Ашның өресе дә чат май иде. Шуңа, ахрысы, капкан ризыгым бик туклыклы булды. Алла боерса, мамонт тешеннән тагын сый әзерләргә исәбем.

— Әхәт, тузга язмаганны сөйлисең түгелме соң? Өрдерергә яратасың син. Әмма бу кадәресен синнән көтмәгән идем.

Әңгәмәдәшем куе һәм тырпаеп торган зур мыегын бармаклары белән сыпырып алды да, елмаеп куйды. Аннан күзләрен миңа төбәп:

— Һәй, Касыйм абый, бергә сөйләшеп утыруның да кызыгы шунда бит, — диде. — Кайчак бераз өрдерергә дә ярый.

— Мамонт теше сиңа ничек килеп эләкте? Әллә геологик экспедициядә йөрдеңме?

— Мәскәүдә булганда, миңа аны геолог студентлар бүләк иткән иде. Мин әлеге тештән шәмдәл ясадым. Шәмнең яме шәмдәл белән, дип юкка гына әйтмиләр бит. Җитмәсә, ул — бик тә борынгы хайван теше. Без хәзер бу җан иясен музейларда һәм рәсемнәрдә генә күрәбез. Миндә башка сәер табылдыклар да бар. Елга буенда йөргәндә, мәсәлән, борынгы күбәләк уелып калган таш кисәгенә тап булдым. Бусы — минем өчен кыйммәтле табылдык,

Әлеге җөйпәк соры ташны мин дә кулыма тотып карадым. Чыннан да, анда уртача зурлыктагы күбәләк рәсеме төшкән иде. Ул, ташта канатларын җәеп, чокырланып үелган. Бу таш, ничәмә миллион еллар җир кочагында ятып, аннары өскә чыккандыр.

Алар — җиде бертуган. Габдрахман абзый белән аның җәмәгате Бибигайшә апа биш малай һәм ике кыз үстергәннәр, укытып кеше иткәннәр, барысын да олы тормыш юлына чыгарганнар. Балалары арасында конструктор да, укытучы, язучы һәм журналистлар да бар. Аларның һәркайсы үз көнен үзе күрә, үз тормышы белән яши.

Габделбәр — араларында иң өлкәне. Ул гаиләсе белән туган авылы Олы Әшнәктә (Балык Бистәсе районы) яшәп ята. Габделхак, Казан авиация институтын тәмамлап, Чаллыга эшкә киткән, КамАЗ акционерлык җәмгыятенең двигательләр заводында конструктор вазифасын башкара.

Габдрахман абзыйның өченче улы Габделәхәтне без Әхәт Гаффар дип кенә йөртәбез. Шулай дими, башкача аңа ничек эндәшесең. Язучы бит ул, унике китап авторы. Әсәрләре арасында хикәяләр, повестьлар һәм романнар да бар. Боларга журналистика өлкәсенә караган дистәләрчә мәкаләләрен, очерклар, публицистик язмаларын да өстәсәк, Әхәт Гаффарның бик актив эшләгәнен күрербез. «Әҗәт», «Язлар моңы» исемле хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары, «Бер йотым су» дигән хикәяләр җыентыгы, «Бодай бөртеге» һәм «Тегермән ташы», «Олы юлның тузаны», «Казан» журналында әле генә дөнья күргән «Богау» романнары, республика театрларында сәхнәләштерелгән һәм хәзер дә уйнала торган пьесалары, башка күләмле әсәрләре язучының тынгысыз иҗат эшчәнлеге хакында сөйлиләр.

Бертуган энеләре Ренат белән Рәкыйп тә журналистиканы үз иттеләр. Аларның беренчесе — «Татар иле» газете мөхәррире, икенчесе Татарстан радиосында «Яшьлек» редакциясен җитәкли.

— Мин матур һәм төрле төстәге шома ташларны да читләтеп үтмим, — ди Әхәт.

— Син сөлгеләр, металл акчалар да җыясың икән. Акчалар — нумизматика мине кызыксындырмый әлегә. Чөнки аның белән күпләр шөгыльләнә. Ә менә чигүле сөлгеләр җыю белән кайчан шөгыльләнә башладың?

— «Яшь ленинчы» газете редакциясендә эшләгән вакытта сөлгеләр белән кызыксына башладым. Бу шөгыльгә алынуымның сәбәбе дә минем өчен онытылмаслык бер хатирә булып күңелдә саклана.

1972 елда Ә.Гаффар Бакый Урманче фатирында, төгәлрәк әйтсәк, атаклы рәссамның остаханәсендә була. Бакый ага аны картиналары, таштан һәм агачтан ясаган скульптуралары белән таныштыра, яшь каләм иясенә хезмәтләре хакында сөйли, аңа дистәләрчә еллар буе җыйган сөлгеләрен дә күрсәтә. Татар халкының бөек рәссамы осталар тукыган төрле чәчәк-үсемлек һәм геометрик бизәкләр төшереп чигелгән сөлгеләр белән кызыксынган икән, бу — бер дә гаҗәп түгел. Чөнки әлеге көнкүреш әйберләрендә халкыбызның борын-борын заманнардан килгән, гасырлар кичкән милли традицияләре, гамәли сәнгать үрнәкләре якты һәм калку гәүдәләнә. Шулар белән бергә аларда стильләшкән рәсем-бизәкләр, төсләр байлыгы да күзләрне иркәли, күңелдә горурлык хисләре уята.

Сөлгеләрнең дә сынлы сәнгатебез аксакалы Бакый Урманчега җан азыгы, рухи азык буларак хезмәт итүләренә тамчы да шикләнмим. Чөнки Ә.Гаффарның «Богау» романы белән танышканнан соң, моның шулай булуына тагын бер кат инандым. Автор үзенең әлеге әсәрендә сөлгегә бәйле бер вакыйганы тасвирлый. Бу вакыйга 1937 елның җәендә була. Авылда Сабантуй бара. Апалар, яшь киленнәр Сабантуй бәйгеләрендә җиңгән батырларга бүләккә сөлгеләр, кулъяулыклар, ашъяулыклар әзерләгәннәр. Бәйрәм тантанасы кызып киткән бер мәлдә мәйданда НКВД вәкиле лейтенант Баязит Юмашев пәйда була. Аның күзе колгада эленеп торган бер сөлгегә төшә. Сәер бизәкләр белән чигелгән була ул. Аның баш-башларына төшерелгән геометрик бизәкләре арасында ике рәт булып, парлы свастикалар үрелмәсе урнашкан. Вәкилнең башында «Болар фашист билгесе бит», дигән фикер уяна. Ул сөлгенең иясен таптыра. Шушы бүләге аркасында, Гыйльмурый килен күпме җәбер-золым кичерә, төрмә шулпасын эчә, тормыш әчесен-төчесен татый.

— Уйлап карасаң, ерак тарих битләренә күз төшерсәң, свастика — бик тә борынгы билге икән. Ул шумерларда, һиндлар, иранлылар, румлыларда, кайбер төрки халыкларда күп гасырлар буена «Мәңгелек билгесе» булып хезмәт иткән. Безнең заманда Гитлер аны фашизм символы итеп ала, — ди Әхәт Гаффар.

— Бу сөлгене сиңа кем бүләк итте? — дип сорыйм аңардан.

— Аны миңа авылыбыз кешесе — фермада эшләүче Илдар биргән иде. Хәзер минем ике дистәгә якын шундый бүләгем бар.

Ә.Гаффарның яраткан тагын бер шөгыле — агач тамырлары һәм ботакларыннан уеп-кисеп, төрле кош-корт һәм хайван сурәтләре иҗат итү. Бу — аның хыял-фантазиясе колачлы булуын күрсәтә, күзләре дә үткен икән. Шундый сыйфатларга ия булмасаң, агач материалда төрле рәвештәге затларны шәйли алмас идең. Шуңа, ахры, Әхәт гамәли сәнгатьнең бу төрендә дә материалдан иркен файдалана, үзенчәлекле скульптура әсәрләре иҗат итәргә тырыша.

Менә аның агач тамырыннан эшләнгән «Мөгезле елан»ы. Чыннан да, ул мөгезле. Гәүдәсенең бер өлеше җыелып-чуалып богарләнгән. Әхәт аңа каләм урнаштыру өчен җайланма да ясап куйган.

Аның «Ишәк», «Бөркет», «Шүрәле», «Жираф», «Төлке» кебек скульптуралары образлы һәм үзенчәлекле булулары белән кызыклы. Кирәк бит авторга шундый затларга якынча охшаган агач тамырларын һәм ботакларын күрә һәм таба белергә. Ул, кисеп-уеп, аларны теге яки бу җан иясе рәвешенә, үзләренә генә хас хәрәкәт халәтенә керткән.

Әнә, ишәк, муенын югары сузып, бер якка башын борган да, тирә-юньгә аваз сала шикелле. Ә менә бөркет, тарлавык үзәненә очлы күзләрен төбәп, канатларын җәеп җибәрергә, таш-кыядан зәңгәр биеклеккә күтәрелергә җыена.

— Бу скульптура өчен материалны кайдан таптың? — дим авторга.

— Авылда, үзебезнең абзар түшәменнән таптым. Кайчандыр ул кыек бәбкәсе булган. Кирәкле өлешен кисеп алдым да, аны бөркет рәвешенә керттем.

Әхәт гөмбә һәм җиләк җыярга да ярата икән. Урманда, агачлар арасында гөмбә эзләп йөргәндә, аның күзе эшләпәле хәзинәләрне генә түгел, кошларга һәм җәнлекләргә охшаган агач тамырларын яки ботакларын күрергә дә өлгерә. Тын аудан кайтып, гөмбәләрен эшкәрткәч, һәм аларны ризык итеп әзерләгәч, ул кулларында кәкре-бөкре агач ботагын тегеләй-болай әйләндереп карый, аңарда теге яки бу затка охшаган билгеләр һәм чалымнар табарга тырыша. Кыскасы, хыялый Әхәт фантазиясен эшкә җигә, әкият геройларын искә төшерә, аларны күз алдыннан кичерә, образны тапкач, кулына пычак яки пәке ала...

— Фәридә, менә бу әзерләмә шүрәлегә охшаганмы? — дип хатынына эндәшә.

Хәләл җәфәте (ул — Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре), агач ботагын кулына алып, аңа күз төшерә дә:

— Менә бу төшен эшкәрткәч, урман сарыгына охшар, — ди.

Атаның шундый сораулар белән өлкән кызы Ләйләгә дә мөрәҗәгать иткән чаклары аз булмаган.

Әхәт, җәмәгате яки кызы хуплавыннан рухланып китеп, яңа уемнар ярдәмендә скульптураның төгәллегенә һәм образлылыгына ирешә.

Ләйлә дә сынлы сәнгатькә гашыйк. Ул рәсемнәр ясый. Әтисенең әдәбият һәм журналистика өлкәләрендәге эшчәнлеге, гамәли сәнгатьнең әлеге төре белән мавыгуы, күрәсең, аңа да уңай йогынты ясаган. Ул Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә 3 курсны тәмамлап,



хәзер Төркия башкаласы Анкара университетында укый. Сеңлесе Сөмбел дә әдәбият юлыннан китмәкче, ул Мәрҗани исемендәге гимназиянең унынчы сыйныфында укый, әкиятләр һәм хикәяләр яза, әсәрләрен туплап, китап чыгарырга ниятли.

Ә.Гаффар әнә шундый тормыш белән яши.

— Әгәр кешедә гамәли сәнгать әйберләре ясау, агач тамырлары һәм ботакларыннан кызыклы скульптуралар иҗат итү ялкыны кабынса, — ди язучы, — ул татар халык фольклорын, шул исәптән әкиятләрне, алардагы геройларны яхшы белергә, хыял-фантазиягә бай булырга тиеш.

Шундый әйберләр ясау өчен агач материалны урман-әрәмәләрдә, туйралыкларда, тагын да хикмәтлеләрен ташлы таулардагы куаклы җирләрдә табып була. Күзең очлы булса, кирәкле агач материалны шул биләмәләрдә тиз табарга мөмкин.

Аларны җилсез һәм күләгәле урыннарда киптерү шарт. Шулай эшләгәндә, әзерләмә бозылмый, аны эшкәртергә дә җиңел була.

Касыйм ТӘХАУ.



ҺӘР КҮҢЕЛДӘ ШИГЫРЬ УТЫ БАР

Гали ага Мөхәммәтҗанов — сугыш ветераны, милиция органнарында 35 ел буена эшләгән, отставкадагы подполковник. Яшькә шактый өлкән булса да, төс-кыяфәте, үз-үзен тотышы һаман да яшьләрчә. Ләкин сүз ул хакта түгел... Хәер, сүз нәкъ менә шул хакта! Гали ага шигырьләр, хикәяләр яза, тормышны, табигатьне, кешеләрне яратып яши. Аның шигырьләрен көндәлек матбугатка мин кайчандыр тәкъдим иткән идем инде. Ә менә бу юлы ул редакциягә автобиографик бер әсәреннән өзек китергән.

— Беләсезме, — диде ул үзе, — мин әдәбиятны, китапларны гел укып-күзәтеп барам. Татар язучыларының әсәрләре арасында үткәнебезне дөрес аңларга теләп язылган батыр-батыр роман-повестьлар, мемуарлар, тарихи кыйссалар бар. Тик менә әллә ни ерак тарихта да булмаган, кем әйтмешли, артыбызга ук терәлеп торган мари урманнарын, андагы гыйбрәтле фаҗигане кайчан күрсәтербез? Суслонгер лагерьларын?..

— Сизәм, сез инде яза башлагансыз һәм язасыз? — дидем мин, аның бу сүзләренә җавап итеп.

— Анысы шулай, ләкин...

Гали аганың әнә шул сүзеннән үк аңладым: ул Суслонгер лагерьларының ни-нәрсә икәнен дә, акылга сыймаслык башбаштакларның асылын да, әрәмгә корбан булган меңнәрчә яшь гомерләрнең фаҗигасен дә үзенчә тойган-төшенгән инде. Тормышының бүгенге үрләреннән ул бу хәлләргә кат-кат борылып караган. Әмма аның әлеге хәлләрне үзенең яшь чагы, солдатка алынган чагы үрләреннән, шул вакыт күзлегеннән сөйлисе килә, унҗиде яшьлек егетнең — авыл укытучысының — хәрби лагерьда кичергәннәре бүгенге көн өчен яңалык булырмы дип шикләнә. Ә нигә шикләнергә? Минемчә, килер буыннарга да, бүгенге чордашларыбызга да сугыш чоры яшьлегенең фаҗигасе хакында сөйлисе сүзләр бар әле, аларны сөйләү кирәк әле... Әйе, без Гали аганың бу хактагы әсәрен укып өйрәнә торабыз һәм бүген укучыларыбыз дикъкатенә аның бер шигырен тәкъдим итәбез.

Нияз АКМАЛ.

Гали МӨХӘММӘТҖАНОВ

Ә Алсуның туган көне иде...

Ул ашыга иде үз өенә,
Туган көне иде кызының, —
Кибет турларыннан узып китте,
Балалары белән җитәкләшеп
Үткән аталарга кызыгып.

Ә бүләге — күптән әзер иде,
Көтә иде кызы кулларын.
Бүләк өйдә иде. Тик нинди көч
Борды аның барыр юлларын?!

...Тын тыкрыкта сабый елап тора,
Үрсәләнеп беткән, өзлегеп, —
Тыны кайнар, үзе төмам туңган,
Куллары да туңган, боз кебек.

Ничек моны күрми үтә алсын,
Яшь милиционер, сержант абыйсы?!
Ул сорады:
— Ник елыйсың, сеңлем?
Исемең ничек? Кайда яшисең?

— Таня... — диеп җавап бирде кызчык
(Бу шәһәрдә күпме Таня бар?!) —
Иванова Таня... (Күпме бездә
Таня кебек Ивановалар?!)

Ә сержантның күз алдына килде
Үз өендә көткән Алсуы.
Алсу, Алсу — аның туган көне...
Ә бу сабый елап калсынмы?!

Китте сержант аның өен эзләп,
Урам буйлап озак йөрделәр.
Эзли торгач, сораштыра торгач,
Кызның өен табып бирделәр...

Ул өенә чапты. «Кичер, кызым!..» —
Шул сүз иде аның уенда.
Алсу инде күптән йоклый иде,
Бүләк курчак иде куенында.

«САНДУГАЧ-95»

Үзәк үзенә дәшә

17 ноябрьдән 7 декабрьгә кадәр «Казан» милли мәдәният үзәге «Сандугач-95» җыр фестивален Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры бинасында уздыра.

Концертларны 17-20 ноябрьдә яшь җырчы Габделфәрт Сафин башлап җибәрә. Ә 21 ноябрьдән 27 ноябрьгә кадәр аларны халкыбызның яраткан җырчылары Зәйнәп Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов дәвам итә.

28 ноябрьдә тамашачыларны Гөлдания Хәйруллина үзенә дәшә.

29 ноябрьдә танылган язучы, шагыйрь, драматург, күп җыр сүзләре авторы Фәнис Яруллинның иҗат кичәсе.

30 ноябрьдә концерт-спектакль, дуэт-башкаручыларны тыңларга рәхим итегез. Сез бу көнне Зәйнәп Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов, Хәйдәр Бигичев һәм Зилә Сөнгатуллина, Айдар Фәйзрахманов һәм Венера Ганиева, Нәфисә һәм Ризван Хәкимовлар, Рамил Миндияр һәм Миләүшә Кайбицкая, Зөфәр Хәйретдинов һәм Алсу Хисамиева, Фәридә һәм Роберт Тимербаевлар, Валентина һәм Атлас Исламовлар, Римма һәм Венер Мөхәммәдиевләр белән очрашырсыз.

1 декабрь көнне Казаннан яшь җырчылар Рөстәм Закиров, Эльвира Хәйруллина, Энҗе, Чаллы шәһәреннән — Вероника Еремина, Екатеринбург шәһәреннән — Хәйдәр Гыйльфанов, Уфа каласыннан — Светлана Хәкимова, Яңавылдан — Наил Шәймәрдәнов, Сабадан — Рисәнә Мостафина, Чаллыдан — Азат Хөсәенов сезгә «Энҗе карлар ява» исемле зур концерт бүләк итәчәк.

2-3 декабрьдә — Башкортстан йолдызлары концерты. Сез анда: Фидан Гаффаров, Идрис Газиев, Айдар Галимов, Радик Динәхмәтов, Нәзифә Кадыйрова, Светлана Хәкимова, Таңчулпан Бабичева белән очрашырсыз.

4 декабрьдә — Уфа каласыннан Радик Динәхмәтов җырлаячак.

5-7 декабрьдә Салават Фәтхетдинов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Зөфәр Билалов, Айдар Галимов, Габделфәрт Сафин, Гөлдания Хәйруллина, Радик Динәхмәтов, Асаф Вәлиев, Зөлфәт Хәким һәм Кырым татарларының «Кырым» ансамбле катнашында фестивальне йомгаклау концертлары узачак.

Билетлар концертлар булачак урыннарда сатыла.
Белешмәләр өчен телефоннар: 36-78-11, 36-78-71.

ҮЧАЯН ЙОЛДЫЗЛЫГЫ АСТЫНДА ТУГАННАР

Котлыйбыз!

10 ноябрь

ХӘМИДУЛЛИН Леон Хәйдәр улы — язучы.

МӘХӘММӘТҖАНОВ Рәүфәль Сабир улы — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры директоры.

11 ноябрь

Рөстәм **КУТУЙ** (КУТУЕВ Рөстәм Гаделшә улы) — язучы.

Ләбиб **ЛЕРОН** (ЛЕРОНОВ Лемон Леронович) — шагыйрь.

12 ноябрь

БАЛАНДИН Михаил Егорович — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры оркестр солисты, Татарстанның атказанган артисты.

МӘСГУТОВ Идрис Мөдәррис улы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

САДЫЙКОВА Әминә Нәҗми кызы — Әлмәт драма театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

ШӘЙДУЛЛИН Миңнехан Габдулла улы — скульптор.

13 ноябрь

ВАСИЛЬЕВА Аграфена Антоновна — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты.

СИРАҖЕТДИНОВ Тәлгать Касыйм улы — Казан техник университетының идарә, маркетинг һәм кәсәбәчелек кафедрасы мөдире, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире.

14 ноябрь

АКМАЛОВ Нияз Рәшит улы — шагыйрь.

ӘХМӘТОВ Тәлгать Гакыйф улы — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры дирижеры.

15 ноябрь

БОРТЯКОВ Виталий Николаевич — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры балет солисты.

ВАШУРОВ Андрей Иванович — рәссам.

ГАЙНАНОВА Фәния Гариф кызы — тәрҗемәче.

ЗАРИПОВ Илдар Касыйм улы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, РФнең атказанган рәссамы.

КАСЫЙМОВ Хатыйп Касыйм улы — язучы.

НӘФИКОВ Кәнәфи Абзалетдин улы — рәссам.

16 ноябрь

МИНҺАҖЕВА Асия Миръякут кызы — шагыйрә.

ТИМБИКОВА Кояш Закир кызы — язучы, публицист.

ХАРИСОВ Зөфәр Назыйм улы — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

Татарстан китап палатасы коллективы, тормышиптәше **Илдус МИРЗАХАН улының** вакытсыз үлүе сәбәпле, китап палатасы директоры Рауза Сибгат кызы Хананованың һәм аның туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Мәдәни ҖОМГА

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миңнеәхмәт ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
22-13-08 — гомуми фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — иҗтимагый тормыш, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-06-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый.

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә.

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Безгә иганәләк ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты: 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга.

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде.

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4465